ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**И.Г. Закирова**

# ӘҮВӘЛ БАШЛАП НИ БЕТТЕ

Казан
2017

**УДК 398.4**
**ББК 82.3(2Рос=Тат)**
**З 18**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре докторы **А.Х. Садыйкова**

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы **Ф.З. Яхин,**
филология фәннәре кандидаты **Л.Х. Дәүләтшина**

**Закирова И.Г.**
**З 18** **Әүвәл башлап ни бетте** / И.Г. Закирова. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 152 б.
ISBN 978-5-93091-229-6

Халык иҗаты әсәрләре катлаулы мәдәни һәм рухи кодлар рәвешендә халыкның киләчәк буыннарга җиткерелергә тиешле тәҗрибәсен саклый. Әлеге китапта авторның шул мәсьәләләр турында эзләнүләрен һәм уйлануларын яктырткан мәкаләләре тупланган.

Китап халкыбызның рухи дөньясы белән кызыксынучыларга адреслана.

**УДК 398.4**
**ББК 82.3(2Рос=Тат)**

**ISBN 978-5-93091-229-6**

© Закирова И.Г., 2017
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2017

## КЕРЕШ СҮЗ

Кешенең эчке дөньясын ачып биргән, аның әхлак нормаларын чагылдырган, мәдәни традицияләрен буыннан буынга тапшырырга ярдәм иткән, ата-бабаларның белемен-ышануларын, кешеләрнең үзара һәм табигатькә булган мөнәсәбәтләрен кануннар рәвешендә саклаган һәм нормага салырга ярдәм иткән фольклорны өйрәнү беркайчан да әһәмиятен югалтмый.

Фән яңа баскычларга күтәрелгән саен фольклор да яңа яктан ачыла бара. Беренче карашка гади, самими тоелган бу иҗатның үз эченә катлаулы фәннәрне дә сыйдыруын күрәбез. Тарих, этнография, тел, педагогика, әдәбият, экология, психология кебек фәннәрнең фольклор белән бәйләнеше бер кешедә дә шик уятмый.

Кешелек җәмгыяте формалашкан дәвердә синкретик сәнгатьнең бер өлеше буларак барлыкка килгән фольклор хәзерге вакытта жанрлар, сюжетлар ягыннан гына түгел, социумга мөнәсәбәте ягыннан да ачыла бара. Фольклорның төрле жанрлары бер буыннан икенчесенә мәдәни стереотиплар рәвешендә формалашкан иҗтимагый тәҗрибәне тапшыру чарасы булып саналалар, халыкның менталь үз-үзен тотышын формалаштыруда һәм билгеле бер кысаларда тотуда зур роль уйныйлар.

Фольклор һәм мифология кешенең һәм җәмгыятьнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен, аның дөньяны кабул итүен, традицион күзаллавын чагылдырган мәгълүмат саклыйлар. Халыкның дөньяны күзаллавы катлаулы күренеш, ул конкрет ситуациягә карата актуаль булган фрагментлардан торган система хасил итә. Бу системаны без дөнья моделе дип атыйбыз. Теләсә кайсы халыкның дөньяга карашын фәкать аның фольклорын һәм мифологиясен камил белгән рәвештә генә аңларга, өйрәнергә һәм мөмкин булган кадәр торгызырга яки реконструкцияләргә мөмкин. Дөнья картинасы беренче чиратта халыкның тел иҗатында – мифларда, мифологик хикәятләрдә, легендаларда, эпоста, әкиятләрдә һәм фольклорның башка жанрларында чагыла. Халыкның дөньяны күзаллавы турындагы мәгълүмат ритуалларда, йолаларда,

гореф-гадәтләрдә саклана. Дөньяны күзаллау белән бәйле карашлар, күренешләр, вакыттан тыш, үзгәрми торган кыйммәтләрдән санала. Бер барлыкка килгән карашлар гасырдан гасырга күчеп килеп, язылмаган кануннар буларак кабул ителгән. Бу күренеш халыкның билгеле бер тотрыклылыкны, аңында яки хыялында гына булса да яшәп килгән гармонияне бозудан куркуы белән бәйләп аңлатыла. Гармония – кешенең сау-сәләмәт булуы, гаилә әгъзаларының исәнлеге, табигатьнең мәрхәмәтле булуы. Ритуалга әйләнгән көндәлек агышны үзгәртү, тормышка яңалык кертү шушы гармонияне бозарга мөмкин. Ритуал аша җәмгыять табигать, параллель дөньялар, аларның ияләре белән мөнәсәбәт урнаштыра, контактка керә. Һәр ике якның бурычлары һәм вазифалары ачыклана. Һәрбер йола яки ритуал катлаулы яшәешнең, социаль тотрыклылыкның бер элементы. Һәм ритулларның төп әһәмияте шунда, алар аша кеше үзен шушы дөньяның аерылгысыз өлеше итеп кабул итә башлый.

Дөньяны танып белүнең нигезе күпчелек халыклар өчен уртак. Бу – гасырлар дәвамында формалашкан дөнья һәм кеше яратылу, күк, җир һәм җир асты дөньялары, бу дөньяларның хуҗалары, үз һәм ятлар дөньясы, аларның турындагы карашлар.

Татар халкының дөньяны танып белүе һәм дөнья моделе башка төрки халыкларныкы белән аваздаш. Алар күпчелек төрки халыкларның уртак кыйммәтләре булып торалар. Шуңа күрә аерым күренешләрне реконструкцияләү өчен башка халыкларның мифологиясенә һәм фольклорына да мөрәҗәгать итү урынлы.

Татар халкының традицион дөньяны күзаллавы гаять катлаулы күренеш. Әмма әлеге хезмәттә аны бөтен яктан тикшерү максат итеп куелмады. Җыентыкка халыкның рухи дөньясын, дөньяны күзаллавын чагылдырган аерым эпизодлар гына кертелде. Алар – дөнья яратылу, параллель дөньялар, беренче кешеләр барлыкка килү һәм төрки халыкларның килеп чыгуы, татар һәм башка төркиләрнең җан һәм язмыш турындагы карашлары, хәзергә кадәр иң популяр булып калган су һәм су ияләре культы, кайбер календарь йолалар һәм халыкның дәүләт һәм хөкемдар турындагы карашларын чагылдырган мәкаләләр.

## ӘҮВӘЛ БАШЛАП НИ БИТТИ?
(Космогоник мифлар һәм легендалар)

Халыкның галәм, җир яратылу, күк, күк җисемнәре барлыкка килү, дөнья, җир төзелеше турындагы карашлары космогоник легендаларда саклана. Әлеге легендалар бөтен дөнья халыклары өчен уртак, охшаш сюжетларга корылган әсәрләр. Кайсы гына космогоник эчтәлекле миф яки легендаларны алып карасак та, аларда дөнья яратылу процессы түбәндәге схеманың бер өлешен тәшкил итә: Хаос → күк һәм җир → кояш, ай, йолдызлар → вакыт → үсемлекләр → хайваннар → кеше → эш кораллары һәм башкалар[1].

Легендаларның беренче өлешендә иң башта нәрсә булганлыгы, ягъни хаос сурәтләнә. Беренчел хаос Шумер, Вавилон, Мисыр, Грек, Себер халыклары мифологиясендә бик ачык күренә. Хаос «бер нәрсә дә: күк тә, җир дә, көн дә, төн дә, яшәү дә, үлем дә ... юк иде» – дип сыйфатлана. Икенче өлештә яратылу процессы, нәрсәләрнеңдер бар кылынганы тасвирлана. Бу күренешкә мисаллар Тәуратта бар: «Һәм Алла әйтте: Яктылык бар булсын... Һәм Алла яктылыкны караңгылыктан аерды. Һәм Алла яктылыкны көн дип, караңгылыкны төн дип атады…: беренче көн. – Һәм Алла әйтте: су өстендә катылык бар булсын... Һәм Алла катылыкны бар кылды, һәм суны аерды... Һәм Алла катылыкны күк дип атады…: икенче көн». Бу процесс шул рәвешле җиде көн дәвам итә[2].

Татар халкының борынгы мәкальдә дә шушы ук процесс тасвирлана.

Әүвәл башлап ни бетте?
Ай бетте дә көн бетте.

---

[1] *Топоров В.Н.* Космогонические мифы // Мифы народов мира.. М., 1995. Т. 2; С. 7.

[2] Ветхий Завет. Быт.

Икенчеләй ни бетте?
Күк бетте дә җир бетте[1].

Бу мәкальдә дә башта ай белән кояш, соңрак күк белән җир яратылуы тасвирлана. Татар телендә дөньяның яратылу процессы хәзерге вакытта беренчел мәгънәсен югалткан «бетү» яки «битү» дигән архаик сүз белән бирелгән. Н. Исәнбәт «бетте» сүзенең бу очракта «яралды», «үсте» мәгънәсендә килүен әйтә[2]. В.В. Радлов тарафыннан Себер татарларыннан язып алынган борынгы әсәрдә дә дөнья яратылу процессы шушы ук юллар белән тасвирлана:

Әүвәл башлап ни битти?
Көн битти дә, ай битти.
Икенчеләй ни битти?
Тау битти дә, таш битти.
Уртасыда ни битти?
Ирмән юшыр ут битти.
Аны утларга ни битти?
Кыл койрыклы мал битти.
Аңа ия булсын, дип,
Туфрактан сурәт кылдырып,
Адәмгә баш бармакча тән битти,
Бер чебенча җан битте[3].

Әлеге әсәрдә дөнья яратылу процессы турындагы мифологик карашлар тулысынча сакланган. Башта кояш белән ай, тау-ташлар, үсемлекләр һәм хайваннар яратыла. Соңрак шушы дөньяга хуҗа яки ия булсын өчен туфрактан кеше яратыла.

Космогоник мифларда һәм легендаларда капма-каршы дуализм күренеше күзгә ташлана. Җирне яки кешеләрне бар кылуда капма-каршы ике көч катнаша. Беренчесе файдалы,

---

[1] *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Т. 1. Б. 419.

[2] *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Т. 1. Б. 409.

[3] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Ч. IV. СПб., 1872. С. 136–137.

кирәкле әйберләрне, кешеләрнең уңай сыйфатларын һәм үзләрен бар кылса, икенчесе, киресенчә, начар, файдасыз әйберләрне, кешеләрдәге явызлыкны, әшәкелекне, кара көчләрне бар кыла.

Җир яратылу турындагы легендаларның сюжеты күп халыклар өчен уртак. Беренче, иң күп таралган сюжет океан төбеннән ләм алып чыгучы кош турында. Күпчелек очракта аерма кошның нинди булуында һәм нинди максат белән чумуында гына. Евразия һәм Төньяк Америка халыклары өчен бу кош гагара, төрки халыкларда үрдәк яки үрдәккә охшаган башка су кошы, шулай ук ташбака, каз һәм башкалар булырга мөмкин. Кош дөнья суы төбенә чумып, үзенә оя ясар өчен, туфрак-ләм алып чыга. Кайбер халыкларның легендаларында Тәңре кушуы буенча яки Илаһи көчкә ял итәргә урын кирәк булганга су өстенә ләм алып чыгып, ул коры җир ясый. Нинди генә вариант булса да, җир шушы кош алып чыккан туфрактан яки ләмнән үсә, башлана.

Г. Дәүләтшин, Болгар территорияләрендә табылган археологик материалларга нигезләнеп, бу сюжетның Идел буе болгарларында да популяр булуын исбатлый[1]. Болгар халкы суга чумып ләм алып чыгучы кошны үрдәк итеп күз алдына китергән. Биләр шәһәре территориясендә алып барылган казу эшләре вакытында алтыннан коелган егермеләп кош сыны табылган. А.Х. Халиков бу табылдыклар турында: «Аларга бизәкләп эшләнгән йомырка сыман өч алтын төймә беркетелгән. Тагын шундый ук төймәләр алканың үзеннән дә нәфисрәк чылбырларга асылган. Кайбер очракларда кош алканың эченә коелган. Рәвешенә караганда, бу – үрдәк яки каз», дип яза[2]. Галим, археологик материалларны өйрәнеп, Болгарда ике мифологик ышануны берләштергән яңа сюжет тууын әйтә. Беренчесе буенча, кош океан төбенә чумып бер кабым ләм яки балчык алып чыга, шуннан коры җир барлыкка килә. Икенче

---

[1] *Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 201–202.

[2] *Халиков А.Х.* Беренче дәүләт: Болгар иле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. Б. 32.

миф Һинд-Иран халыклары арасында таралган. Аларда су кошы – якты дөнья яки җир өсте символы. Аның өч асылы – күктә оча, җирдә йөри, суда йөзә, гомумән, җирдәге дөньяны чагылдыра. Шуның өчен дә кошның өч атрибуты булырга тиеш. Беренчесе – күк гөмбәзе, икенчесе – җир катылыгы, өченчесе – су тирәнлеге[1].

Җир яратылу турындагы легенданың безнең көннәргә хәтле бик кыска бер варианты гына килеп җиткән. «Элек заманнарда дөнья тоташ судан гына торган. Кешеләр әле булмаган. Суда балыклар һәм су кошлары гына яшәгәннәр. Шунда бер үрдәк, су төбенә чумып, борыны белән бер кисәк балчык алып чыккан. Бу зурайган һәм шуннан җир хасил булган» (Риваятьләр, 1987, б. 232). Әсәр үзенең мифологик мәгънәсен югалткан, җир яратылу процессы очраклы вакыйга итеп тасвирлана. Алдарак чорларда язып алынган вариантларда дөнья яратылу процессы тулырак бәян ителә. Легенданың тулырак вариантын Енисей губернасында яшәүче Себер төркиләреннән Н.Ф. Катанов язып алган. Легенданың сюжеты берничә өлештән тора: җир яратылу, кешеләр, аларның уңай һәм тискәре сыйфатлары яратылу һәм башкалар. Җир яратылу процессы болай тасвирлана: «Иң элек үрдәк [Алла] бар иде. Икенче үрдәкне [шайтанны] иптәше итте һәм аны су төбеннән ком алып менәргә җибәрде. Үрдәк бер тапкыр чумып ком алып менеп бирде... Икенче тапкыр... Өченче тапкыр чумганнан соң алып менгән комын биреп бетермәде. Үрдәк [Алла] комны тугыз көн дәвамында төеп, җир итеп җәйде. Икенче үрдәкнең авызында калган ком үсә башлады. Ул аны да төкерде. Ком тауташларга әверелде. Җирдә олы-олы таулар хасил булды»[2].

Биләр территориясендә табылган алкалардагы үрдәк сынының да авызына алтын бөртекнең берсен кабып, ике бөртегенең канатына һәм койрыгына беркетелгән булуы шушы легендага туры килергә дә мөмкин. Ул бөртекләр үрдәкнең

[1] *Халиков А.Х.* Беренче дәүләт: Болгар иле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991, Б. 32–34.

[2] *Катанов Н.Ф.* Качинская история о сотворении мира // ИОАИЭ. 1894. Т. XII. Вып. 2. С. 185–188.

өч тапкыр чумып, өч кабым ком алып чыгуын күрсәтә ала. Г. Дәүләтшин бу сын турында «Бу – космогоник легенданың болгар бизәнү әйберләрендәге сынлы сәнгать сюжеты белән бәйләнүе, аның болгарларда да киң таралуы хакында сөйли. Күрәсең, алар фикеренчә, Җир, Кояш, Ай өч үрдәк йомыркасыннан (өч төймәдән) барлыкка килгән»[1].

Борынгы легендага, халык ислам дине кабул иткәннән соң яңа мотивлар өстәлә, әмма сюжет шул ук кала: «Аллаһы Тәгалә кодрәте белән бер күлне яратты. Ул күлгә үрдәкне җибәрде: «Күл төбендәге барлык комны йот!» – дип боерды. Үрдәк бөтен комны йотты. Аннан соң Аллаһы Тәгалә боерды: «Эчеңдәге барлык комны чыгар!» Үрдәк, үзенә азык булыр дип, комның бер өлешен эчендә калдырды. Эчендәге ком үсә башлады һәм аны да чыгарды»[2]. Н.Ф. Катанов вариантында үрдәк демиург итеп тасвирлана. Ул – Җирне бар кылучы илаһи көч. Ислам йогынтысында үрдәк, Аллаһы Тәгалә кушканны үтәүче ярдәмче көчкә әверелә, илаһилыгын югалта. Аккош, каз, үрдәк сурәтләрен болгарларның бик күп көнкүреш әйберләрендә очратарга була. Г.М. Дәүләтшин үрдәкнең бу сурәтләрдә һәм сыннарда Кояш, күк йөзе символы буларак сурәтләнүләрен яза[3].

Болгар халкы, башка күп халыклар кебек, дөнья өч өлештән тора дип, яки өч катлы дип ышанган: күк, җир өсте һәм җир асты дөньялары. Бу дөньяларның һәрберсенең үз тормышы, үз халкы булган. Аларның һәрберсендә үзенчәлекле тормыш-яшәеш барган. Җир өстендә кешеләр яшәгән, үлгән кеше җир астына яки үлеләр дөньясына эләккән. Җир астына кара көчләр хуҗа булган. Күктә Аллалар яки Илаһи көчләр, мифологик затлар яши дип уйлаганнар. Бу ышануларның эзләре легенда-риваятьләрдә, табышмакларда, мәкальләрдә һәм әкиятләрдә сакланган.

Борынгы мифология буенча, башта күк йөзе белән җир аерылмаган була. Аннары Күк Җирдән аерылып, өскә менеп

---

[1] *Дәүләтшин Г. М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Б. 201.

[2] *Давлетшин Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. С. 47.

[3] Шунда ук. С. 48.

китә. Аның сәбәпләре Күкнең үпкәләве, Күк белән Җирнең ачуланышуы булырга мөмкин. Безнең вакытка кадәр килеп җиткән легендаларның эчтәлекләре бик гади. Мәсәлән, Дагыстан халыклары фольклорында күкнең җирдән аерылуы түбәндәгечә сурәтләнә: «Бик борынгы заманнарда Күк йөзе Җиргә бик якын торган. Аны үрелеп кул белән тотарга мөмкин булган. Бер хатын ризык әзерләгәндә пычранган кулын күккә сөртеп чистарта. Күкнең бу эшкә бик ачуы килгән һәм ул җирдән аерылып югарыга менеп киткән»[1]. Легенданың варианты татар фольклорында да бар. Аерма Күкнең үпкәләү сәбәбендә генә. Башка легендаларда Күк, Җир белән ачуланышканнан соң, Җирне ташлап китә.

Кайбер вариантларда күкне демиург яки Алла күтәрә, һәм, яңадан төшмәсен өчен, күк белән җир арасына нәрсәдер куя. Мәсәлән, җирне Алтай халыкларында – кылыч, грек мифологиясендә Атлант күтәреп тора. Кайбер халыклар мифологиясе буенча күк белән җирне дөнья агачы аерып тора. Дөнья агачы үскән саен күк җирдән ерагая бара. Күкне «дөнья тавы» күтәреп торган вариантлар да бар. Дөнья тавын күк йөзе белән бер итеп күзаллау да очрый. Мәсәлән, грек мифологиясендәге Олимп тавы шундый күк терәгенә һәм аллалар дөньясына мисал булып тора. Барыбыз да «күк терәве», «дөнья терәге», «алтын багана» кебек фразеологизмнарны яхшы беләбез. Аларда әйтеп үтелгән мифларның эзе саклanган. Димәк, борынгылар, күкнең терәве бар, аны шул күтәреп тора, җиргә төшеп китәргә ирек бирми, дип уйлаганнар. Күк белән җирнең яңадан кушылуы дөнья бетүне аңлата. Г.М. Дәүләтшин бу турыда: «Табигать стихияләре, яки иҗтимагый афәтләр вакытында Күк белән Җир беренче халәтләренә якынаерга мөмкиннәр («Күк белән Җир тоташкан кебек булды»)», – дип яза[2].

Күк җисемнәре турындагы легендалар да күп халыкларда очрый. Күп кенә халыкларның фольклорында ай белән кояш

---

[1] *Халидова М.Р.* Мифологический и исторический эпос народов Дагестана. Махачкала: ДНЦ РАН, 1992. С. 273.

[2] *Давлетшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 200.

ир белән хатын яки игезәк бертуганнар итеп сурәтләнә. Татар халкында да мондый эчтәлекле әсәрләр саклана. Мәсәлән, шундый легендаларның берсендә бертуган кызларның күк җисемнәренә әверелүе бәян ителә. Бер кешенең ике кызы була. Кызлар үзара дус булмыйлар. Ай исемлесе бигрәк тә усал булып, гел Кояшны рәнҗетеп торган. Моңа борчылган әтиләре: «Мин сезне бер-берегезне күрми торган итәм. Ай кызым, син кара йөзле булып кал, ә син, Кояш кызым, ак йөзле бул, гел мине искә ал», – дигән. Шулай диюе булган, ике кызы да күккә очып киткән. Шушы мизгелдән соң ике туган бер-берсен күрми яшиләр. Кояш, Айны күрергә теләп калыкса, Ай җир астына төшеп китә, Ай Кояшны күрергә теләсә, Кояш офыкка китеп югала. Шул рәвешле көн белән төн алмашынып чыга башлаганнар һәм күк йөзендә Ай белән Кояш барлыкка килгән[1].

Татар телендәге «кояш бату» һәм «кояш калку/чыгу» дигән гыйбарәләр буенча борынгыларның кояшны су төбендә төн куна дип ышанулары аңлашыла. Татар халкының бу ышануы башка халыклар мифологиясе белән дә аваздаш. Мәсәлән, грек мифологиясендә үзенең көнлек юлын үткәч, кояш алласы – Гелиос океанның изге суына төшә. Океанда ул үзенең алтын көймәсенә утырып кире көнчыгышка, Кояш иленә йөзә. Анда аның гаҗәеп сарае урнашкан. Кояш алласы анда төне буе ял итә, иртәгесен яңадан балкып күтәрелер өчен көч җыя[2]. Борынгы халыклар кояшны алтын кош яки канатлы ат рәвешендә дә күзаллаганнар. Болгар чорына караган ювелир әйберләрдә дә, гомумән, археологик материалларда да канатлы кояш сурәте очрый.

Борынгы төркиләр бөтен тереклек өчен кояшның никадәр мөһим роль уйнавын яхшы аңлаганнар, кояшны илаһилаштырганнар, аңа табынганнар, корбан китергәннәр.

---

[1] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 63.

[2] *Кун Н.А.* Легенды и мифы древней Греции. Душамбе: Гл. науч. ред. тадж. сов. энциклопедии, 1988. С. 51.

Ул булса көн була,
Ул булмаса кем була?[1]

диелә борынгы табышмакта.

Татар телендә «кояш куян атланды», «кояш куянга атланган чак» дигән фразеологизмнар очрый. Г.М. Дәүләтшин: «Татар һәм чуашларның космогоник карашларында кояш төрле хайван образларында гәүдәләнә: кояш төшкә кадәр – үгездә, төш вакытында – атта, төштән соң куянда бара», – дип яза[2].

Борынгы төркиләр иртә белән беренче эш итеп Кояшны сәламләгәннәр. «Күзеңне ач та, көнне әйт», дигән мәкаль дә борынгыларның кояшны олылауларын күрсәтә[3].

Кояш, ай образлары белән бәйле ышануларның эзләре мәкаль һәм табышмакларда яхшы сакланган.

Албасты күкне басты, кояшны йотты,
Җир посты.
Авызын ачмый албастыны упты[4],

дигән борынгы табышмакта кояш тотылу белән бәйле ышану чагыла. Бу табышмакның җавабы: күкне болыт басу, кояшның болыт артында калуы, яңгыр яву. Һинд халыклары мифологиясендә сакланган сюжет белән чагыштыргач, табышмакның борынгырак эчтәлеге ачыла. Ул мифның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт: бервакыт асурлар белән аллалар бергәләшеп океан төбеннән амрита (үлемсезлек бирүче эчемлек) салынган савытны чыгаралар. Раху дигән аждаһа, Алла кыяфәтенә кереп, эчемлекне үзенә алырга тели. Кояш белән Ай Рахуны та-

---

[1] Татар халык иҗаты. Табышмаклар / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Хуҗиәхмәт Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 35.

[2] *Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 207.

[3] Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Хуҗиәхмәт Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 39.

[4] *Исәнбәт Н.* Татар халык табышмаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. Б. 475.

ныр алалар һәм аңа комачаулыйлар. Вишну Рахуның башын чаба. Эчемлекне кабып өлгергән Рахуның башы үлемсезлеккә ирешә. Үле гәүдәсе җиргә төшеп китә. Рахуның үлемсез башы шул вакыттан бирле күктә яши. Ул Кояш белән Айга чиксез нәфрәт саклап, аларны куып йөри. Кайвакыт, тоткан вакытларында, йотарга тели. Кояш һәм Ай тотылу шуннан килә[1]. Кояш һәм Ай тотылу белән бәйле легенда Сахалин утравында яшәүче нивх халкында да сакланган. Аның эчтәлеге болай: күктә бер эт яши. Кайвакыт ул Кояшны ашарга керешә. Бу вакытта Кояш «үлә». Кайвакыт ул Айны да ашый[2]. Алдарак искә алынган табышмак буенча фикер йөртсәк, моңа охшаган легенда болгарларда да булган дип уйлыйбыз. Кояшка яки Айга албасты һөҗүм итә. Кайвакыт ул Кояшны йотарга теләп, аны куып йөри. Әгәр куып җитсә, кояш тотылу күзәтелә.

Себер татарлары һәм Алтай төркиләре мифологиясендә Ай белән Кояшка һөҗүм итүче тагын бер образ – Җилбәгән (Елбегән) очрый[3]. Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендә: «Йети башлыг йелбүкә», – дигән гыйбарә бар[4]. Аның хәзерге татар телендә «җиде башлы аждаһа» дигән варианты да очрый[5]. Ай белән кояшка һөҗүм итүче мондый персонажлар төрки халыкларның күбесендә булган, алар турында татар халкында да легендалар булуы ихтимал. Татар телендәге «кояш тотылу», «ай тотылу» дигән гыйбарәләр менә шушы ышануларның эзен саклый булса кирәк.

Татарларда Айда яшәүче Зөһрә кыз турында да легенда сакланган. «Зөһрә бик матур, уңган-булган кыз була. Әмма

---

[1] Мифы древнего мира / сост. М.Б. Бурдыкина. СПб.: Каравелла, 1995. С. 108.

[2] *Крейнович Е.А.* Очерк космогонических представлений гиляк острова Сахалина // Этнография. 1929. № 1. С. 78.

[3] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Т. 1. Б. 98.

[4] *Кошгарий М.* Туркий сузлар девони (Девону луготит турк). Т. 3. Тошкент, 1963. III. С. 247.

[5] Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Б. 468.

үги әнисе аны бер дә яратмый. Бервакыт ул аңа төнлә белән иләкләп су ташырга куша. Кызны һәрвакыт күзәтеп торган Ай, аны кызганып, үзенә ала»[1]. Легенданың берничә варианты билгеле. Әсәрнең күп вариантлылыгы аның халыкта таралган булуын күрсәтә. Әсәрнең башка халыкларга да мәгълүм булган борынгырак версиясе Себер төркиләрендә сакланган. «Бик борынгы заманнарда, таш кешеләр яшәгәндә, Ай булмаган. Бервакыт бу таш кешеләр гадәти бер кызны тотып алып, коллары иткәннәр. Аны төннәрен уятып су ташытканнар. Кыз су ташыганда барлык моң-зарларын күккә сөйли торган була. Күк кызны, кызганып, үзенә алган һәм Айга әверелдергән. Ә Айдагы таплар булып кызның чиләк-көянтәсе күренә икән. Бу вариант нәкъ татар легендасын хәтерләтә: кызны Ай иясе үзенә ала[2]. Легенданың татар халкында сакланган тагын бер вариантында Айның Зөһрә кызны, кызганып, үзенә алуы һәм кызның Зөһрә йолдызга әверелүе сөйләнә.

Кызларның йолдызларга әверелеп күккә ашуы турындагы ышанулар шактый таралган. Мәсәлән түбәндәге табышмакта да шул ышану эзләре саклана:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык.

Н. Исәнбәт, бу табышмакта йолдызларга әверелгән унике кыз турындагы борынгы ышану чагылыш тапкан, дип яза[3]. Эчтәлеге белән Болгар чорын бәян иткән «Мәрҗән каласы һәм унике кыз хикәясе» дигән риваятьтә дә кызларның йолдызларга әверелеп күккә ашуы сурәтләнә.

---

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Сәлим Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 232–234.

[2] *Гурвич И.С.* Космогонические представления и пережитки тотемического культа у населения Оленекского района // СЭ. 1948. № 3. С. 148–151;

[3] *Исәнбәт Н.* Татар халык табышмаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. Б. 469.

«Борын заманда Мәрҗән шәһәрендә Тырышмал Хуҗа хөкем сөргән. Аның унике кызы булган. Бервакыт Болгар илен яу баскан. Унике кыз сугыш артында карап торганнар. Шуның белән баскынчыларның көчләрен какшатканнар. Моны күреп ачулары чыккан илбасарлар кызларны куа башлаганнар. Тырышмал Хуҗаны һәм аның унике кызын тотып алып, Хуҗалар тавы кырыена китергәннәр. Монда алар, дошман кушуы буенча, яланаяк килеш, көне-төне туфрак ташып, яңа бер тау өйгәннәр. Дошманнар, биек тау өелеп беткәч, аларны шул тау башына тереләй күмеп куярга теләгәннәр. Шулчак кызлар унике йолдыз булып күккә күтәрелгәннәр, ә аталары таудан сикереп, елга суына әверелеп, агып киткән»[1].

Кызларның яки гомумән кешеләрнең йолдыз булып күккә атылуы, йолдызга әверелү мотивы бик борынгы. Ул грек, Америка индеецлары һ.б.ның мифологиясендә дә очрый. Мәсәлән, грек мифологиясе буенча, Зевс титан Атлант белән Океанияда Плейонаның җиде кызын җиде йолдызга әйләндерә[2].

Татар халкының тагын бер борынгы мәкалендә дә йолдызларга әверелгән кызлар образы калкып чыга.

Җидегәндә җиде кыз,
Ай янында Зөһрә кыз,
Таң янында Чулпан кыз,
Унике йолдыз – унике кыз,
Тимерказык бер ялгыз[3].

Борынгы заманнарда кешеләр җир күкнең чагылышы дип уйлаганнар. Күктәге һәр йолдызга җирдә бер кеше туры килә, ягъни һәр кешенең күктә үз йолдызы бар дип ышанганнар. Бүгенге көнгә кадәр, «йолдыз атылганда берәү дөньяга килә,

---

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 37–38.

[2] Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. / гл. ред. С.А. Токарев. 2-е изд. М.: Сов. энцикл. Изд-во малого предп. «Останкино». Т. I., 1991. С. 117.

[3] *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Т. I. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Б. 419.

берәү китә», дигән ышану сакланган. Бу ышану күп халыкларда очрый, күпләрендә легендасы да сакланган. «Һәр кешенең үз йолдызы була. Берәүләрнең ул якты, икенчеләрнең тонык. Кешеләрнең язмышы шушы йолдызга бәйле. Әгәр йолдызы якты икән, кешенең тормышы да шундый: ул хөрмәткә ия, атаклы шәхес була. Күп яхшылык, изгелек кылып яши. Әгәр йолдызы тонык булса, ул тормышта да «күренмичә» генә яши. Йолдыз – ул кешенең җаны. Ул күктә атылганда, җирдәге кешесе дә үлә»[1]. Татар телендәге «йолдыз атылу», «йолдызы сүнү» дигән гыйбарәләр дә шушы ышану эзләрен саклый.

Татар халкында күкнең елга бер генә тапкыр ачыла торган капусы яки капкасы булу турындагы мифологик ышану да бар. Бу мифологик ышану телдәге гыйбарәләрдә, мәкальләрдә саклана: «күк капусы ачылганын күргән кеше бәхетле була», «күк кабагы ачылганда, ни әйтсәң, шул кабул була имеш»[2]. «Күк капусы», «күк кабагы ачылган көн» дигән гыйбарәләр бар. Күк капусы елга бер генә тапкыр ачыла икән. Аның ачылганын күрү бик сирәк кешегә генә насыйп була. Әгәр кеше бу вакыйганы күрсә, теләк теләргә тиеш. Аның бөтен теләкләре кабул була, хыяллары чынга аша имеш. Борынгылар күктә капка бар дип күзалдына китергәннәр. Ул капка артында Тәңре яши, капка ачык вакытта ул кешеләрнең нәрсә соравын ишетә дип уйлаганнар, күк капусы ачылганда теләнгән теләк тормышка аша дип ышанганнар. Ислам мифологиясе буенча күк капусы елга бер тапкыр – Коръән иңдерелгән Кадер кичәсендә генә ачыла. Күк капусы ачылган Кадер киче, бу төн белән бәйле гамәлләр Г. Тукайның «Кадер кич» шигырендә бәян ителә:

Бу кадер кич елда бер кич – барча кичләр изгесе;
Сафланыр таптан бу кич мөэмин күңелләр көзгесе.
Сафланыр ул, пакьләнер,– бик зур Ходайның дәүләте;
Һәм төшәр ул көзгеләргә күк капугы шәүләсе.

---

[1] *Халидова М.Р.* Мифологический и исторический эпос народов Дагестана. Махачкала: ДНЦ РАН, 1992. С. 91.

[2] *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Т. I. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. Б. 406.

Шул капугъдан күндерермез Тәңремезгә без теләк,–
Бер кадер кич Тәңре каршында мең айдан изгерәк.

Күк йөзе белән бәйле тагын бер легенданы Идел буе болгарларының тормышын тасвир иткән хезмәтендә Ибне Фазлан язып калдырган. Болгарлар яшен яшьнәп, күк күкрәп торган күк йөзен тугры һәм дошман җеннәрнең үзара бәрелеше итеп тасвирлыйлар[1]. Мондый карашлар кайбер борынгы табышмакларда да сакланган:

Югарыда яу купкан.
Угын атар, үзе качар[2].

Борынгылар дөньяны өчкә бүлеп караганнар, җир асты дөньясы булуга да ышанганнар. Бу ышану телдәге гыйбарәләрдә, әкият фрагментларында сакланган. Җир асты дөньясын үлеләр дөньясы итеп кабул иткәннәр. Шулай ук анда кара көчләр, тискәре мифик геройлар яши дип ышанганнар. Җир астын үлеләр дөньясы итеп күзаллау борынгы төрки кабиләләрнең күбесенә хас була. Монгол һәм Алтай төркиләре бу дөньяның хуҗасы яки алласы итеп Эрлик ханны саныйлар. Эрликнең исеме борынгы уйгурларның Эрклиг каган (могучий государь) сүзенә – буддизмдагы тәмуг хуҗасы Яманың эпитетына барып тоташа. Буддизм легендалары буенча, Эрлик гаҗәеп көчкә ия булган изге монах була. Гаепсезгә үтерелгәннән соң, ул куркыныч демонга әверелә. Аны җиңеп, җир астына төшерәләр һәм ул анда җир асты хуҗасына әверелә. Кайбер халыклар мифологиясе буенча Эрлик – кара көч, шайтан, демиург яки демиург яраткан беренче җан иясе. Алтай төркиләре легендалары буенча Эрлик төннәрен җир өстенә чыга һәм иң

---

[1] *Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков: Изд-во Харьковского университета, 1956. С. 134–135.

[2] Татар халык иҗаты. Табышмаклар / томны төзүче, искәрмәләрне әзерләүче һәм кереш мәкаләне язучы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 3.

чибәр хатын-кызларны, ирләрне үтерә, аларны, җир астына алып китеп, үзенә хезмәтче итә. Үлгәннәрнең җаннары аңа хезмәт итә. Кешеләргә авыру җибәрә. Аларның канын эчә. Эрлик кара үгезгә яки атка атланып йөри. Кайвакыт аның кара көймәдә йөзүен күреп була. Җир астында аның туксан тугыз (яки сиксән сигез) зинданы бар[1]. Моңа охшаш легенда борынгы болгарларга да таныш булган дип уйлыйбыз. Ул, ислам дине кабул ителеп, үлеләр дөньясы күккә күчерелгәч кенә әкренләп онытыла башлаган. Борынгы мифологик карашлар тулысынча онытылып бетми, алар, кагыйдә буларак, фольклорның төрле жанрларында фрагментлар, аерым мотивлар, һич югы, гыйбарәләр булып саклана. Космогоник эчтәлекле легендаларның эзләре, мифлар, әкият фрагментлары булып, күп сакланганнар. Әкиятләрдә җир астында дию патшалыгы урнашкан. Дию җир өстенә чыгып кешеләргә явызлык кылып йөри. Ул чибәр кызларны, гадәттә патша кызларын, урлап китә. Аның җир астындагы зинданнарында ул урлаган кешеләр җәфа чигә. Дию җир астыннан берәр кое яки тау тишеге аша чыгып-кереп йөри. Гадәттә патша кызын коткарырга баручы герой да шушы ук юлдан җир астына эләгә. Әкиятләрдәге шушы җир астындагы дию патшалыгы кайчандыр үлеләр дөньясы булган. Үлеләр дөньясына баруның икенче юлы да бар. Бу юл су аша салынган. Кайбер әкиятләрдә дию патшалыгы күл яки диңгез төбендә булырга яки елга, диңгез-дәрья аръягында урнашырга мөмкин. Бу диңгезне кичүче көймәче карт образы да әкиятләрдә сакланган. Мәсәлән, «Карунбай» әкиятендә мондый эпизод бар: «Көн бара, төн бара, бара торгач, барып җитә бу зур диңгезгә. Карый. Караса, бер бабай көймәдә кешеләрне күчереп йөри. Әйтә малай:

– Бабай, мин фәлән-фәлән җиргә барам, мине аръякка күчер әле, – ди. Бабай җавабында:

---

[1] Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. / гл. ред. С.А. Токарев. 2-е изд. М.: Сов. энцикл. Изд-во малого предп. «Останкино». Т. II, 1992. С. 668.

– Күчерүен күчерермен, улым, тик анда барганнардан берәү дә кире кайтмый бит, – ди»[1].

Җир астына төшкән геройга якты дөньяга чыгарга ике дөнья арасында арадашчы булган берәр хайван яки кош булыша. Мәсәлән, «Камыр батыр» әкиятендә шушы мотив сакланган:

«Бер зур агач күрерсең, шуның башында Сәмруг кош оя ясаган булыр. Һәр елны бер вакытта аждаһа елан килеп, аның балаларын ашап китә икән, әгәр син, барып җитеп, еланны үтереп, Сәмругның балаларын коткара алсаң, бәлки ул сине җир өстенә алып чыгып куяр»[2]. Әкият герое җир астына дию пәрие урлаган кызны коткарыр өчен төшә һәм аны кире җир өстенә чыгара. Әкиятләрдән дию патшалыгының үлеләр дөньясы булуы яхшы аңлашыла. Беренчедән, «анда барганнар кире кайтмый», икенчедән, герой «якты дөньяга» чыга. Дию патшалыгы борынгы грек легендаларындагы Аид патшалыгын хәтерләтә. Грек легендаларында да җир асты дөньясыннан кире кайтып булмый. Анда үлекләрнең җанын көймә белән Харон ташып тора. Аид та, дию урлаган кебек, җирдән кешеләрне алып китеп тора. Анда да үлеләрне коткарыр өчен Аид патшалыгына төшүче геройлар бар. Үзенең хатыны Эвридаканы коткарыр өчен Аид патшалыгына Орфей бара[3]. Җир астын, үлеләр дөньясын Одиссей төшеп күрә[4].

Югарыда әйткәннәрдән борынгыларның үлеләр дөньясын ничегрәк күзаллаулары күренә. Алар өчен җир асты – үз хуҗасы, үз халкы булган өченче дөнья – үлеләр дөньясы. Аның хуҗасы Дию кешеләрне бу дөньядан теге дөньяга урлап киткән. Ике дөнья арасында чик буларак дәрья урнашкан. Дәрьяда көймә белән үлеләрнең җаннарын ташып торучы карт бар.

---

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Икенче китап / томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 279.

[2] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Беренче китап. Казан, 1977. Б. 303.

[3] *Кун Н.А.* Легенды и мифы древней Греции. Душамбе: Гл. науч. ред. тадж. сов. энциклопедии, 1988. С. 189.

[4] Шунда ук. С. 380.

Әмма ул бер кешене дә кире якты дөньяга чыгармый. Ул дөньяга үтеп керә торган юллар булса да, гади кеше аны үтә алмый, Җир тишеге аша гына үтеп була. Теге дөньядан бу дөньяга Сәмруг кош (яки Каракош) кына чыгара ала. Сәмруг кошның оясы дөнья агачына урнашкан. Бу турыдагы легенданың фрагментын Болгарга сәяхәт иткән гарәп сәяхәтчесе әл-Гарнати яза: «Йура халкы утлар белән яктыртып караңгылык дөньясына кереп йөри. Анда гаять олы агач үсә. Ә ул агачта бик зур җан иясе яши. Аны кош дип сөйлиләр»[1].

Мифология буенча, тормыш агачы өч дөньяны да тоташтырып тора. Агачның башы күккә тия һәм күпчелек очракта күкне күтәреп тора. Ә тамырлары җир асты дөньясына урнашкан һәм дөньяны шул агач тотып тора. «Тормыш агачы» болгар сынлы сәнгатендә еш очраучы образ. Һуннар һәм суварлар өчен Тормыш агачы күктә яшәүче Тәңре белән бәйләүче чара булган. Тәңрегә корбанны да шушы агач аша биргәннәр[2]. Татар халык дастаннарында тормыш агачы образы бай-каен яки бай-тирәк булып кергән. Эпос герое тормышының мөһим этапларында шушы агач янына барып чыга. Тормыш агачының ябалдашында кошлар яши. Татар фольклорында ул мифик сәмруг кош яки каракош. Бу кошларны кайвакыт кояш образы белән дә бәйләп карыйлар. Агач башындагы ике кош ай белән кояшны аңлата[3].

Борынгыларның дөньяны өч өлешкә бүлүләрен күрдек. Әмма бу караш ислам дине кабул иткәннән соң үзгәрә. Алар күк йөзен һәм җир өстен генә таный башлыйлар. Җир асты дөньясы әкиятләрдә генә сакланып кала. Космогоник карашларда Коръән тәэсирендә үзгәрешләр барлыкка килә. Җир һәм күк

---

[1] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / О.Г. Большаков, А.Л. Монгайт. М.: Главная редакция восточной литературы издательства «Наука», 1971. С. 32.

[2] *Давлетшин Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. С. 54.

[3] Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. / гл. ред. С.А. Токарев. 2-е изд. М.: Сов. энцикл. Изд-во малого предп. «Останкино». Т. II, 1992. С. 346.

җисемнәрен, барча тереклекне Аллаһы Тәгалә бар кыла. «Җир һәм күкләр бергә кушылган иделәр. Без аларны аердык вә һәр терек мәхлукны судан халык кылдык». «Без күкне түшәдек мәхкәм сакланмыш түбә итеп». «Ул – Аллаһ, кичне вә көндезне һәм кояшны вә айны яратып, кояш, ай вә йолдызлар һава бушлыгында йөзеп йөриләр»[1]. Аллаһы Тәгалә җирне ике көндә төзи. Тагын ике көндә җиде кат күкне төзеп бетерә. Күкне йолдызлар белән зиннәтли. Әгәр фәрештәләрнең сүзләрен шайтаннар урлап тыңларга телиләр икән, аларны атылучы йолдызлар саклый. Аллаһы Тәгалә күкне җиде кат итеп ярата. Җиденче катта Аллаһы Тәгаләнең тәхете урнашкан. Шулай ук, җәннәт җиденче кат күктә урнашкан санала. Ә җәһәннәм яки тәмуг беренче кат күктән түбәнрәк урнашкан. Күктә яхшылык һәм нурдан яратылган фәрештәләр яши[2].

Традицион концепция буенча, җирне Каф тавы уратып алган. Ә җир үзе, бер версия буенча, фәрештәләрнең иңбашына урнашкан. Икенче версия буенча, җир – үгез мөгезендә, үгез – балык өстендә, балык – суда, су һавада эленеп тора[3]. Бу ышану белән Рәшид-әд-дин хезмәтендә дә очрашабыз. Ул: «Айдан балыкка кадәр, күктән җиргә кадәр»[4], – дип яза. «Айдан балыкка кадәр» дигән гыйбарә «бөтен дөньяда» дигәнне аңлаткан.

Космогоник легендаларны өйрәнгәндә, аларның барлык халыклар өчен дә уртак сюжетка корылуын күрәбез. Аларда җир яратылу, Җир белән күкнең аерылуы, күк йөзе, җир өсте һәм җир асты дөньялары турында сөйләнелә. Легендаларның дөнья халыкларының күпчелеге өчен уртак сюжетка корылган булуы аларның бик борынгы чорга карауларын исбатлый. Әсәрләргә һәр чор үзенең үзгәрешләрен дә керткән. Мәсәлән,

---

[1] Коръән, 21:30, 32, 33.

[2] Коръән, 41:9,12; 67:3; 71:14 һ.б.

[3] Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. / гл. ред. С.А. Токарев. 2-е изд. М.: Сов. энцикл. Изд-во малого предп. «Останкино». Т. II, 1992. С. 84.

[4] *Рашид-ад-дин.* Сборник летописей. Т. I. Книга первая. М.-Л: Изд-во АН СССР, 1952. С. 57.

ислам дине йогынтысында үзгәрешләр барлыкка килгән, әсәрләр яңа яңгыраш алган.

Борынгы риваять-легендаларның күбесе мифологик караш-ышануларга нигезләнгән. Хәтта тарихи чынбарлыкка корылган риваятьләргә дә мифологик фантазия килеп керә. Белгечләр риваять-легендаларның халык хәтерендә 200–500 ел чамасы саклануын әйтәләр. Риваять-легендалар, язмача теркәлмәгән очракта, әкренләп онытылганнар. Бу хезмәттә образлары яки сюжет фрагментлары башка чыганаклар ярдәмендә табылган очракта, татар халкында булган дип фараз кылынган легендаларның сюжет линиясе реконструкцияләнеп бирелә.

## ҮЗЕНӘ ИТАГАТЬ ӨЧЕН ТӨЗДЕ ХАЛКЫН...

(Татар халкының генеалогик легендалары)

Үзен аңлый башлаган һәр кеше, һәрбер халык кешелекнең, аерым халыкларның барлыкка килүе белән кызыксынмый калмый. Кешелекнең барлыкка килүе, халык һәм нәсел тарихлары белән кызыксыну, шәҗәрәләрен барлау төрки халыкларга да күптәннән хас була. Легендалар, мифлар, телдәге гыйбарәләр, тарихи чыганакларда теркәлеп калган мәгълүматлар татар халкының иң беренче кешеләр һәм аерым бер халык яки нәсел барлыкка килү, төркиләрнең килеп чыгышы турындагы карашларын, ышануларын саклый.

Борынгы ышануларда кешелекнең барлыкка килүе хайваннар белән бәйләнгән. Күпчелек халыклар үзләренең нәсел башында аерым бер хайван торуына ышанганнар. Мәсәлән, Тибет халкы үзләрен маймылдан килеп чыккан дип уйлый, монгол халкы – соры бүре белән боланны, төркиләр бүрене үзләренең тотемы, ягъни нәсел башында торган хайван буларак олылыйлар.

Бүре – дөнья мифологиясендә аерым урын алып торган хайваннарның берсе. Ул – дөньяның күпчелек халыклары мифологиясендә яши, кайбер очракларда шактый каршылыклы образ. Еш кына бүре хәрби дружина юлбашчысы яки кабилә башлыгы ролендә тасвирланган. Бүрене олылау бик борынгы заманнардан ук килә. VI гасырга караган Кытай елъязмаларында бүренең төркиләр дөньясында зур роль уйнавы әйтелә. Л.Н. Гумилёв Кытай хроникаларында теркәлгән мәгълүматлар буенча, «Төрки хан» һәм «бүре» сүзләренең синонимнар булуын яза[1]. Борынгы төркиләрнең ханы Шаболио «Хан үзенең сыйфатлары белән бүре» дип

---

[1] *Гумилёв Л.Н.* Древние тюрки. М.: Товарищество «Клышников-Комаров и К», 1993. С. 23.

сурәтләнә[1]. Төркиләрнең байракларына алтын бүре башы сурәте ясалган була[2].

Кытай елъязмаларында төркиләрнең килеп чыгышын бүре белән бәйләгән ике легенда теркәлгән. Аларның беренчесендә уйгур халкының бүре белән кеше никахыннан килеп чыгуы бәян ителә. Шаньюйның, ягъни һун ханының тиңсез матурлыкка ия ике кызы туып үсә. Кешеләр, аларның матурлыгын күреп, кызларны Алиһәләргә тиңлиләр. Шаньюй да кызларына гади җир кешеләрен тиң күрергә теләми : «Бу кызларны кияүгә кешеләргә бирергә мөмкин түгел; Мин аларны Күккә бирәм», – дип, башкаладан төньякка китеп, шунда кешеләр яшәми торган җирдә сарай салдыра, кызларын шунда урнаштыра. Кызларын үзенә алуын сорап Күккә ялвара башлый. Күпмедер вакыт үткәннән соң бер бүре ияләшә, ул көне-төне сарайны саклый башлый. Кече кыз, язмышым шушыдыр, дип, шул бүре янына чыга, бүренең хатыны булып ир бала таба[3].

Икенче легендада да төрки халыкларның килеп чыгуы бүре һәм кеше никахы белән бәйләп аңлатыла. Һун йортының бер тармагы булган Ашина кабиләсе Көнбатыш диңгезеннән көнбатышта яши. Л.Н. Гумилев бу территориядә Атилла җирләре булуын яза[4]. Күрше халыклар һөҗүм итеп аларны тулысынча тар-мар итә. Бары ун яшьлек бердәнбер ир бала гына исән кала. Сугышчылар баланың аяк-кулларын чабып, сазлыкка ташлап китәләр. Һәркөн аның янына бер ана бүре килеп йөри башлый, гарип егеткә ашарга китерә. Дошманнары, баланың исән калуын белеп, аны үтерер өчен яңадан кешеләр җибәрә. Алар эзләп килеп егетне үтерәләр, бүре исә качып өлгерә. Ул Көнбатыш диңгезеннән көнчыгышка таба китә. Анда таулар арасына качып ун ир бала тудыра[5]. Бу легендадан

[1] *Бичурин Н.Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.; – Л.: Изд-во Акад. наук СССР, 1950. I. С. 237.

[2] *Бичурин Н.Я.* Собрание сведений. С. 229.

[3] Шунда ук. С. 214.

[4] *Гумилёв Л.Н.* Древние тюрки. М.: Товарищество «Клышников-Комаров и Ко, 1993. С. 23.

[5] *Бичурин Н.Я.* Собрание сведений.... С. 220–221.

күренгәнчә, Алтай төркиләре үзләренең тарихын Көнбатыш һуннар белән бәйлиләр, әмма үзләрен турыдан-туры аларның гына оныклары итеп санамыйлар. Бер яктан нәсел башы итеп һуннар, икенче яктан бүре санала. Тарихка күз салсак, Көнбатыш һуннарның 468 елда юк ителүләрен күрәбез, төркиләр мөстәкыйль халык булып 545 елда аякка баса[1].

Легенданың ана бүре образы белән бәйле тагын бер варианты бар. Анда төркиләрнең башында Со кабиләсе һәм ана бүре торганы турында сөйләнә[2].

Идел буе Болгар территориясенә караган шәһәр урынnaрында фәнни әдәбиятта «гарипләр» яки «ярымтыклар» дип атап йөртелгән бронза сыннар күп табылган. Алар – бүре яки барска охшаган хайванга атланган гарип ир кеше яки хатын-кыз сыннары. А.Х. Халиков бу сыннар турында: «Беренче булып 1966 елда мөгезле барс кыяфәтендәге йозак өстенә утырган хатын-кыз сыны табылган. Ул бронзадан коелган. Аның төп өлеше сул кулы белән күкрәгенә баласын кыскан куыш хатын-кыз фигурасыннан гыйбарәт. Уң кулы җилкә буынының уртасыннан юк. Уң аяк та шулай. 1984 елда шунда ук икенче сын да табыла. Монда җайдак – ир кеше. Аның да уң ягында гарипләндерелгән урыннар күренә»[3], – дип яза. Әлеге статуэткалар борынгы төркиләрнең килеп чыгулары турындагы алдарак искә алынган легендаларга нигезләнеп ясалган булырга мөмкин. Бу сыннарда мәчесыманнар (мәсәлән, барс) ясалган, бүрене барс алмаштырган. А.Х. Халиков: «Мәчесыманнар нәселеннән булган ерткыч барс Урта Азиянең көнчыгышында, Көньяк Себер һәм Алтайда таралган. Ихтимал, ул Идел буе һәм Төньяк Кавказдагы җитәкче болгар кабиләсе – барсилларның тотемы булгандыр. Билгеле булганча, барсиллар яки көмеш болгарлар Идел Болгарстаны халкының әйдәп баручы төркеме

---

[1] *Гумилёв Л.Н.* Древние тюрки. С. 23.

[2] *Аристов Н.А.* Заметки об этническом составе тюркских племен и народностей и сведения об их численности. СПб.: тип. С.Н. Худекова, 1897. С. 5.

[3] *Халиков А.Х.* Беренче дәүләт: Болгар иле. Казан : Татар. кит. нәшр., 1991 Б. 37–39.

булганнар. Күренекле татар тарихчысы Ш. Мәрҗани фикеренчә, барс болгар патшаларының уран билгесе булган. Барстагы мөгез дә мәртәбә билгесе»[1], – дип яза.

Төрки халыкларның үз тотемнары итеп бүрене сайлауларының бер сәбәбе бу хайваннарның һәрвакыт үз ирекләрен сакларга омтылуы белән аңлатыладыр. Алдарак әйтелгәнчә, төркиләрнең байрагына алтын бүре башы ясалган була. Бүре ул заманнарда да батырлык, ныклык, тугрылык, ә бүре өере – бердәм, дус хәрби дружина символы булган. Бүре өеренең бердәмлегенә соклану, алардан үрнәк алырга теләү бик борынгы заманнардан килә. Бүре күп халыкларның мифологиясендә очрый һәм ул, һәрвакыт диярлек, уңай образ.

Мифологиядә бүре образы белән бәйле тагын бер сюжет бар. Бүре нәсел башы, юлбашчы булачак баланы яки игезәкләрне тәрбияли. Рим шәһәренә нигез салган Ромулны һәм аның игезәк сыңары Ремны да бүре тәрбияләп үстерә[2].

Татар халкында бүре образы белән бәйле мифологик ышануларны саклаган әсәрләр бар. Бер легендада ак бүре турында сөйләнә. Кайчандыр татар халкы тау-урман аралап күчкәндә адашып, дошманнар камап алгач, ниндидер ак бүре аларны үз яклавына алып, яшерен юллардан ияртеп алып чыгып коткара. Н. Исәнбәт: «Шул легенда нигезендә, ак бүре әкият һәм легендалар, эпослар иясе, бер миф булып киткән»[3], – дип яза.

Ф.И. Урманчеев язганча, татар халкының төп яшәү урыны булган Идел буенда бөтен бер кабилә адашып калырлык таулар юк. Кеше үтмәслек таулар Бөек Болгар дәүләте территориясендә дә булмаган. Риваятьтә Алтай таулары турында гына сүз булырга мөмкин. Тарихтан билгеле булганча, ул җирләрдә төрки кабиләләр V гасырдан бирле яшәгән. Бу

---

[1] *Халиков А.Х.* Беренче дәүләт. Б. 40.

[2] Мифы древнего мира./ сост. М.Б. Бурдыкина. СПб.: Каравелла, 1995. С. 268–270.

[3] *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Т. III. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. Б. 565.

легендада шул чор вакыйгаларының эзләре сакланган булса кирәк[1].

Риваятьтә бүренең ак төстә булуына басым ясала. Мифологиядә ак төс бәхет-шатлык, уңыш символы, илаһилык яки башкалардан өстенлек, затлылык билгесе. Төрле халыкларның фольклорында һәм ышануларында ак төстәге хайваннар хуҗа яки патша буларак тасвирланалар. *Ак* сүзе белән әйбернең төсе генә белдерелми. Татар телендә дә «ак әби», «ак бабай» дигән гыйбарәләр бар. Алар да саф күңелле, мәрхәмәтле, яхшы кешеләргә карата кулланыла торган сүзләр. Бу сүз саф, чиста мәгънәсендә дә кулланыла. Мәсәлән, татарлар «ак бәхет» телиләр, «ак күңел» дигән гыйбарә бар.

Галимнәр «башкорт» этнонимының да бүре сүзеннән, «баш бүре»дән килеп чыккан дигән фикер әйтәләр. Бу турыда риваять-легендалар да шактый. Мәсәлән, «Башкорт каян килеп чыккан» дигән легендада бүренең дүрт бертуганга юл күрсәтүе турында сүз бара. Бүре аларны Көнчыгышка ияртеп килә. Легенда башкорт этнонимының бүре сүзеннән килеп чыгуын аңлата: «Бу җиргә аларны корт (бүре) баш булып, ияртеп алып килгәнлектән, шушы җиде ыруны «башкорт» дип әйтер булганнар» [2]. Башкорт халкының «Бүреләр токымы» дигән легендасында да аучы белән бүре никахы турында сүз бара: «Ата-бабайлар күчеп-кунып йөргәндә, аларга бер ана бүре очраган. Бер аучы моны атыйм дисә, бүре телгә килеп әйткән: «Атма мине, койрыгымнан тотып җиргә сук». Сукса, теге бик матур кыз булган. Аучы аны алып кайткан да тора башлаган. Балалары булып, зур бер ил төзеп җибәргән. Аналары бүредән булгач, аларны да «бүреләр» дип йөткәннәр. Ыругны башлап җибәргән әлеге аучыны Баш Бүре дип атаганнар. Менә без шул Баш Корт токымыннан киләбез инде[3].

---

[1] *Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. С. 9.

[2] Башҡорт халыҡ ижады. Риүәйәттәр һәм легендалар / төҙөүсе, инеш мәҡәлә яҙыусы, аңлатмалар биреүсе Ф.А. Нәҙершина; яуаплы редакторы Кирәй Мәргән. Өфө, 1980. Б. 29.

[3] Шунда ук. Б. 29.

Бүре турында легендалар Европа халыкларында да бар. Мәсәлән, Скандинавия халыклары мифологиясендә бүреләрне аллаларның этләре, ягъни сакчылары итеп тә тасвирлыйлар. Мәсәлән, О́динның[1] (яки Во́тан) юлдашлары ике бүре – Гери һәм Фреки, ул аларны үз өстәленнән ашата, бүреләр Одинның этләре вазифасын үтиләр[2]. Римда бүре бу шәһәрнең яклаучы алласы Марсның изге хайваны санала[3]. Якутлар бүрене борынгы тәңреләре – Улуу-Тойонның улы дип олылаганнар[4]. Бүре образы төрки халыклар мифологиясендәге һәм фольклор әсәрләрендәге сыйфатларын саклап «Слово о полку Игореве» әсәренә дә кергән. Әсәрдәге «босый волк» гыйбарәсенең төрки телләрдәге «бүз бүре»дән алынганы галимнәр тарафыннан исбатланган. В.А. Гордлевский: «Бүз бүре яки босый волк» «Слово о полку Игореве» әсәренә килеп кергәч, метаморфоза кичерә. Бүре һәрчак тугры юлны күрсәтүче юлбашчы образы булып кала, әмма ул рус кенәзенә хезмәт итә»[5], – дип яза. Бүре әсәрдә җитезлек символы. Аны җитезлек символы буларак тасвирлау күп халыкларга, шул исәптән төркиләргә һәм монголларга да хас күренеш. Эпос геройлары ерак араны тиз вакыт эчендә узу өчен бүрегә әвереләләр. Мәсәлән, бурят эпосында бу күренеш түбәндәгечә тасвирлана:

И в волка синего тогда
Она мгновенно превратившись,

---

[1] Один – Скандинавия мифологиясенең иң өлкән алласы.

[2] Беовульф. Старшая Эдда. Песнь о нибелунгах (Сер. Библиотека всемирной литературы). М.: Художественная литература, 1975.

[3] *Иванов В.В.* Реконструкция индоевропейских слов и текстов, отражающих культ волка. Известия АН СССР: Серия литературы и языка, 1975. Т. 34. № 5. С. 408.

[4] *Негматов Н.Н., Соколовский В.М.* Капитолийская волчица в Таджикстане и легенды Евразии // Памятники культуры: новые открытия. Ежегодник,1974. М.: 1975. С. 449.

[5] *Гордлевский В.А.* Что такое «босый волк». Избр. соч., т. 2. М., 1961. С. 332.

Скакала быстро ясным днем
И прыгала туманной ночью[1].

Татар фольклорында да бүренең кешегә һәм, киресенчә, кешенең бүрегә әверелүе турындагы сюжетлар да бар. Мәсәлән, «Ак бүре» дигән тылсымлы әкиятнең героена ярдәмгә килгән мифологик персонаж Ак бүре яшь егет кыяфәтенә дә, бүре кыяфәтенә дә, Сәмруг кош кыяфәтенә дә керә ала[2]. Төрки халыклар фольклорында бүренең эпос героена ярдәмгә килүе тасвирлана. «Ак бүре» әкиятендәге күренешләр дә шуның варианты булып тора. Хакас эпосы «Сарыг чанывар»да («Сары бүре») геройларга дошманнарын җиңәргә күк бүресе – сары бүре ярдәм итә[3].

Димәк, бүрене олылау бик борынгы заманнарга карый. Төрки халыкларның үзләренең килеп чыгышын бүре белән бәйләп аңлатулары очраклы күренеш түгел. Беренчедән, бүре ярым илаһи хайван саналса, икенчедән аның акыллы булуы, иреген сакларга омтылуы, коллыкка түзмәве, һәм шул ук вакытта усал булуы ихтирам уяткан. Бу әсәрләр халык хәтерендә гасырлар буе сакланган. Дошманнар һөҗүм иткәндә илне сакларга, яу чыгарга кирәк булган вакытларда алар бигрәк тә актуаль яңгыраган булса кирәк. Бүрене үзләренең яклаучылары, киңәшчеләре итеп сурәтләп яңа әсәрләр иҗат ителгән.

Бүренең тотем сыйфатлары – яклаучы, саклаучы һәм ярдәмче булуы халык медицинасында, бала багу фольклорында саклана. Бүре образына им-том, бала багу поэзиясендә мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, бүре теше кешеләрне, бигрәк тә балаларны зәхмәттән саклый торган әйбер санала[4]. Яңа туган

---

[1] Аламжи Мерген: бурятский эпос / под общ. ред Ю.М. Соколова; стихотворный пер. И.А. Новикова; вводн. статья и коммент. Г.Д. Санжеева. М-Л.: Полиграфкнига, 1936. С. 145.

[2] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Беренче китап. Казан, 1977. Б. 187.

[3] Сибирские сказания / переводы и переложения А.В. Преловского. М.: Современник, 1991. С. 37–124.

[4] Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 316.

баланы юындырганда аңа бүреләрдәге җитезлек, көч, сәламәтлек күчүен теләп, баланы бүре баласы дип атыйлар.

Соңрак чорларда бүрене тотем итеп хөрмәтләү туктый, аның уңай сыйфатлары онытыла. Халык иҗаты әсәрләрендә ул аңгыра, комсыз итеп сурәтләнә башлый. Шулай да кайбер әсәрләрдә бүренең үз иреген сакларга омтылуы, бәйсез булуы саклана. Мәсәлән, үзгәртүләргә аз бирешә торган, борынгылыгын саклаган татар халык мәкальләрендә бүренең көчле, бәйсез зат булуы турында сүз бара. Н. Исәнбәт мәкальләрдәге бүре образының шул сыйфатларына игътибар итеп: «Үз иркен саклавы, кешегә кол булмавы белән, эткә караганда затлылык сурәтләмәсе булып йөри», – дип яза[1].

Төрки халыкларның килеп чыгышын дөньяны туфан суы басу һәм Нух пәйгамбәр нәселе белән бәйли торган легенда бик борынгы заманнардан килә һәм ул төрле вариантларда дөньяның барлык халыкларына да билгеле. Туфан турындагы сюжет безнең эрага кадәр XII гасырда Борынгы Шумерда иҗат ителгән «Гильгамеш турындагы эпос»та урын алган, соңрак Тәүрат белән Коръәндә теркәлгән. Әлеге сюжетта әхлакый яктан бозылып беткән кешелекнең Алла тарафыннан туфан суы белән юк ителүе турында сүз бара. Бу сюжет төрки халыкларда да күп төрле вариантларда билгеле булган. Ул М. Кашгарыйның XI йөз язма истәлеге булган «Диване лөгатеттөрк» хезмәтендә дә теркәлгән. Диванда төрки халыкларның килеп чыгуы турында: «Төркиләр асылда егерме кабиләдер. Алар һәммәсе Нух пәйгамбәрнең улы Яфәскә, Яфәснең улы Төреккә барып тоташалар» [2], – дип язылган. Туфан суы һәм Нух пәйгамбәр турындагы легенда татар халкында һәрвакыт популяр була һәм халык телендә соңгы вакытларга кадәр саклана. «Туфан суы» дигән гыйбарә булып телгә дә керә. Легенданың бер вариантын 1920 елда археограф С. Вахидов Спасс кантонында (хәзерге Спас, Алексеев, Әлки районнары)

---

[1] *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. Т. 3; Б. 565.

[2] *Кошгарий М.* Туркий сузлар девони: (Девону луготит турк) Т. 3. Тошкент, 1960. I. С. 64.

язып ала. «Нух пәйгамбәрнең өч улы булган. Бер улы Яфәс атлы икән. Яфәснең Газый, Төрек, Алып исемле уллары була. Алып таңкалдыргыч батырлыкка ия. Ул, чынлап тотынса, кечерәк тауларны да аудара икән, сыңар кулы белән ат-сыерларны да күтәрә ала икән... Алып бер көнне ауга чыккач, адашып, абыйсы Төрек янына кайта алмаган. Урман эчендә йөри торгач, бер су янына килеп чыккан. Ул су буенда аның белән бер телдә сөйләшә торган, ләкин Алыпка ят булган кешеләр тора икән. Алып шунда яшәп калган, өйләнгән. Аның ике ир баласы туган. Балаларга Болгар һәм Бортас дип исем биргәннәр. Бу балалар үсеп җиткәч, икесе ике урында кала корып яши башлаганнар. Бу ике калада яшәгән кешеләрнең балалары күбәеп, күп еллар үткәч, бер токымнан ике төрле халык: болгарлар һәм бортаслар барлыкка килгән[1]. М. Кашгари сүзлегендә бирелгән риваятьтә бөтен төркиләр Төректән килеп чыккан булып саналса, С. Вахидов язып алган вариантта болгарлар килеп чыгышларын Алып исеме белән бәйлиләр.

Коръән һәм Тәүрат буенча, Нух/Ной – Туфан суы басканда исән калган пәйгамбәр. Ислам мифологиясе буенча, Нух Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләрне иманга китерергә җибәрелә. Әмма бик азлар гына аны тыңлыйлар. Аллаһы Тәгалә Нух пәйгамбәргә көймә ясарга боера: «И Нух, һәр хайваннан берәр пар ал, вә иман китергән кешеләрне, вә өй җәмәгатеңне көймәгә алып кер, мәгәр алар хакында Аллаһудан «алар кяферлек кылдылар» дигән сүз булган бер хатының илә бер угълың көймәгә кермәсләр»[2]. Аз сандагы иман китергән кешеләр генә көймәдә котылып кала һәм шул кешеләр җирдәге яңа тормышка нигез сала. Коръәннән соңгы әдәбиятта Нух пәйгамбәргә багышланган әсәрләр шактый языла. Алар барысы да мифологиягә таянып иҗат ителгән әсәрләр.

Ислам динендәге Нух образы христиан динендә һәм иудаизмда Ной буларак билгеле. Коръәндәге Нух пәйгамбәрдән

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. Б. 20–21.

[2] Коръән, 11:40.

аермалы буларак, Ной көймәсенә иман китерүче халыкны түгел, үзенең хатынын һәм хатыннары белән өч улын ала. Нойның уллары Сим, Хам һәм Йафет Туфаннан соң туган кешеләрнең нәсел башы булалар[1]. Шунысы да игътибарга лаек, төрки халыкларның легендаларында, шәҗәрәләрендә һәрвакыт Нух пәйгамбәрнең улларының (кайбер вариантларда кызларының) исеме күрсәтелә. Коръәннең нәкъ Туфан суы белән бәйле аятьләрендә Нух пәйгамбәрнең улларының исеме аталмый.

Төрле халыкларның Туфан суы турындагы легендаларында геройларның исеме төрлечә бирелә. Сюжет бик борынгы заманнар мифологиясеннән килә. Мәсәлән, Шумер мифологиясендә Зиусудра кешеләрнең яклаучысы булган Энки дигән алладан булачак туфан яңгыры турында хәбәр ала. Герой алла киңәше белән көймә ясый һәм җиде тәүлек буе дәвам иткән яңгырда хатыны белән исән кала. Бу сюжет алга таба Аккид (Вавилон) мифологиясендә үстерелә. Атрахасис Эйи (Энки) киңәше белән төзегән көймәсенә гаиләсен, һөнәрчеләрне, «икмәк һәм үлән ашаучы» барлык хайваннарны ала[2]. Сюжет грек мифологиясендә Зевс исеме белән бәйле легендада яңгыраш тапкан. Зевс, бөтен кешелек дөньясын юк итәргә теләп, җиргә яңгыр җибәрә. Бары этисе Прометей киңәшен тотып, көймә (тартма) ясаган Девкалион белән аның хатыны Пирра гына исән калалар. Яңгыр туктагач, Зевс аларга ташлар җыярга куша. Девкалион җыйган ташлар – ир кешегә, Пирра җыйганы хатын-кызга әверелә. Шулай итеп, Туфаннан соң җирдә таштан яралган кешеләр токымы яши башлый[3]. Бөтен дөньяны туфан басу турындагы мифлар Алтай төркиләрендә дә популяр була. Теленгитлар легендасы буенча Алтай шаманизмының өлкән алласы Үлген Нам исемле кешегә туфан турында хәбәр бирә, сал ясап шунда һәр җан иясеннән берәр пар алырга куша[4].

---

[1] Библия, Быт, 9, 19.

[2] *Крамер С.Н.* Мифология Шумера и Аккада. Мифология древнего мира. М.: Наука, 1977. 402 с.

[3] *Кун Н.А.* Мифы и легенды Древней Греции. Душамбе: Гл. науч. ред. тадж. сов. энциклопедии, 1988. С. 68.

[4] *Вербицкий В.И.* Алтайские инородцы. М., 1903. С. 102–103.

Кайсы гына халыкның туфан турындагы легендаларын карасак та, алар бер сюжетка корылган. Туфан суы Алла тарафыннан кешеләрнең бозыклыгына җәза итеп җибәрелә. Үзләренең әхлакый сыйфатлары белән башкалардан өстен торган, гөнаһсызлыклары белән танылган берничә кеше генә исән кала. Алардан туып җирдә яңа кешеләр токымы яши башлый. Тәүрат һәм Коръәндәге Ной/Нух турындагы легендаларның нигезендә шушы борынгы миф ята. Бу сюжет алга таба дини әдәбият аша тагын да киңрәк тарала. Тәүрат-Коръәнгә яраклаштырылган, шәҗәрә тарихын Нух, Яфәс (Яфәт) һәм Төректән башлаган төрле варианттагы генеалогик легендалар күп халыкларда тарала.

Нух пәйгамбәр турындагы легенда XIII йөз – XIV йөз башында яшәгән фарсы галиме Рәшид-әд-диннең «Җәмигъ әт-тәварих» хезмәтендә дә теркәлгән: «Нух пәйгамбәр җирне төньяктан көньякка таба өч кисәккә бүлә. Беренче өлешен Хамга бирә. Аңардан кара тәнле кешеләр токымы барлыкка килә. Икенче өлешен Симга бирә – ул гарәп һәм фарсыларның нәсел башы була. Өченче өлешне Яфәткә (Яфәскә) бирә һәм аны Көнчыгышка җибәрә. Яфәттән бөтен төрки халыклар башлана[1]. Легенданың тагын бер варианты Н.Я. Бичуринның Урта Азиядә яшәгән халыкларның тарихын яктырткан хезмәтендә очрый: «Яфәт улы Төрекне Каспий диңгезеннән алып, Корея култыгына кадәрле территорияләрдә Урта Азиядә яшәүче барлык төрки халыкларның нәсел башы дип саныйлар. Төрекнең җиденче буын оныклары – игезәкләр туа: Татар һәм Монгол. Әтиләре Илли-хан, Төрек илен бүлеп, Татарга илнең көнчыгышын, Монголга көнбатыш ягын бирә. Монголдан өченче буында Кара-ханның улы бөек Огуз-хан туа»[2]. «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгының беренче әсәре «Чыңгыз хан

---

[1] *Рашид ад-Дин.* Сборник летописей. Том 1. Книга 1. М.-Л. АН СССР. 1952.С. 80.

[2] *Бичурин Н.Я. (Иакинф)* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. М.-Л.: Изд-во АН СССР. Т. I. 1950. С. 222–223.

турындагы дастан» да Чыңгыз хан нәселенең Нух пәйгамбәрдән башланган шәҗәрәсен бәян итүдән башлана[1].

Карап үткән легендалардан аңлашылганча, татар халкында ике сюжет линиясенә тупланган генеалогик әсәрләр популяр булган. Беренче легенданың версияләре VI–VII гасыр Кытай хроникаларында ук язмача теркәлеп калган, ул төрки халыкларның килеп чыгышын тотем хайван – бүре белән бәйли. Болгар территориясендә археологик казу эшләре вакытында табылган «гарип» сыннар бу сюжетның болгарларда да популяр булуын исбатларга мөмкинлек бирә. Икенче сюжетка корылган легендалардан аны татар халкына ислам дине, Коръән аша кергән дип фаразларга мөмкин. Туфан турындагы сюжетның тамыры, Шумер-Аккад мифологиясе белән генә чикләнмичә, тагын даераграк китә булса кирәк. Туфан турындагы легендалар татар халкында XXI йөз башына кадәр популяр була. Алар кешеләргә бу дөньяның фани булуын искәртә.

---

[1] Дәфтәре Чыңгызнамә / басмага әзерләүче, сүзлек һәм аңлатмалар авторы Сәлим Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 5.

## КҮБӘЛӘКТӘЙ ҖАН БИРГӘН
(Төрки фольклорда җан белән бәйле ышанулар)

Төрки фольклорда, мифологиядә җан белән бәйле ышанулар-күзаллаулар күп саклана. *Җан* сүзе күп төрле мәгънәләргә ия. Татар фольклорында һәм мифологиядә җан «тәнгә тереклек бирә торган һәм аннан башка да яши ала торган мәңгелек башлангыч» буларак күзаллана[1]. Димәк, җан – тере затның үлемсез, матди булмаган, ягъни рухи өлеше, яшәешнең төп кыйммәте. Мифларда һәм фольклор әсәрләрендә җан параллель дөньяларны үзара бәйләп торган төп кыйммәт.

Җан төшенчәсенең мифологиядәге, ягъни халык күзаллавындагы аңлатмасына, беренчеләрдән булып, этнограф Эдуард Тэйлор игътибар итә. Аның «Первобытная культура» дигән хезмәтендә җан белән бәйле ышануларның килеп чыгуы аңлатыла, җанга билгеләмә бирелә. Галим, йокы, төш күрү, авыру-үлем күренешләренә бәйле ышану, күзаллауларны анализлау нәтиҗәсендә, җанның кеше эчендә утырган «зат»; «ия» дип кабул ителүен яза[2].

Төрки фольклорда да җан шундый «зат» рәвешендә күзаллана. Җанның төрле халәтен белдергән сүзләр дә төркиләрдә шактый. Мәсәлән, *тын-тун, кут-кот, сур, сүне* һ.б. *Тын* сүзе татар телендә хәзерге вакытта сулыш мәгънәсендә сакланган. *Тын-сулыш* җанлы субъектларга гына хас булып, *тын алмау* үлемне белдерә. Күп төрки телләрдә ул җан мәгънәсен саклый. Алтай телендә *тыны чыгу* – җан чыгуны, *тын өзелү* – үлемне; тува телендә *тын* – тереклек, яшәүне аңлата. Татар телендә *тынып калу, тынсыз калу* гыйбарәләре күпмедер дәрәҗәдә сүзнең борынгы мәгънәсен саклый. *Тын-сулыш* сүзләренең

---

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. Б. 772.

[2] *Тэйлор Э.* Первобытная культура. М.: Государственное социально-экономическое издательство, 1939. С. 259–345.

җан белән бәйле булуы рус телендә дә күренә. *Душа* сүзе белән *дыхание* сүзләре дә уртак тамырдан.

Җан мәгънәсендә икенче сүз – *кот* сүзе, *кот* – гомумтөрки сүз. Кот (ягъни кут) сүзенең мәгънәләре күп. Бу очракта сүзнең *җан, рух, яшәү көче* дигән мәгънәләре кызыксындыра. Сүзнең бу мәгънәсе татар халкының әйтем-мәкальләрендә саклана. «Котым очты», «кот чыгу», «кот ботка төшү» гыйбарәләреннән котның тәннән чыгып китүе, яки күчеп йөрүе аңлашыла.

Алдарак искәртелгәнчә, җан төрле дөньяларны бәйләп торган уртак кыйммәт. Җанны күкләр бирә, җир дөньясында яшәүчеләр гомерләре буе җаннарын саклар өчен көрәшә, аны саклыйлар, кадерлиләр, югалтудан куркып яшиләр. Үлгәннән соң кешенең җаны «теге» дөньяга, яки үлеләр дөньясына күчә.

Фольклорда кешенең җаны урнашкан урыннар турында бай мәгълүмат, мифологик карашлар сакланган.

Борынгы ышанулар җанны кан белән бәйли. Бу ышанулар килеп чыгуны аңлату кыен түгел – каны агып беткән зат яшәүдән туктый. Шушы күренешне күзәткән борынгылар җанны кан белән тәңгәлләштергән. Кан бары җанлы затларда гына булып, ул аларның урта дөньяга – кешеләр дөньясына каравын да күрсәтә. Һәм киресенчә, геройның каны булмау – аның кеше булмавын, башка дөнья вәкиле булуын исбатлый.

Кансыз геройлар төрки эпоста да очрый. Мәсәлән, төркиләрнең уртак мирасы «Кузы Көрпәч һәм Баян-Сылу» дастанының алтай версиясе «Козын-Эркеш»нең төп герое түбәндәгечә сурәтләнә:

Козын-Эркеш юноша
Богатырем родился,
Кровью истечь – у него крови нет;
Умереть – у него души нет[1].

«Идегәй» дастанының татар версиясендә дә җанның кан белән бәйләнеше турындагы ышануга мисал бар.

---

[1] *Улагашев Н.У.* Алтай-Бучай. Ойротский народный эпос / под редакцией А. Коптелова. Новосибирск: ОГИЗ, 1941. С. 205.

Кадыйрбирде бер чүкте,
Түбәсеннән кан чыкты,
Кан чыкканда җан чыкты! [1]

Татар халык мәкале дә җанның канда яшәвенә ышануга мисал була ала:

Җан канда чәчәк атар, гөл – кояшта[2].

Төрки-монгол халыкларында батырлар үзләрен каннарын чыгармый үтерүне сорыйлар. Бу очракта каһарман җаны исән калуга һәм яңадан дөньяга килүгә өметләнә. Мәсәлән, монгол халкының XIII йөзгә караган «Сокровенное сказание» дигән язма истәлеген дә («Юнь-чао би-ши») Тимучинның сугышчан дусты Джамуха үзен канын чыгармыйча үтерүне сорый:

Если казнишь, то казни ты меня
Лишь без пролития крови.
Смертным забудусь я сном.
Ныне же скорей оптусти же меня![3]

Бу юллардан каны коелмаган кеше үлми, бары икенче дөньяга гына китә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Канны җан белән тәңгәлләштерү диндә дә бар: Библиядә канны ризык итеп куллануда тыю шуның белән аңлатыла: «Ибо душа всякого тела есть кровь его, она душа его»[4]. Ислам дине дә канны ризык буларак куллануны тыя, әмма аның сәбәбе ачык күрсәтелми[5].

Төрки мифологиядә һәм фольклорда җан төрле аерым органнарда да саклана. Шуларның беренчесе – баш. Кешенең җаны башында урнашкан дигән ышану белән бәйле рәвештә

---

[1] Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 239.

[2] *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Т. 2; Б. 816.

[3] *Козин С.А.* Монгольская хроника 1240 г. / Институт востоковедения АН СССР. М.- Л.: Изд-во АН СССР, 1941. Т. I. § 201.

[4] Ветхий завет. Левий: 17,14 // Библия. Книги Священного писания Ветхого и Нового завета. Брюссель: Изд-во «Жизнь с Богом», 1989.

[5] Коръән, 16: 115; 2: 173; 5: 3.

Кисек баш образы формалашкан. Мәсәлән, урта гасырның әдәби ядкарьләре «Кисекбаш», Хисам Кятибнең «Җөмҗемә Солтан» әсәрләрендә геройларның гәүдәләреннән аерылган башы яшәвен дәвам итә. Татар халкының мәкаль-әйтемнәрендә дә башның иң кирәкле орган булуы аңлашыла: «Баш исән булсын», «Баш исән булса, мал табыла».

Фольклорда Кисек баш мотивы «Ак Күбек» дастанында очрый. Ак Күбек Коден ханның башын кискәч тә, Коден ханның башы сөйләшүен дәвам итә. «Огуз хан» дастанында да шушы ышану саклана: *men senä bašumni gutumni berämen*[1]. Ягъни, мин сиңа үземнең башымны, үземнең җанымны бирәм. Бу мисалда җан кот сүзе белән бирелгән, башны бирү җанны бирүне аңлата.

Төрки фольклорда җан бармакта саклануын тасвирлаган үрнәкләр дә очрый. Төркиләрдә баш бармакның (яки урта бармакның) кешенең үзе белән чагыштырылуы яки тәңгәлләштерелүе дә мәгълүм. Баш бармакның хайваннарның күпчелегендә булмавы, кешеләрне хайваннардан аеручы билге булып тора. Алтай дастаны «Алтай-Буучай»да батырның җаны аның баш бармагында урнашкан:

Пикой его колют – проткнуть не могут,
Рубят мечом –
Мечу не поддается
Иного способа придумать не могли.
«Два больших пальца (рук)
Надо отрезать», – сказали
И два больших пальца
С хрустом резать стали[2].

Батырның баш бармакларын кискәч кенә, аны үтереп була, геройның җаны чыга.

Җанның бармакта урнашуы турындагы ышану эзләре татар халкының тылсымлы әкиятләрендә бар. Мәсәлән, «Ях-

---

[1] Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. С. 471.
[2] *Суразаков С.С.* Алтайский героический эпос. М.: Наука, 1985. С. 45.

шылыкка – явызлык» дигән әкияттә мондый эпизод бар: Җалмавыз карчык[1] батырны йоткач, аны кире төкерми. Карчыкның эчен ярып карыйлар, Батыр карчыкның эчендә дә табылмый. «Шуннан һәртөрле сөякләрен бергә җыеп китереп карасалар, баш бармагы юк икәнлеге аңлашыла. Бармак, чабып җибәргәндә, бер читкә тәгәрәп киткән икән. Бармакны табып ярып карасалар, эченнән таркан хәтле генә кеше килеп чыга»[2]. «Әйгәли» әкиятендә дә убырлы карчык йоткан кешене убырлының бармагында табалар. «Таңбатыр» әкиятендә дә баш бармак убырлы карчыкның үзе булып чыга. Бу өч әкияттә дә, баш бармакта җан саклана, яки ул кешенең үзенең күчермәсе булып тора.

Дастаннарда җанның иминлеген тәэмин итүнең тагын бер шарты – һәр сөякнең урынында булуы. Җан иминлеге сөякләр ныклыгына да мохтаҗ. Мәктәп-мәдрәсәләрдә балаларны «Ите сезгә, сөяге безгә» дип тапшыру, «Сөяк-санагың сау булсын!» дигән теләкне аңлата. Дастан героена кире җанын кайтару өчен, аның сөякләрен урыннарына урнаштыру шарт. Шуннан соң геройга сулыш-тын, ягъни җан өрелә. Җан – искән җил белән дә тәңгәлләшә. «Козын-Эркеш»тә геройны үтерү өчен аның һәр сөяген буыныннан аеру кирәк:

– Кости мои, пересчитывая,
По суставам режь [3].

Шушы ук дастанда җанны җеп яки чәч кебек нечкә итеп күзаллауның мисалы да бар.

Как волос, тонкую душу его
Я порвал [4].

---

[1] Татар мифологиясендә һәм әкиятләрендә очрый торган явыз зат, убырлы карчык. .

[2] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Беренче китап / томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 208.

[3] *Улагашев Н.У.* Алтай-Буучай. С. 228.

[4] Шунда ук. Б. 230.

Татар телендә дә *өзелү, җан өзелү* гыйбарәләре бар. Алар үлемне аңлата.

Әкиятләр-дастаннарда җанның гәүдәдән аерым саклануы, хәтта еракта, бөтенләй чит предметларда яшерелгән булуы турында да ышанулар саклана. Әкиятләрдә Дию, Дию пәрие кебек образларның җаны еракта булып, геройга Диюне җиңү өчен шактый киртәләр үтеп, аның җанын кулга төшерү кирәк була. «Унберенче Әкмәт» дигән әкияттә Җен патшасының җаны үз тәнендә түгел, ә ерак утрауда саклана. «Юк, – ди, карт әйтә, – минем җаным бу тирәдә түгел, – ди, – менә моннан бер 150 чакрымда читтә, бер күл бар, – ди, – шул күл уртасында бер утрау бар, утрау уртасында бер үрдәк оясы бар, үрдәк оясында дүрт йомырка бар, минем җаным шулар эчендә, – ди»[1].

Дастан геройларының җаны белән аларның яу коралы арасында да бәйләнеш бар. Үзләренә махсус аталган корал булдырган вакыттан алар арасында бәйләнеш барлыкка килә. Герой үзенең коралы белән бер булып карала башлый, еш кына аны бары үзенең коралы белән генә үтерергә мөмкин. Мәсәлән, татар халкының «Ак Күбек» дастанында Маңгыш үзен бары үз коралы белән генә үтерергә мөмкин булганын әйтә, Ак Күбеккә үзенең кылычын бирә. «Козын-Эркеш» дастанында да яшәү мәгънәсен җуйган Козын-Эркеш дошманы кулына үз коралын тоттыра. Шул ук дастанда Козын-Эркешне яңадан терелтү өчен башта аның сынган хәнҗәрен ялгау кирәк.

Алмазный нож с желтой ручкой
Переломленной оказался.
Байым-Сур красавица
Алмазный нож подняла,
Целебной водой его облила,
Белым можжевельником окурила,
В белый шелковый платок завернув,
На груди его подержала...
Алмазный нож
Вновь целым стал,

---

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Беренче китап. Б. 285.

Козын-Эркеш богатырь
Глаза открыл[1].

Өзектән күренгәнчә, өзелгән сөякләрне ялгау да, тере суы бөркү дә, башка магик ритуаллар башкару да Козын-Эркешкә җанын кире тәненә кайтарырга ярдәм итми. Байым-Сур геройның җанын артыш төтене белән дә, ак яулык белән җилләтеп тә кире тәненә кайтарырга омтыла. Бу өзектә Козын-Эркеш яңадан терелсен өчен, Байым-Сур геройның коралын да яңадан ялгарга тиеш була. Геройның җаны коралы белән дә бәйләнештә.

Татар телендә *сулыш өрү* дигән гыйбарә бар. Ул *җан иңү*не аңлата. Дастаннарда, әкиятләрдә геройга җан өрү аңа тын (сулыш) өрү буларак та бәян ителә. Бу очракта җан җил буларак тасвирлана. «Турай батыр» дигән татар әкиятендә үлгән геройны анасы, үзенең җылы сулышын өреп, яңадан терелтә.

Тереклекнең вакытлы булуы, аның теләсә-кайсы вакытта өзелүе борынгыларда җанны нечкә җеп рәвешендә күзаллауны да тудырган. Бу күзаллау да татар телендәге үлемне аңлаткан *тыны өзелү, җаны өзелү,* яки *өзелү* гыйбарәләрендә саклана. *Җан җебе* дигән гыйбарә дә бар.

Кеше үлгәндә аның җаны тын, сулыш яки җил булып чыга, һәм тере кешенең җаны ниндидер зат буларак күзаллanса да, ул төгәл реаль зат (материал) буларак сурәтләнми. Татар мифологиясендә үлгәннән соң кешенең җаны матдиләшеп, күбәләк, кош булып күзаллана башлый. Төрки фольклорда һәм әдәбиятта *җан кошы, күбәләк җан, чебен җан* дигән сүзтезмәләр очрый. Кыргыз халкының «Манас» эпосында *чебендәй җан* дигән гыйбарә бар. Башкорт халкының «Урал-батыр» поэмасында исә җан *күбәләктәй* дип сурәтләнә. «Кызыл әтәч» дигән татар әкиятендә кешенең җаны сары чебен буларак тасвирлана. Кеше йоклаганда аның җаны чебен булып очып китә. Кеше чебен кире кайтып авызына кергәч кенә уяна.

[1] *Улагашев Н.У.* Алтай-Бучай. С. 285.

Мифологиядә һәм фольклорда җанның кош булып очып китүе дә саклана. Гомумән, төркиләр үлгән кешенең җаны күгәрчен яки башка кош булып оча дип күзаллыйлар. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да шушы ышану чагылыш тапкан:

Шәриф тәннән аерылды гъәзиз җаны,
Кошка охшап, ул оҗмахка очты инде[1].

Төрки фольклорда җан белән бәйле күп ышанулар сакланган. Алардан җанның күкләр тарафыннан бирелгән кыйммәт булуы аңлашыла. Ул кеше тәнендә матди булмаган субстанция халәтендә яши һәм, кеше үлгәннән соң, яңадан күкләргә кайтарыла.

[1] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф / төз. Н. Хисамов. Казан: Матбугат йорты, 2008. Б. 273.

## ҮЗЕМНЕҢ КОТЫМ БАР ӨЧЕН...

(Борынгы *кот*/*кут* сүзенең мәгънәләре турында)

Караханилар чорының безнең көннәргә килеп җиткән күренекле әдәби истәлекләренең берсе – Мәхмүт Кашгарыйның «Диване лөгатет төрк» (1072–1074) сүзлегендә төрки халыклар телләрендә очрый торган тугыз мең чамасы сүз һәм сүзтезмә китерелеп, һәр сүз яки гыйбарә, сүзтезмәнең мәгънәсе халык иҗатына караган әсәрләрдән өзекләр, мәкаль-әйтемнәр аша аңлатып бирелә.

Әлеге хезмәттә хәзерге вакытта да татар телендә еш кулланыла торган, әмма шул ук вакытта беренчел мәгънәсен югалткан *кот* сүзе кергән берничә мәкаль дә бар. Бу мәкальләр түбәндәгеләр:

Улугны улугласа кут болур[1] (Олыны олыласа, бәхетле/котлы булыр).

Кут бәлгиси билик[2] (Бәхет/кот билгесе – белем).

Кутлугка коша йагар[3] (Бәхетлегә/котлыга куш явар, ягъни ике өлеш тияр).

Ума келсә кут келир[4] (кунак килсә, бәхет/кот килер).

Эрдәмсиздән кут чертилүр[5] (әдәпсездән бәхет/кот китәр).

Кутсуз кудугка кирсә, кум йагар[6] (бәхетсез/котсыз коега төшсә, өстенә ком явар).

Мәхмүт Кашгарый шунда ук «кутсуз» сүзенә дә аңлатма бирә:

---

[1] *Кошгарий Махмуд.* Девону луготит турк (Туркский сузлар девону). Уч томлык. Тошкент: Узбекстан ССР Фанлар Академияси нашриёти, 1960. Т. 1. Б. 297.

[2] Шунда ук. Т. 1.Б. 403.

[3] Шунда ук. Т. 2. Б. 68.

[4] Шунда ук. Т. 1. Б. 118.

[5] Шунда ук. Т. 2. Б. 266.

[6] Шунда ук. Т. 1. Б. 426.

Кутсуз – иши оркасига кеткан одам[1] (Котсыз – эше кире киткән адәм).

Бу мәкальләрдән аңлашылганча, «кут» сүзе бәхетне аңлата. Әмма мәкальләрдән котның да ике төрле булуын күрәбез. Аның беренчесе – бәхет, һәм кеше үз-үзен тотышы, әдәбе-тәрбиясе, тырышлыгы ярдәмендә бу бәхеткә ирешә ала. Бу рәвешле котлы, ягъни бәхетле булуның төп шартлары да күрсәтелә: мәкальләр буенча бу шартлар – белем алу, олыларга ихтирамлы булу. Ягъни тәрбияле, әхлаклы, олыны олы иткән, кунакчыл, үзенең белемен арттырган, гыйлемгә омтылган кешенең бәхетле булырга мөмкинлеге зуррак. Алдагы ике мәкальдә котлы булуның кешенең үз ихтыярында булмавы, язмыш белән бәйле булуы аңлашыла. Татар телендәге «күктән төшкән бәхет» яки «күктән ишелгән бәхет» гыйбарәләре нәкъ шушы очракка туры килә. Котлы кешегә артык тырышлык куймыйча да мал, дәүләт үзе килә, ә котсыз кеше ничек кенә тырышмасын, эше бармый. Мәхмүт Кашгарый котсыз кешене «эше кирегә китә торган адәм» дип аңлата. Соңгы ике мәкальдән котның Алла тарафыннан бирелгәнлеге, кешенең үз тырышлыгы белән аңа ирешә алмавы аңлашыла.

Бу үрнәкләрдән күренгәнчә *кот* сүзенең ике мәгънәсе бар. Беренчесе – кешегә үз тырышлыгы белән килгән, икенчесе – Алла тарафыннан бирелгән бәхет.

«Кут» яки «кот» бик борынгы төрки сүз. Аның язмача теркәлеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән беренче үрнәкләре VIII гасырга карый. Сүз Орхон-Енисей язмалары дип фәнгә кергән ташъязмалар турында бара. Бу язмаларда «кот» сүзенең мәгънәсе бәхет сүзенә генә туры килми. Ул кешенең Алла тарафыннан сайланган, башкалардан өстен куелган булуын аңлата, һәм хәзерге вакыттагы «харизма» мәгънәсенә туры килә. Күлтәгин истәлегенә куелган ташта әлеге шәхеснең котлы булуы аркасында тәхеткә утыруы, хакимлекнең күкләр тарафыннан бирелүе турында сүз бара. «„Тәңри ярлыкадукын үчүн, өзим кутым бар үчүн, каган олуртым“ („Тәңре ярлыкаган өчен, үземнең котым бар өчен, каган

[1] *Кошгарий Махмуд.* Девону луготит турк. Т. 1. Б. 426.

булдым“)»[1]. Л.П. Потапов «кут» сүзенең нәкъ шушы мәгънәсенә игътибар итә һәм әлеге сүзне тәхеткә утырырга Алла тарафыннан бирелгән хокук дип аңлата[2]. Орхон-Енисей ташъязмалары дәверендә «кот» сүзе Тәңре тарафыннан сайланган шәхесләргә, хөкемдарларга карата кулланылса, бераз соңрак аның мәгънәсе киңәеп, ул «бәхет» һәм «эшнең уңайга китүе», һәм татар телендә тәрҗемәсе булмаган «везение» мәгънәсен дә ала. Шул рәвешле кот ике мәгънәне аңлаткан: беренчесе – Алла биргән яки күктән төшкән бәхет булса, икенче мәгънәсе – кеше үзенең тәрбиясе, әдәп-әхлагы белән ирешкән бәхет. Котбәхет, кот-харизмадан аермалы буларак, тырышлык, хезмәт, тәрбия нәтиҗәсе. XI йөз әдибе Йосыф Баласагуниның «Кутадгу белег» әсәрендә дә *кот* сүзе бәхет мәгънәсендә кулланыла. Шагыйрь кешене бәхетле иткән шартларны курсәтә. Мәсәлән, *Кешене тел агырлар, булыр кот кеше*[3] (Кешене тел аклар, булыр бәхетле кеше). Бу – белемле булу, кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булу, тәмле телле булу һ. б. Поэмадан аңлашылганча, бәхетле булу кешенең үз кулында. Әсәрнең исеме дә шуны аңлата. Аны «бәхет юлларын өйрәтүче яки бәхетле булу өчен белем» дип аңларга да мөмкин. Чөнки әсәрдә нәкъ бәхетле булуның, бәхетле җәмгыять төзүнең кануннары бәян ителә.

Алтын Урда чорына караган аноним көмеш тәңкәләргә дә уйгыр хәрефләре белән «Кутлуг болсун» дигән сүзләр язылган. Бу да «бәхетле булсын!» дигән мәгънәне аңлата[4].

Кут – барлык төрки халыклар өчен уртак сүз. Казак һәм каракалпак телләрендә ул яшәү көче, жан, хайваннарны саклаучы амулет һәм бәхет мәгънәләрендә кулланыла. «Кот качу» гыйбарәсе эшнең кирегә китүен аңлата. Кут тува телендә – жан, яшәү көче; хакасларда – җан, рух, яшәү көче. Шушы ук тамырдан ясалган

---

[1] *Малов С.Е.* Памятники древнетюкской письменности. Тексты и исследования. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1951. С. 28

[2] *Потапов Л.П.* Умай – божество древних тюрков в свете этнографических данных // Тюркологический сборник. 1972. М., 1973. С. 196.

[3] *Юсуф Хос Хожиб*. Котадгу билиг. Тошкент: Фан, 1971.

[4] *Бартольд В.В.* Сочинение. Т. 5. Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов. М.: Наука, Гл. ред. вост. литературы, 1968. С. 139.

сүзләр монгол һәм тунгус-маньчжур телләрендә дә бар. Бу телләрдә *кут* тамыры белән ясалган сүзләр *бәхет* мәгънәсен бирә.

Сүзнең иң борынгы мәгънәсе – жанның матди чагылышы – эмбрионны һәм яшәү көчен аңлата.

Хәзерге татар әдәби телендә *кот* сүзе белән ясалган гыйбарәләр, сүзтезмәләр күп Хәзерге татар телендә *кот* сүзе берничә мәгънәдә кулланыла. «Котлы булсын», «котлау», «котлы» сүзләрендә ул бәхет мәгънәсендә кулланыла: бәхетле булсын, бәхет теләү, бәхетле. Котлау изге теләк теләүне аңлата. «Кот очу», «кот очкыч», «кот очыргыч» гыйбарәләрендә *кот* сүзенең мәгънәсе «җан» яки «яшәү көче»нә якын. «Кот» сүзенең борынгы төрки телләрдә жан, яшәү көче, рух мәгънәсен белдерүенә Н.А. Баскаков та игътибар итә[1]. Бу очракта *кот* сүзенең мәгънәсе җан сүзеннән бераз аермалырак. Җан чыгу – туры мәгънәсендә үлемне, кот чыгу – бик нык куркуны белдерә. Ул, жан булудан бигрәк, кешене сәламәт хәлдә тотучы рух. Татар халкының ышанулары буенча, коты чыккан кешенең яшәү көче бетә, ул авырый башлый.

Татар телендә *кот* дип мәҗүсилек чорында кешенең рухын, икенче җанын гәүдәләндергән кургаштан коелган кечкенә сыннарны яки курчакларны да атаганнар. Шулай ук кешене бәлаказалардан саклаучы, аның яшәү көчен саклаучы бөтине, амулетны да *кот* дип атыйлар. Хәзерге вакытта кадәр «кот кою», «кот чакыру» дигән им-том төре билгеле. Ул җаны-рухы имгәнгән, бик каты курыккан, авырган кешеләрне имләүне аңлата.

Сүзнең тагын бер мәгънәсе матурлык, байлык, ямьне белдерә. Мәсәлән, котсыз кеше – ямьсез кеше, өйнең коты китү – яме китү, котаю – баю һ.б.

Бу мисаллардан күренгәнчә, телебездә актив кулланылышта булган гади генә кот сүзенең ерак үткәннәргә киткән тарихы, күп мәгънәләре бар. Ул җан, эмбрион, яшәү көче, рух, бәхет, уңыш, Күкләр/Тәңре тарафыннан бирелгән бәхет, харизма, ямь, матурлык, байлык мәгънәләрендә кулланылган һәм кулланылуын дәвам итә.

---

[1] *Баскаков Н.А.* Душа в древних верованиях тюрков Алтая (Термины, их значения и этимология) // Советская этнография. 1973. № 5. С.109.

## ТӘКЪДИРЕНӘ НИ ЯЗГАН БУЛСА ХОДА…

(Төрки фольклорда һәм Урта гасырлар әдәбиятында язмыш мифологемасы)

Язмыш – кешенең үзе туганчы ук билгеләнгән яки язылган тормышы, эш-гамәлләре, яшәеше, һәр адымының – бәхет һәм бәхетсезлегенең илаһи көчләр яки күкләр тарафыннан билгеләнгән булуы. Ислам дине кабул ителгәннән соң, язмыш белән янәшә шул ук мәгънәдәге тәкъдир сүзе дә кулланыла башлый. Тәкъдир – Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән язмыш. «Тәкъдиргә язылу», «Тәкъдир тактасы» кебек гыйбарәләр дә бар. Язмышның «өлеш» сүзе белән аталуы да мәгълүм. Өлеш – һәр кешенең өлеше, аңа бүлеп бирелгән гомер, тормыш, бәхет, кайгы-хәсрәт. Өлеш сүзе, беренче чиратта, бәхетне яки бәхетсезлекне һәм һәр кешегә яшәү өчен бүлеп бирелгән вакытны күз алдында тота. Язмыш мәгънәсендә «язу» сүзе дә кулланыла. Авыр язмышлы кешеләргә карата «язулы» дигән сүз кулланыла. Бу сүзләр барысы да «язу» тамырына кайтып кала, бу – язмышның норматив характерына ишарә ясый. Язмыш – кешенең үзе туганчы ук билгеләнгән, Алла тарафыннан язып куелган киләчәге, тормышы. Язылган язмышны кеше үзгәртә алмый.

Фарсы теленнән кергән «фәләк» сүзе дә язмышны аңлата. Бу сүзнең беренче мәгънәсе «күк йөзе», ул да язмышның күкләр белән бәйләнешенә күрсәтә.

Язмыш – татар әдәбиятында һәм фольклорда төп мифологемаларның берсе. Фольклорда да, борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятында да язмыш мотивы берничә аспектта ачыла: язмышның алдан билгеләнгән, язылган булуы; кешенең язмышы алдында көчсезлеге; шул ук вакытта язмышны үзгәртергә, фаҗигале язмыштан качарга тырышу, язмышны, ягъни бу очракта алда ни көткәнен белергә омтылу һәм төрле ритуал-йолалар белән язмышны бәхетле итәргә теләү.

Язмыш белән бәйле ышанулар фольклорның иң кечкенә күләмле жанрлары – мәкаль-әйтемнәрдә күп саклана. Аларда язмышның котылгысыз булуы, аннан качып, аны үзгәртеп булмау турында сүз бара.

Адәм сөйләр, тәкъдир көләр.
Адәм сөйли, язмыш көйли.
Бәндәнең тәбдире Алланың тәкъдиреннән узмый.
Бер башка ике язмыш юк.
Берәүгә язган икенчегә булмый.
Безгә язганны болан күтәрмәс.
Кая барсаң да кара сакалың артыңнан калмас.
Өлешеңә тиеш көмешең һ.б.

Бу мәкальләрдән һәр кешенең үз язмышы, үз өлеше булуы аңлашыла. Ул өлеш – кешенең бәхетле яки бәхетсез булуы. Язмыш һәр кешегә күкләр, Тәңре яки Алла тарафыннан бирелә. Язмыш белән бәйле ышанулар бик борынгыдан килә. Төрки халыкларның язмыш белән бәйле ышануларының безнең көннәргә килеп җиткән иң борынгы үрнәкләре Орхон-Енисей буе эпитафик истәлекләрендә саклана.

Мәсәлән, Билге-Каган истәлегенә куелган ташта аның барлык тормышының күкләр тарафыннан бирелгән язмыш булуы күренә: «Тäңрi јарлыкадукын ӳчӳн, ӳзiм кутым бар ӳчӳн»[1]. Рун язулы истәлекләрдә язмыш ülüg сүзе белән бирелгән. Әлеге язмаларда һәр нәрсәнең күкләр тарафыннан бирелгән язмыштан булуы күрсәтелә: Кули-Чур язмаларында безнең көннәргә кадәр телдә кулланылышта булган шундый гыйбарә бар: «ülüg anča ermiš erinč»[2] (язмышы шундый булган). Бу язмаларның барысында да Күк яки Тәңре күздә тотыла. Һәр нәрсәнең Тәңредән булуы, язмышны үзгәртү мөмкин булмау аңлашыла. Кешегә язмышын ничек бар шулай кабул итәргә,

---

[1] *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1951. С. 28.

[2] *Малов С.Е.* Енисейская письменность тюрков. Тексты и переводы. Л.: Изд-во АН СССР, 1952. С. 62.

аның белән килешергә генә кала. Татар мәкальләрендә дә язмышның котылгысыз булуы аңлашыла:

Адәм сөйли, язмыш көйли.

VIII–IX яки IX–X йөзләргә нисбәт ителгән рун язулы «Ырк битиг» – борынгы төркиләрнең безнең көннәргә кадәр килеп җиткән юрау китапларының берсе. Бу китапта Юл Тәңресе турында болай язылган: «Ala atiyɣ jol tänri män. Jaryn kičä äšűr män...Qorkma, – timiš, gut birgäї män, – timiš»[1] (Ала атлы юл Тәңрисемен. Иртән кичә йөрим. Курыкма – тимим, кот бирүчемен, ди). Шушы ук язмада ул икенче тапкыр «Qara jol taņri män»[2] (Кара юл тәңресе) дип бирелә. Бу Тәңренең вазифалары – дөньяда иминлекне тәэмин итү, кешеләргә бәхет бирү. Юл Тәңресе кешеләргә бәхет өләшә, аңардан бәхет сорыйлар. Мисалда да Юл Тәңресеннән бәхет сорарга кирәклеге дә аңлашыла: «Är ömäläjä barmyš täņrikä soogušmyš gut golmyš gut birmiš»[3] (ир үрмәләп барды Тәңрегә, сорады кот, көлде, кот бирде).

Бу мисаллардан күренгәнчә, борынгы төркиләрнең үзенең махсус вазифалары булган язмыш тәңресенә ышанганнары аңлашыла. «Ырк битиг»тә («Юрау китабы»нда) теркәлгән язмада ул кешеләргә бәхет өләшүче буларак сурәтләнә.

Борынгы төрки халыкларда язмыш махсус китапта язылса, татар халкында аның кешенең маңгаена язылуына мисаллар бар. Язмышның һәр кешенең маңгаена язылган булуы турында ышану мәкальләрдә саклана: «Маңгайга язылган язмышны тир белән сыпырып төшереп булмый». Ислам мифологиясе буенча кешенең язмышы «Тәкъдиренә язылган», яки «Тәкъдир тактасы»на язылган була, һәм шул ук вакытта һәр гамәле «Ләүхел Мәхфүз»гә[4] язылып бара. Димәк, ислам кануннары буенча кешенең язмышы алдан ук билгеләнгән,

---

[1] *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. С. 80.

[2] Шунда ук. С. 83, 90.

[3] Шунда ук. С. 83.

[4] Ләүхел Мәхфүз (гарәп.) – кешенең гомере буе кылган гамәлләре языла бара торган такта. Бу язмалар җуелмый (Зайнуллин Д.Г. Словарь арабо-персидских заимствований. Казань: Магариф, 1994. С. 79).

маңгаена язылган булса да, күпмедер дәрәҗәдә үзеннән дә тора, ул үзенең эш-гамәлләрендә ирекле, тормышының аерым борылышларында үзе сайлаган юлдан китә ала. Шул рәвешле ислам дине кешегә һәрвакыт яңа мөмкинлекләр бирә[1].

Хәзерге татар телендә «Язмышлар китабы» дигән гыйбарә саклanса да, әлеге китап турында татар фольклорында мәгълүмат юк. Язмыш китабы турында ышанулар Алтай халыклары фольклорында һәм мифологиядә яхшы сакланган. Язмыш китабы образы алтай эпосында бер әсәрдән икенчесенә күчә бара, төрле яктан ачыла. Алтай фольклорында язмыш китабы «Ай-Судур» яки «Судур-Бичик» дип атала, яки «Ойгор бичиг» – акыллы, зирәк китап, дигән вариантта да очрый. Бу китапта геройның исеме, аты, бөтен тормышы бәян ителә. Герой үзенә аталган ат, насыйп киләчәге турында да шушы китаптан укып белә.

Мәсәлән, күпчелек төрки халыкларның уртак мирасы булган «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу» дастанының Алтай версиясе «Козын-Эркеш»нең төп герое Козын-Эркеш шушы китаптан үзенең кем булуы турында, булачак киләчәге турында укый:

Козын-Эркеш баатыр эмди
Ойгор бичигин алып кычырды,
Оноҥ арыгы јӱрӱмин кӧрди.
Айландыра ончозын кӧрӱп турза,
Ададаҥ бӱдерде, энедеҥ чыгарда,
Кызарып агар каны јок,
Кыйылып ӧлӧр тыны јок
Баатыр болуп бӱткен эмтир.
Эш эдип алар балазы –
Кара-кӱреҥ атту Караты-каанныҥ
Јаҥыс кызы
Байым-Сур деп кыс эмтир.

Козын-Эркеш батыр хәзер
Акыллы китапны алып укыды,

[1] *Пиотровский М.Б.* Ислам и судьба // Понятие судьбы в контексте разных культур / Научный совет по истории мировой культуры. М.: Наука, 1994. С. 96.

Аннан алдагы тормышын күрде.
Әйләндереп бөтенесен күреп торса:
Атадан булганда, анадан туганда ук
Кызарып агар каны юк,
Кыелып үләр тыны юк,
Батыр булган икән.
Ише аның –
Кара-көрән атлы Караты ханның
Ялгыз кызы –
Байым-Сур дигән кыз икән (*автор тәрҗемәсе.*)

Алтай эпосы «Алып-Манаш»ның герое Алып-Манаш та үзенә аталган кыз турында язмышлар китабыннан белә[1]. Алтай халыклары эпосы геройларының язмышлары махсус китапларда да, төрки халыкларның дөнья агачы Бай-тирәк яфрагына языларга да мөмкин. Мәсәлән, «Ак-Бокё улы Кан-Таджи» эпосының герое язмышын белергә теләп, Бай-Тирәк, ягъни Алтын-Чогорга һәм күктә яшәүче Кудайга мөрәҗәгать итә. Тирәк яфрагы язмыш язылган «Сабра-бичик»кә әверелә[2]. «Маадай-Кара» эпосында Маадай-Кара, «Судур» дан укып, үзенең киләше кем буласын һәм үзенең нәрсәләр эшләргә тиешлеген белә. Язмышлар китабыннан карап геройның кайда һәм кайчан тууын, җаны кайда яшерелгән булуын да белергә мөмкин.

Јети кады ай судурды бу кодорды,
Айлаткышту алтын бичик бу кычырды[3].

Җиде катлы ай судурны бу күтәрде,
Акыллы алтын китапны бу укыды.

Төрки халыкларда язу традициясе борынгыдан килә. VIII–IX гасырларга караган Орхон-Енисей эпитафик истәлекләре

[1] Алып-Манаш // Алтай-Бучай, Ойротский народный эпос. Новосибирск, 1941. С. 82–83.

[2] *Никифоров Н.Я.* Аносский сборник. Собрания сказок алтайцев // Записки Западно-Сибирского отделения Русского географического общества. 1915, 37. С. 161.

[3] Маадай-Кара. С. 355.

моның ачык мисалы. Шуңа күрә төрки дастаннарда язу традициясе, «Язмыш китабы» образы килеп керү, очраклы түгел. Алтай эпосында ул «Язмыш китабы», «Ай-Судур» яки «Судур-бичик» дип атала. «Бичик» – борынгы төрки сүз «битиг» сүзеннән, ул «язу», «китап» мәгънәләрен бирә. Хәзерге вакытка кадәр татар фольклорында бу сүз саклана:

Бөте-бөте бөтегән,
Бөте өстендә көтегән,
Кенә суы йөгерткән,
Күк җеп белән каяган[1], –

дигән табышмак бар. Табышмактагы *бөте-бөте* сүзләре *бите* дигәнне, ягъни язуны аңлата. «Судур» – санскрит сүзе – *sutra*-дан (Будда гыйлеменнән) кергән. Бу сүз белән буддизмда эчтәлекле китапларны атаганнар. Шул рәвешле галимнәр эпос сюжетына Судур китабы образы керүен Үзәк Азия диннәре йогынтысы белән бәйләп аңлаталар[2].

Язмышлар китабы уйгур язма истәлеге «Алтын ярук» («Алтын яктылык/нур») китабында да искә алына. Ул «Ан битиг» («Язмыш китабы») дип атала. Әлеге китапта һәр кешенең бөтен тормышы юлы, гомер озынлыгы күрсәтелә, яки аңа бирелгән вакыт искәртелә[3].

Ислам дине киләчәкне юрауларны тыюга карамастан, татар халкында дингә нигезләнгән юрау ысуллары яшәп килгән. Шундыйларның берсе – Коръән ачу. Дини эчтәлекле китаплар ярдәмендә киләчәкне яки язмышны белергә омтылып фал ачу, китап ачу күренеше ислам динендә генә түгел, башка диндәге халыкларда да мәгълүм. Мәсәлән, ул Тибет ламаизмында билгеле була. Дога укыган вакытта китапны баш өстенә күтәреп ачалар. Ачылган биттәге текст ярдәмендә киләчәкне

---

[1] Татар халык табышмаклары / җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. Б. 475.

[2] *Сагалаев А.М.* Мифология и верования алтайцев. Центрально-азиатские влияния. Новосибирск: Наука, 1984. С. 63–64.

[3] *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. Тексты и исследования. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1951. С. 158–155.

юрыйлар[1]. Язмышны шушы рәвешле белергә омтылу күренеше татарларда да XX гасырга кадәр саклана. Бу күренеш Идел буе татарларында «Фал ачу», «Китап ачу», «Коръән ачу» дип атала, Себер татарларында «палтар ачу» исеме белән мәгълүм. Бу максаттан «Коръән» һәм Кол Галинең Болгар чоры әдәбияты истәлеге «Кыйссаи Йосыф» поэмасына мөрәҗәгать итәләр. Бу үзенчәлекле юрауларның кагыйдәләре дә формалаша һәм ул Р. Еквал күрсәткән юрауларга якын[2].

Киләчәкне, язмышны белергә омтылып башкарылган гамәлләрнең тагын берсе – төш күрү – төш юрау. Төрки фольклорда һәм Урта гасырлар әдәбиятында төш мотивы сюжетны оештыручы мотивларның берсе булып, язмыш мотивы белән нык бәйләнештә тора. Төркиләрдәге «төшлек салу» күренеше дә дастаннарда чагылыш тапкан. «Төшлек салу» – киләчәкне, язмышны белергә омтылып төш күрү. Мәсәлән «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастанының «Кузы-Көрпә» дигән вариантында әлеге күренеш тасвирлана. Улының юлында нәрсәләр күрәсен белергә омтылып әнисе «юл төше» күрә:

«Әнисе әйтте:

– Тукта! Мин төш күрим синең китә торган юлыңа!»

Түренә бер ястык ташлады, аңа әнисе ятты. Әнисе йоклап калды. Күп яткач, Кузы-Көрпәч әнисен уятты.

– Яттың озак, – диде, – Минем юлымны кыскартма!

Әнисе торды.

– Ни күрдең, әнием, төштә?

Әнисе әйтте төшәгән төшен:

– Бүгендә яман төш күрдем, балам,
Өем артында байтирәк күрдем, балам,
Өй өстенә егылды, балам,
Ишегем алдында сары елан, балам,
Юлымда сузылып ятты, балам!»[3]

---

[1] *Ekvall R.* Religious Observances in Tibet. Patterns and Function. Chicago. London, 1964. P. 265.

[2] Шунда ук. P. 265.

[3] Татар халык иҗаты. Дастаннар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр.., 1984. Б. 138.

Бу мисалдан «юл төше»нең, ягъни төшлек салуның «заказ белән күрелгән төш» булуы аңлашыла.

Өзектән Кузы-Көрпәчнең юлы уңмаячагы аңлашыла. Әнисе төшен улының үлеменә юрый, байтирәк – дөнья агачы, ягъни нәсел агачы егылу, бу ыруның-гаиләнең киләчәге булмаячагын, нәсел җебе өзеләчәген күрсәтә.

Шул ук вакытта махсус күрелмәгән төш тә киләчәкне, язмышны хәбәр итә. Төш рәвешендә герой үзенең язмышыннан хәбәр ала. Кол Галинең Болгар чорына әдәби ядкаре «Кыйссаи Йосыф» поэмасы да геройның төш күрүе белән башланып китә. Бу әсәрдә төшләр геройларның, хәтта дәүләтнең киләчәген сөйли.

Борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятында һәм төрки фольклорда, язмыштан хәбәр буларак, төш күрү күп әсәрләрдә кабатлана. Һәрберсендә язмышның котылгысыз булуы, кешенең язмышын үзгәртә алмавы, тәкъдир алдында көчсез булуы күрсәтелә.

Мәсәлән, «Аксак Тимер нәселе турындагы дастан» Җодай ханның төш күрүе белән башланып китә. Төш юраучылар:

«Алмалык дигән җирдә Торагай исемле кешенең туачак баласыннан әҗәлең – үлемең булыр», – дип төшне юрыйлар. Җодай хан үлеменнән, ягъни тәкъдирдән качарга омтылып, туачак баланы үтерергә әмер бирә. Дастанда бу эшнең мөмкин булмавын, язмышның котылгысыз булуын күрсәтеп, «Ул ахмак тәкъдирне тәдбир белән бозмак теләде. Хак Тәгаләнең тәкъдире ничек бозылыр», дигән нәтиҗә ясала[1]. Әлеге әсәрдә язмыш мотивы алга таба да котылгысызлык, чарасызлык буларак ачыла. Мәсәлән, Аксак Тимернең Бүләр шәһәрен алуы, халкын кыруы да язмыш дип карала: «Ул Аксак Тимер нишли алыр иде, Тәңренең тәкъдиредер»[2].

Е.Д. Турсунов төштә күргәннәргә нигезләп киләчәкне белергә омтылуның, төшлек салуның якутларда да булуын яза: «Якут ойууннары төрле рәвештә киләчәкне белергә омтыла-

---

[1] Дәфтәре Чыңгынамә / Басмага әзерләүче, сүзлек һәм аңлатмалар авторы Сәлим Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 23.

[2] Шунда ук. Б. 29.

лар. Әгәр кемдер шаманга «туул» (төшеңдә киләчәктә нәрсә буласыны күр) дигән үтенеч белән мөрәҗәгать итсә, ойуун икенче көнне иртән күргән төшен сөйли һәм үзе үк юрый»[1].

Юл төше мотивы төрки халыклар эпосында еш очрый. «Пи таш» дигән Алтай эпосында да анасының улы юлына төш күрүе бәян ителә:

Төнлә, төнлә төш күрдем
Бу йөрәк туктагыр![2]

Фольклорда язмышны белергә омтылып йолдызларга мөрәҗәгать итү дә чагылыш тапкан. Бу борынгыдан килгән юрауның нигезендә түбәндәге ышану ята: борынгылар һәр кешенең үз йолдызы булуга ышаналар. Берәүләрнең йолдызы якты булып, язмышы бәхетле, гомер юлы йолдыз кебек якты эз калдыра. Ул хөрмәткә ия кеше була. Йолдыз кешенең күктәге чагылышы булып, ул сүнгәндә, кеше дә үлә[3]. «Йолдыз сүнү», «Кояшы сүнү» кебек гыйбәрәләр шушы ышануның эзләрен саклый.

Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан» («Егетләргә бүләк») поэмасында да кеше язмышы белән йолдыз арасында параллель уздырыла:

Фәләк ди: «Ярмөмид, тыңла бу – өндер:
Йолдызыңда – үзең хуҗа, хакимдер.
Мин ни эшлим, йолдызыңа сал күзең
Ишетер чөн: йолдыз ни дияр сүзең...»[4]

Шагыйрь аерым кешеләрнең «бәхет йолдызы» белән дус булуын күрсәтә. Бу – бәхетле язмыш дигәнне аңлата:

---

[1] *Турсунов Е.Д.* Древнетюркский фольклор: Истоки и становление. Алматы: Дайк-Пресс, 2001. С. 93.

[2] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы. Ч. 1. С. 215.

[3] *Халидова М.Р.* Мифологический и исторический эпос народов Дагестана. Махачкала: ДНЦ РАН, 1992. С. 91.

[4] *Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 132 (65).

Кемгә бәхет йолдызы дусты булыр,
Ул миһербан илнең олысы булыр[1].

Татар телендә «бәхетле йолдыз астында туган» дигән гыйбарә дә шушы ышануны күрсәтә.

Татар телендәге «Язмыш йомгагы», «Язмышлар бәйләнү», «Язмыш җебе» кебек төшенчәләрдән язмышны эрләнгән җеп, җеп йомгагы итеп күзаллау аңлашыла. Бу күзаллау төрле халыкларның мифологиясендә һәм фольклорда киң чагылыш тапкан. Хетт мифологиясендәге язмыш алиһәләре, грек мифологиясендәге айс, мойралар, рим, скандинав халыклары һ.б. мифологиясендәге эрләүче затлар җеп итеп кешеләргә язмышларын эрлиләр. Н.А.Криничная, рус фольклоры һәм этнографик материалларга нигезләнеп, язмышның универсаль моделен күрсәтә, җеп эрләүче мифик затлар кешеләргә язмышларын, тормышларын җеп итеп эрли, бәйли, тукый һ.б. Галимә рус мифологик хикәятләрендәге эрләүче затлар буларак йорт иясе, йорт хуҗасы, мара, кикимора, русалка, Баба-яга һ.б.ны күрсәтә[2].

Кешеләргә язмыш эрләүче персонажлар татар-төрки фольклорында да күп. Аларның иң беренчесе – убырлы карчык, яки урмандагы ялгыз йортта яшәүче карчык. Бу образ тата тылсымлы әкиятләрендә яши. Урман эчендә ялгыз яшәүче убырлы карчык яки җалмавыз карчык өендә җеп эрли. Юл эзләп, адашып килеп кергән геройга юл күрсәтер өчен, үзе эрләгән җеп йомгагын биреп, аңа шул йомгак артыннан барырга куша. Шул рәвешле герой йомгак, ягъниүзенең язмышы артыннан бара.

Йомгак артыннан язмышы йөрткән геройларның берсе – татар халыкның «Үги кыз» әкиятендәге Үги кыз. Ул адашып калганнан соң, йомгагын эзләп юлга чыга. Ягъни ни эшләргә

---

[1] *Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 133 (65).

[2] *Криничная Н.А.* Нить жизни (Реминисценции образов божеств судьбы в мифологии и фольклоре, обрядах и верованиях). Петрозаводск: Изд-во Петрозаводского университета, 1995.

белми калган вакытта, үзенең язмышын барлый башлый. Һәр очраган кешегә нәрсә эшләргә белмәвен, югалып калуын аңлата, аннан ярдәм сорый: «Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, көтүче (агай, әбекәй)?» Үги кыз – анасыз калган бала, ана – халыкның гасырлар буена тупланган тәҗрибәсе. Үги кызда бу тәҗрибә, халык акылы юк, шуңа күрә ул тормышының җиде юл чатында калган. Әмма кыз үзалдына яшәргә максат куя, яшәү юлын эзли. Беренче булып язмышын эзләгән кыз көтүчегә мөрәҗәгать итә. Көтүче – табигать белән аңнан тыш бәйләнеш, интуицияне аңлата. Икенче булып агайга эндәшә. Агай – бер яктан салкын акыл, икенче яктан көч була ала. Ахырда үги кыз әбекәйгә килә. Әбекәй – халыкның зирәклеге. Һәм кызы, һәрберсе күрсәткән юл белән баргач, ахырда, убырлы карчыкка барып чыга. Аның ярдәмендә үги кыз тормышын һәм язмышын яңарта. Ягъни Убырлы карчык кушкан эшләрне башкарган вакытта ул үзенең тормыш программасын яңадан ача. Ахырда үги кыз баеп, ягъни тормышын бәхетле итеп төзерлек программа белән үзенең өенә кайта[1]. Кызның баеп, исән-имин өенә кайтуы – аның язмышы.

«Сүз тотмас» әкиятендә геройлар тәгәрәгән йомгак артыннан барып үзләренә кәләш табалар. Тәгәрәгән йомгак аларга язмышларын табарга булыша:

«Менә нәрсә, оланнар, ди, мин сезнең өчегезгә дә берәр йомгак бирәм, ди, шул йомгакның очын үзегездә калдырып, йомгагын тәгәрәтеп җибәрегез дә, шуның артыннан барыгыз. Йомгагыгыз кем өенә барып керсә, шуның кызын алырсыз, ди»[2].

Татар мифологиясендә иң популяр образларның берсе – өй иясе/өй анасы/ йорт иясе/ йорт анасы. Ул мифологик хикәятләрдә түбәндәгечә сурәтләнә:

«Өй иясе кай чагында җеп җерли, тик үзен бер дә күреп булмый. Өй иясе кабада җерләп бетерелмәгән түтәм калса гына җерли, ди»[3].

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 2 китап. Б. 215–218.
[2] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 китап. Б. 175.
[3] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 264.

«Өй иясе бу чакта утырган, җерли дә җерли, орчык тавышы бөтен өй эченә ишетелә, үзе бөтенләй киенгән күк-ак, башы озын чәч белән булырга кирәк, бөтенләй томаланган, битен күпме күрәсем килсә дә, күрә алмадым, миңа аркан утырган иде. Шуннан соң минем уянганны сизде булырга кирәк, тиз генә урыныннан торды, орчык-кабасын күтәрде дә, китеп, мич артына кереп югалды»[1].

«Йорт иясе өйдә шулай җеп эрләп утырса, ул өйгә бәхет-муллык тели дигән сүз»[2].

Әлеге мифологик хикәятләр XX гасыр урталарында гына язып алынган. Аларда йорт иясенең җеп эрләүче зат булуы турында мәгълүмат саклана. Җеп эрләп өйгә бәхет-муллык теләве генә күпмедер дәрәҗәдә язмышка мөнәсәбәте булуын күрсәтә. Җеп эрләгәндә җайлы-тыныч тавыш белән эрләсә, өйгә бәхет килгән, зыр-зыр килеп усалланып эрләсә, бу өйгә бәхетсезлек килергә мөмкин.

Татар телендә «язмышлар бәйләнү» башкача «чәчләре чәчкә бәйләнү» дип атала. Бу – никахны аңлата торган гыйбарә. Анда «чәч»нең дә язмышка бәйле булуы аңлашыла. Шул ук вакытта кешенең кемгә өйләнәсе яки кияүгә чыгасы да язмышка язылган була. Алтай эпосы геройлары язмыш китабыннан, беренче чиратта, үзләренең кәләшләре турында беләләр.

«Язмыш сукмагы» дигән гыйбарә дә кешенең язмышын сукмак, юл итеп күзаллаудан килә. Әкиятләрдә геройның өч яки җиде юл чатында калуына һәм берсен сайларга тиеш булуына, күпмедер дәрәҗәдә аның язмышын сайлау мөмкинлеге булуына, язмышының үз кулында булуына да ишарә ителә. Әкият герое убырлы карчык күрсәткән сукмаклар белән бара, яки үзе берничәгә аерылган юлның берсен сайлый.

Мәсәлән «Кош эзләп йөргән хан улы», дигән әкияттә, өч егет өчесе өч юлны сайлый. Һәрберсенең үз язмышы – үз юлы була. «Өч ул чыгып китте бер юл белән. Бара-бара юл өстендә торган бер баганага барып җиттеләр. Бу баганадан өч юл аерылды. Баганага: «Уңга киткән кеше – бик бай булыр, урта юл

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 265.

[2] Шунда ук. Б. 266.

белән киткән кеше – урта бай булыр, сулга киткән кеше әйләнеп кайтмас», – дип язылган.

Өлкән улы әйтте:

– Мин сезнең өлкәнегез, мин уңга китим, – диде.

Уртанчы улы әйтте:

– Мин уртанчы улмын, миңа урта юл да ярый, – диде.

Кече улы әйтте:

– Ходай әмереннән чыгып булмас, шулай булгач, мин сулга китим, – диде»[1].

Бу өзектә юлның язмыш булуы һәм аны үзгәртергә мөмкин булмау аңлашыла. «Унберенче Әхмәт» дигән әкияттә дә герой юл чатында кала. Аның да уңга яки сулга китәргә – юлны үзе сайларга мөмкинлеге бар. Бу – кешенең язмышы алдында көчсез булса да, сайлау мөмкинлеге барлыгын күрсәтә. Геройга «уңга керсәң, уңарсың, сул якка керсәң, бик зур авырлыкларга очрарсың», – дип, киңәш бирелә[2].

Ислам кануннары буенча да кешенең, тәкъдире маңгаена язылуга карамастан, үзенә юл сайларга мөмкинлеге бар. Кеше аңлы рәвештә үз юлын сайлап ала. Бу – кешенең язмышы күпмедер дәрәҗәдә үз ихтыярында булуны күрсәтә.

Борынгы һәм Урта гасырлар төрки-татар әдәбиятында һәм фольклорында, язмыш белән бәйле мотивлар аша, күктән, Аллаһ тарафыннан бирелгән язмышның котылгысыз булуы исбатлана. Кеше үзенең язмышы белән ризалашырга тиеш.

Мөхәммәдъярның «Төхфәи Мәрдан» поэмасында да сүз шул турында бара.

Тәкъдирендә ни язган булса Хода,
Аңа кирәк кол үзе булса риза,
Өлешеңне сиңа бит Ул җиткерер,
Алсаң һәм алмасаң да, сиңа бирер[3].

---

[1] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 китап. Б. 179–180.

[2] Шунда ук. Б. 284 .

[3] *Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 132 (65).

Мөхәммәдъярның поэмасында, тәкъдир мотивына иллюстрация буларак, «Бүре һәм падишаһ кызы турында хикәят» бирелгән[1].

Хикәятнең кызыклы ягы шунда, әсәрдә язмышны язып торучы затлар образы тасвирлана. Бер Падишаһ кичен яктылык күреп, анда юнәлә. Анда хатын-кызлар олы бәйрәм ясыйлар. Араларында ике зат утырган. Аларны падишаһтан башка бер кеше дә күрми.

Кемдер икәү утырган болар ара,
Кулларына алганнар каләм-кара.
Шаһ күрә, тик һич кеше күрмәс моны,
Бу – гаҗәп сер, һич кеше белмәс моны.
Шаһ боларны әле күрә, әле юк,
Әле чагыла күзенә, әле юк.
Шаһ аларның эшеннән нык шүрләде,
Шикле хәлдән башка берни күрмәде.
«Хода хакы өчен! – диде аларга, –
Әйтегез кемнәр дип сезне аңларга?
Тәэсир бигән әйтте: Без беткүчемез,
Тәңре ни сурса, аны әйткүчемез»[2]

Язмыш ияләре үзләрен «беткүчеләр», ягъни «язучылар» дип атыйлар, һәм вазифаларын «Тәңре сурганны әйтү», ягъни Тәңре биргәнне әйтү, дип аңлаталар. Язмышны язучылар әсәрдә очраклы образлар түгел. Алар йорт хуҗасының гүзәл кызының язмышыннан хәбәр бирәләр:

Кайчан бу кыз ундүрт йәшкә җитәр, ди,
Шулчак аны бүре ашап китәр, ди[3].

Шаһ кызының язмышын үзгәртергә теләп, кызын бикләр өчен сарай салдыра. Сарайга бер кеше дә керерлек булмый. Бер еллык азык, су куеп кызны сарайга биклиләр. Ялгызлыктан күңелсезләнмәсен, дип, янына бер кыз кертәләр. Кыз Шаһ кызының серен, ни өчен сарайга бикләнүен сорый.

---

[1] *Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 126–131 (58–63).

[2] Шунда ук. Б. 127 (59).

[3] Шунда ук. Б. 127 (60).

Тәкъдиремә Илаһ язып куйган, ди.
Ундүрт яшьтә бүре ашар дигән, ди[1].

Шаһ кызы, шул рәвешле үзенең язмышыннан хәбәрдар була. Кыз, бу серне белгән, Аллаһыдан үзен бүре итүен сорый:

Ул кыз диде: «И сер белән падишаһ, –
Мине бүре итсәң, ни булыр, Илаһ?
Ихлас белән кылынды кыз догасы,
Аны кабул итеп алды Ходасы.
Бүре булып ашады ул Шаһ кызын, –
Китте кызый, калдырып, ул кан эзен[2].

Шаһ шул рәвешле язмыштан качып булмасын аңлап, тәүбә кыла.

Язмыш, өлеш, тәкъдир кешегә яшәү өчен бирелгән вакытны, гомер озынлыгын да күз алдында тота. Кеше үзенә бирелгән вакытны белергә омтылып, төрлечә юрап карый. Шундый юрауларның берсе – гомер озынлыгын белергә теләп күке кычкырганда аңа үзенең калган гомере турында сорау бирү һәм күке кычкырганын санау. Беренче карашка бик гади тоелган әлеге юрауның башка төрки халыкларда да булуы мәгълүм. Борынгы Себер төркиләре, Алтай халыклары фольклорында Изге күке – язмышны белә торган образ. «Мадай-Кара» эпосында да күкеләрнең шушы роле тасвирлана[3].

Күкеләр кешенең гомер озынлыгын билгеләсә, башка кошлар язмыш хәбәрчесе – үлем яки бәхет хәбәрчесе булырга мөмкин. Мәсәлән, «Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу» дастаның казак версиясендә ханнарның башларына кунган кара сыерчык – үлем хәбәрчесе. Ул Сарыбайның гомере бетүен хәбәр итә[4].

---

[1] *Мөхәммәдъяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 130.

[2] Шунда ук. Б. 130.

[3] Шунда ук. Б. 130.

[4] *Баранов Е.* Козу-Курпеч и Баян-Слу (Киргизское народное предание) // Ежемесячные литературные приложения к журналу «Нива»на 1899 г. СПб., 1899. С. 318.

Төрки халыкларда Иран мифологиясе аша кергән Хомай кошы образы да мәгълүм. Иран мифологиясендә Хомай (Хумай) кешеләргә бәхет бирүче кош. Әгәр берәр кеше Хомай кошының күләгәсендә калса, ул кеше бәхетле була. Төрки халыклар ышануларына да әлеге мифик кош бәхет кошы буларак кергән. Шушы ук функцияне башкарып, алда торган бәхетне хәбәр итә торган икенче кош – дәүләт кошы дип атала. Төрки фольклорда сакланган ышанулар буенча ул тәхеткә утырырга тиешле кешенең иңбашына яки башына куна. Бу образ «Идегәй» дастанына кергән:

Куш канатлы алтын таҗ,
Күз урыныда гәүһәр каш,
Чыңгыздан килгән дәүләт кош[1].

Татар халкында кошларның үз-үзләрен тотышына, тавышларына карап юрау шактый таралган. Шундый фалнамәләрнең берсе «Козгын фалы» дип атала. Аны борынгы кулъязмалардан алып фәнни әйтелешкә керткән М. Әхмәтҗанов «Нугайлардан кергән мирас», – дип саный[2]. Тексттан козгынның үз-үзен тотышына, кычкыруына карап нәрсә булачагы, кешеләргә нәрсәгә әзер торырга кирәклеге бәян ителгән.

Дөньяның барлык халыкларында да, язмыш котылгысыз булуны кабул итсәләр дә, аны үзгәртергә яки язмышның бәхетле булуын тәэмин итәргә омтылып башкарыла торган йолалар бар. Алар бала туган көннән башланып, кешене соңгы юлга озатканга кадәр дәвам итә. Бала битлек белән туса, бәхетле була, дигән ышану бар. Бала бәхетле булсын, аңа зыян сала алмасыннар өчен баланың битлеге белән төрле йолалар башкарылырга мөмкин. Мәсәлән, аны кеше йөрми торган җиргә күмү яки саклау.

Төрки халыклар балага исем сайлауга да җитди карыйлар, исем аша баланың гомерле, бәхетле булуын тәэмин итәргә

[1] Төш юрау китабы / текстын туплаучы фәнни эшкәртүче, искәрмәләр авторы һәм җыючы Марсель Әхмәтҗанов. Казан: Татар «Мирас» фонды. 1991. Б. 15.

[2] Идегәй. Казан, 1988. Б. 17.

омтылыш ясала. Мәсәлән, Алтай төркиләре балага исем сайлаганда, аны авыру-бәхетсезлекләрдән яклар өчен «начар» исем бирергә мөмкин. «Чтобы уберечь новорожденного от болезней и бед ему давали заведомо плохое, неблагозвучное, «обманное» имя. Считалось, что, произнося его, глава нижнего мира Эрлик не остановит своего внимания на малыше и ему будет сохранена жизнь»[1]. Татарларда балалары үлеп торган гаиләләрдә яңа туган балага гомер теләп, «Үлмәс», «Туктар» кебек исемнәр кушу XX йөзләргә кадәр очрый. Начар исеме чыккан, халык арасында хөрмәте булмаган кешеләрнең исемен бирүдән дә сакланалар.

Бу – исем белән кешенең киләчәген, язмышын бозудан саклану, тискәре сыйфатларга ия кешенең язмышы балага күчүдән курку белән аңлатыла. Балага бирелгән исем аңарда шул исемдәге сыйфатлар булуын теләүне күрсәтә. Татарларда кызларга бирелгән «Гүзәл», «Айсылу» кебек исемнәр аларның чибәр, сөйкемле булуып теләүне аңлатса, ир балаларга «Булат», «Тимер» («Тимур»), «Алмаз» кебек исемнәр бирү, аларның киләчәктә нык, көчле булуын теләүне күрсәтә.

Димәк, язмыш – кешенең үзе туганчы ук билгеләнгән тормыш юлы, гомеренең төп моментлары, бәхетле-бәхетсез булуы, аңа бирелгән вакыт. Төрки фольклорда язмыш алдан язып куелган программа буларак сурәтләнә. Бер яктан, аны үзгәртеп тә булмый. Әмма кешенең «уңга – сулга» киткәндә сайлау мөмкинлеге бар. Яхшы яки яман юлны, үзенең язмышын күпмедер дәрәҗәдә ул үзе сайлый. Фольклорда кешеләрнең язмышларын үзгәртергә яки алдан белергә омтылулары чагыла. Төрки, шул исәптән татар фольклорында да язмыш аллаларының трансформацияләнгән образлары, җеп эрләүчеләр, карчык образлары сакланган. Шулай да язмышның акыл, тәҗрибә, зирәклек, интуиция белән яшәүне инкарь итмәвен онытырга ярамый.

---

[1] Традиционное мирвоззрение тюрков Южной Сибири. Человек. Общество. Новосибирск: Наука. 1989. С. 170.

**СУ ИЯСЕЗ БУЛМЫЙ**

(Төрки-татар фольклорында су һәм су ияләре белән бәйле мифологик мотивлар)

Кайсы гына халыкның мифологиясен алып карасак та, су – яшәешнең башында торган берәмлек. Төрки халыкның мифологиясендә дә дөнья яки җирнең су яки дәрья төбеннән чыккан туфрактан яратылуы бәян ителә[1]. Шул рәвешле су беренчел хаосның эквиваленты булып тора, аның туу, яңару белән бәйле стихия булуы аңлашыла.

Төрки халыклар *су* сүзен җир белән янәшә куеп, «җир-су» дип сөйлиләр, ул туган җирне, Ватанны аңлата, фольклорда да туган җирнең метафорасы булып тора, изге төшенчәләрдән санала.

Бер яктан, тормышның башында торган стихия булуы, икенче яктан, туган җирне аңлаткан төшенчә белән бәйле булуы суның «дөнья мифологиясенең иң борынгы, популяр, көч-куәте чикләнмәгән универсаль категориясе буларак гәүдәләнүенә»[2] китерә.

Аларны шартлы рәвештә ике төркемгә аерырга мөмкин: суның үзен сакральләштерү һәм су ияләре – су хуҗалары образлары белән бәйле мотивлар. Еш кына су яки сулыкны сакральләштерү су иясе образын олылау белән кушылып та китә.

Су белән бәйле йолалар, нигездә, суны сакральләштерүгә, ягъни суның сихри, гайре табигый көчен тануга кайтып кала. Бу мотив татар халкының борынгы ышануларыннан килә һәм безнең көннәрдә дә яшәвен дәвам итә.

---

[1] *Катанов Н.Ф.* Качинская история о сотворении мира // ИОАИЭ. 1884. 1. XII. вып. 2. С. 185; Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. Казань: Таткнигоиздат, 1990. С. 47.

[2] *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 2 т., Казан, 2009. Б. 339.

Дөнья халыкларының күбесенә мәгълүм тере һәм үле сулары турындагы ышану татар фольклорында да чагылыш тапкан.

Тере суны икенче төрле тереклек суы, мәңгелек суы һәм әбелхәят дип атыйлар. Легендалар буенча, әбелхәят суын эчкән кеше үлемсезгә әйләнә, ягъни ахырзаманга кадәр яши. Ә тере суы үлгән кешене дә терелтү сәләтенә ия.

Мәңгелек су эзләү турында эпизод «Коръәндә» дә бар. Каф сүрәсендә Муса пәйгамбәрнең хезмәтчесе белән ике диңгез кушылган җирне эзләп юлга чыгуы тасвирлана: «Әлбәттә, туктамыйча китәрмен ике диңгезнең кушылган җиренә барып җиткәнче, яки туктамыйча озын заман китәрмен»[1]. Муса пәйгамбәрнең юлга чыгуының сәбәбе – Хозер г-мне эзләп табу. Муса пәйгамбәр хезмәтчесе белән ике диңгез кушылган җиргә җиткәч, анда кипкән балыкларын онытып калдыралар. Кипкән балыклар терелеп, суны ярып, диңгезгә кереп китә. М.Б. Пиотровский бу эпизодны тере су белән бәйләп аңлата: «Её коснулась живая вода, но этого в тексте не сказано»[2]. Галим ике диңгезне Тигр һәм Евфрат елгалары белән бәйләп карый һәм әлеге сюжетның борынгы чыганакларын да күрсәтә: «Истоки этого сюжета много древнее чем Роман об Александре. Коран сохранил память и об этих, древнейших связах сюжета. «Место слияния двух морей», где происходит кораническое действие, – это там, где Тигр и Евфрат (пресное море), соединившись, вливаются в Персидский залив (соленое море). Там же, в районе Бахрейна, подземные реки Аравии выходят в море, создавая на дне его пресные родники. В эти места (на Бахрейне, древнем Дильмуне) древние месопотамицы помещали рай, место вечной жизни. В этих местах происходило действие многих древних сказаний о поисках источника вечной жизни»[3].

Бу сюжет Көнчыгыш халыкларында Александр Македонский исеме белән бәйле рәвештә бәян ителә.

---

[1] Коръән, 18: 60.

[2] *Пиотровский М.Б.* Коранические сказания. М.: Наука, 1991. С. 105.

[3] Шунда ук. С. 111.

Александр Македонскийның мәңгелек су эзләве Көнчыгыш халыклары фольклорында һәм әдәбиятында чагылыш тапкан. Низами Ганҗәвинең «Искәндәрнамә» поэмасында Александр Македонскийның кешеләргә үлемсезлек бирергә сәләтле мәңгелек су эзләп юлга чыгуы бәян ителә[1]. Искәндәрнең тере су эзләве төрки халыкларның фольклорына һәм әдәбиятына килеп кереп, шактый гына әсәрләрдә кабатлана. Мәсәлән, әлеге сюжет Насреддин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» дигән китабында да бар. Бу әсәрдә Александр Македонскийның тереклек чишмәсен эзләве бәян ителә: «Көннәрдән бер көнне патша үзенең дус фәрештәсенә әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә камил коллык кылу өчен мин озын гомер телимен». Фәрештә әйтте: «Әгәр озын гомер теләсәң, җирнең төньягында караңгылыкта бер чишмә бар. Шул чишмәнең суын эчкән кеше ахырзаманга кадәр яшәр» – диде. Зөлкарнәен тереклек чишмәсен эзләде. Әмма насыйп булмады[2]. Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихы Болгария» әсәрендә дә Сократ хаким белән Искәндәрнең тормыш суы эзләп төньякка китүләре искә алына[3]. Насреддин Рабгузи тереклек чишмәсен кем табуын да хәбәр итә: «Хозер г-мгә насыйп булып, ул чишмәдән эчте»[4]. Дини риваятьләрдә Хозер г-мнең мәңгелек суын эчкән бердәнбер кеше һәм үлемсезлеккә ирешкән пәйгамбәр булуы сурәтләнә.

Искәндәрнең тереклек суын эзләве хакындагы эпизод Баһавиның «Бүз егет» дастанына да керә:

Җаны үлемгә йиткәндә,
Йирнең йөзе бозылып,
Көннең күзе тотылып,
Мәңге суны табалмай
Егерме дүрт яшендә
Искәндәр үткән дөньядан[5].

---

[1] *Низами*. Поэмы и стихотворения. Л., 1969.

[2] *Рабгузи Насретдин.* Кыйссасел Әнбия. Казан, 2003. Б. 285.

[3] *Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. С. 161.

[4] *Рабгузи Насретдин.* Кыйссасел Әнбия Б. 285.

[5] Татар халык иҗаты. Дастаннар. 1984. Б. 327.

Риваятьләрдә атаклы басып алучыларның ярты дөньяны басып алуларының мәгънәсе үлемсезлек чарасы эзләүгә кайтарып калдырыла. Александр Македонский кебек үк, Чыңгыз ханның да үлемсезлек эликсиры, ягъни мәңгелек суы эзләве турында риваять бар. Чыңгыз хан бөек даос Чан Чунь белән очраша. Дөнья мәшәкатләреннән читтә торган даосны үлемсезлек эликсиры тапкан дип белгән бөек хан сүзне нәкъ үзен кызыксындырган сораудан башлый: «Святой человек, какой эликсир бессмертия привез ты для меня из своей далекой страны?» «Я знаю много средств, чтобы защитить жизнь, но ни одного, чтобы дать бессмертие», – очень мудро ответил китайский монах»[1].

Татар халкында кешенең бу дөньяда вакытлы булуын аңлаткан: «Беркем дә мәңге суы эчмәгән», – дигән мәкаль дә бар.

Мәңгелек суы турындагы ышану әкиятләрдә дә шактый очрый. «Алтын Алма» дигән әкияттә тере суының авыруларны, үлемне терелтү сәләтенә ия булуы тасвирлана. Герой берсеннән – тере, икенчесеннән үле суы агып торган ике чишмә таба. Тере суны күзләренә тидергән сукыр карт күрә башлый, агачка әверелдергән гаскәр терелеп кеше була[2]. «Аучы» дигән әкияттә тере суы чишмәсе турындагы эпизод үзгәреп, зур сулык буларак сурәтләнә. Үлгән кешене анда алып барып югач та, ул яңадан терелә[3]. «Аучы егет һәм җәнлекләр» дигән әкияттә дә үле һәм тере сулары ярдәмендә үлгән кешене терелтү турында сүз бара: «...әүвәле хуҗага үле суын сипте, аннары тере суны сипте. Теге терелеп сикереп торып утырды»[4]. «Яшьлек суы» дигән әкияттә дә үле һәм тере сулары турында сүз бара. Татар әкиятләрендә бу ике су берьюлы кулланыла, димәк геройны ике су ярдәмендә генә терелтеп була.

«Кузы Көрпәч белән Баян-Сылу» дастанының Алтай версиясендә дә Байым-Сур, Козын-Эркешне терелтү өчен, тере су –

[1] *Лунквист А.* Воля неба. М., 2003; *Мишель Хоанг.* Чингисхан. Ростов-на-Дону: Феникс, 1997. С. 311.

[2] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 китап. Б. 232–233.

[3] Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 2 китап. Б. 56.

[4] Шунда ук. 2 китап. Б. 64.

кутук су китерә. Байым-Сур кутук су алып Козын-Эркешнең сөякләрен юа:

Козын-Эркештинг канча сööгин
Орды-ордына јууп ийди,
Аржан суула јунуп ийди [1]

Козын-Эркешнең бөтен сөяген
Урынын урынына куеп җыйды,
Тере суы белән юып җыйды.

Алтай телендәге *кутук суны* җан суы дип аңларга мөмкин. *Кот/кут* сүзенең җан яки рух мәгънәсе дә бар.

Башкорт халкының «Урал батыр» эпосында да мәңгелек чишмәсе тасвирлана. Әлеге кобаерда үлемсезлек бирүче мәңгелек чишмәсе җанчишмә дип атала.

...Был дөньяла үлмәскә,
Кора ергә кермәскә –
Минем илдә булмаган,
Үзен берәү күрмәгән,
Дейеү батша биләгән
Йәншишмәнең һыуы бар...[2].

Әкиятләрдә геройны терелтер өчен тере һәм үле суларының сихри көче ярдәмгә килсә, аларга дию яки аждаһа белән көч алышыр өчен «хәл кертә торган» суны эчү дә җитә. Бу су да ике төрле, берсе «хәл кертә торган су», икенчесе «хәлне бетерә торган су». Моңа мисал итеп, «Таңбатыр» әкиятен күрсәтергә була: «Менә монда ике мичкә бар, аның берсендә көч кертә торган су, икенчесендә хәл бетерә торган су, ди»[3]. «Ике туган» дигән әкияттә дә герой көч бирә торган су ярдәмендә мәсьәләне хәл итә: «Кем дә кем бу савыттан суны эчсә, эчкән кешегә бөтен дөнья халкы каршы торса да җиңә алмый»[4].

[1] *Улагашев Н.У.* Алтай-Бучай. Ойротский народный эпос. С. 231.
[2] Башкирский народный эпос. С. 108.
[3] Әкиятләр. 1 кит. Б. 248.
[4] Әкиятләр. 2 кит. Б. 81.

В.Я. Пропп әкиятләрдәге тере һәм үле су образларының килеп чыгуын грек мифологиясе белән бәйләп аңлата. Борынгы грекларның җир астындагы Аид дөньясында ике чишмә булган. Чишмәләрнең берсе – уң якта, икенчесе сул кул якта урнашкан. Үлгән кеше сакчылар саклап торган чишмәнең суын эчәргә тиеш булганнар. В.Я. Пропп әлеге су турында: «Какая же это вода? В тексте она не названа ни живой, ни мертвой. Но она – благо для умершего, вода для мертвецов или, иначе говоря, вода «мертвая». Можно предположить, что эта вода успокаивает умершего, т.е. дает ему окончательную смерть или право на пребывание в области Аида»[1], дигән фикердә тора. Галим, бу су үле су булса, икенчесе тере су булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килә һәм үзенең фикерләрен раслар өчен яңадан мифологиягә мөрәҗәгать итә: «По некоторым параллелям можно предположить, что это – «вода жизни», вода для мертвецов, не входящих в Аид, а возвращающихся из него. До входа в Аид она не имеет никакого действия, поэтому она и не охраняется. Это явствует из вавилонского катабазиса богини Иштар. Как говорит Иеремиас, «она отпускается обратно после того как привратник вынужденным образом вспрыскивает ее водой жизни. Если высказывание здесь предположение верны, то это объясняет, почему героя сперва опрыскивает мертвой водой, а потом живой. Только теперь, после окропления мертвой водой эта живая вода будет действовать»[2]. В.Я. Пропп үле һәм тере суларның бер-берсен тулыландырып торуына, берсенең генә ярдәм итмәячәгенә игътибар итә, аларның авыруларны дәвалаучы судан аерылып торуын, икесенең ике төрле су булуын күрсәтә.

Аерым чишмә, күл суларының хәл кертү, дәва үзлегенә ия булулары турында ышанулар татар халкында хәзергә кадәр бар. Халык аерым чишмә суларының сихри көчкә ия булуына ышана. Татар халкында изгеләр чишмәләренә бару, аның суын дәвага куллану күренеше бар. Бу очракта сүз үзенең минерал

---

[1] *Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки. Л., 1946.
[2] Шунда ук. С. 180.

составы белән шифалы саналган сулар турында бармый. Чишмәләрне изгеләштерү, кагыйдә буларак, берәр риваять белән канунлаштырыла. Шундый чишмәләрдән Болгар чорына караган Болгар һәм Биләр (Бүләр) шәһәрләре территориясенә кергән изгеләр чишмәсен һәм суы дәвалау үзлегенә ия саналган Габдрахман коесын мисалга китерергә була. Изгеләр чишмәсенең килеп чыгуы, кагыйдә буларак, берәр изге кешенең исеме белән, аның үлеме белән бәйле. Яки Биләрдәге Изгеләр чишмәсе кебек ил күләмендәге зур тарихи вакыйгалар белән бәйле рәвештә сакральләштерелә: «Бүләр шәһәрен дошман явыннан саклаган Тырышмал хуҗаны һәм аның унике кызын дошманнары Хуҗалар тавына китерә. Монда алар дошман кушуы буенча, яланаяк килеш көне-төне туфрак ташып, яңа бер тау өйгәннәр. Дошманнар, биек тау өелеп беткәч, Хуҗаны һәм аның кызларын шул тау башына тереләй җиргә күммәкче булганнар. Шулчак кызлар унике йолдыз булып күккә күтәрелгәннәр, ә Тырышмал Хуҗа таудан сикереп, елга суына әйләнеп, агып киткән. Халык хәзер дә шул елга башланган чишмәне изге санап, аңа адарына, ә кызлар өйгән тауны «Кыз тавы» дип атый»[1]. Әлеге чишмә хәзерге вакытта республикада яшәүче руслар, татарлар, чувашлар һ.б. халыкларның барып йөрү урыны. Өлкән яшьтәгеләр биредә корбан суеп, дога укыр өчен барса, яшьләр өчен ул – тарихның җанлы шаһите.

Күп кенә изге чишмәләрнең риваяте нәкъ менә болгар чоры белән бәйле. Яки алар борынгы кала территориясендә урнашкан. Болгар чоры риваятьләрендә дошман яуларына каршы көрәшкән ил батырлары, яки сәхабәләр исеме белән бәйле кое-чишмә тарихлары бәян ителә. Болгар шәһәре территориясендәге Габдрахман коесы Болгарга килгән ислам миссионеры Габдрахман сәхабә исеме белән бәйле[2]. Бу кое «Шәһри Болгар бәетләре»ндә дә телгә алына:

Габдрахман коесыннан дәвага су алалар,
Габдрахман тау башына нәзер корбан чалалар.

---

[1] Риваятьләр һәм легендалар. Б. 38.
[2] Шунда ук. Б. 25.

Габдрахман коесының төбе тирән, суы күп,
Габдрахман сәхабәнең исеме калган, үзе юк[1].

Татарстан территориясендә аерым чишмә сулары бөтен чирләрдән дәва саналса, кайберләрен билгеле бер авыруга гына шифа бирә дип уйлыйлар. Мәсәлән, күз юар өчен «Күз чишмәсе»ннән су алалар.

Изгеләр чишмәләре белән бәйле риваятьләрнең бер төре аларның килеп чыгышларын сакральләштерсә, икенче төр риваятьләрдә, ул чишмә сулары ярдәмендә шифа тапкан кешеләр, суның сихри шифалы көченә ышаналар. Әлеге төр риваятьләр һәрбер чишмә турында бар, алар хәзерге вакытта да иҗат ителә. Шул ук вакытта татар халкының һәрбер сулыкка игътибарлы булуы да мәгълүм. Сулыкларның чисталыгын саклау саваплы эш санала. Һәм, киресенчә, еш кына авыру-сырхауларның килеп чыгуын сулыкларны пычрату, чишмәләрне корыту белән бәйләп гыйбрәтле хикәяләр сөйләнә.

Татар халкында суның сихри көченә ышану белән бәйле таң суы алу традициясе бар. Бөтен шартлары үтәп алынган «таң суы» кешеләрнең күп чирләрен юып алу көченә ия санала.

Ислам дине тоткан бөтен халыклар өчен Гарәбстанның Мәккә шәһәрендәге зәм-зәм суы аерым хөрмәткә ия. Бу су кешеләрне дәвалап кына калмый, рухи яктан да сафландыра. Дини риваятьләр буенча, зәм-зәм суы җәннәттән чыга. Коръән аша таралган легендалар әлеге чишмәне Исмәгыйль пәйгамбәр исеме белән бәйли.

Изгеләр чишмәләре, елгалар һәм күлләр буенда төрле йолалар уздырыла. Шундый йолаларның берсе – су буенда яңгыр сорап корбан сую, яңгыр боткасы пешерү. Бу йола борынгы чорда су иясенең күңелен күрергә юнәлтелгән йолалардан булган.

Су аллалары, су ияләре бик борынгыдан килгән мифик образлар. Бу образлар дөньяның күпчелек халыкларында мәгълүм. Борынгы греклар диңгез алласы Посейдонны олылаганнар. Борынгы римлыларның диңгез алласы – Нептун. Ул аларда пантеонның иң югары баскычларын биләүче аллалардан

[1] Бәетләр. Б. 24–25.

саналган. Рим халкы 23 июльдә Нептун хөрмәтенә нептуналия бәйрәме уздырган. Алар Нептуннан корылыктан саклавын сораганнар[1].

Борынгы төрки халыкларның да Җир-Су дигән аллалары булган. Изге Җир-су алласы, ягъни «Ыдук Йири-Субы» дигән Тәңренең исеме VIII гасырга нисбәт ителгән Күл-Тәгин истәлегенә куелган ташъязмада сакланган:

Үзә түрк тәңриси
Түрк ыдук йири субы анча тимис:
Түрк будун йок болмазун тийин
Бодун болсун, тийин[2].

Төркиләрнең тәңресе –
Төркиләрнең изге җире-суы болай дигән:
Төрки халык юк булмасын, ди,
Халык булсын, ди (*автор тәрҗемәсе*).

Вакытлар узу белән, мәҗүсилекнең диңгез, су аллалары сулыкларның ияләре, хуҗалары белән алмаштырыла. Кешеләр һәр сулыкның үз иясе, хуҗасы бар дип ышаналар.

Татар мифологиясенең иң популяр су иясе – ул Су анасы. Татар халкының мифологик хикәятләре буенча ул елга, күлләрдә яши. Татар халкында «Иясез су юк» дигән ышану бар. Мифларда Су анасы матур хатын-кыз итеп сурәтләнә: «Су кызы бик матур, үзе сагышлы булган. Озын чәчләреннән су агып тора икән»[3]. Киресенчә, ул шыксыз итеп тә сурәтләнергә мөмкин: «Аның гәүдәсе кеше гәүдәсенә охшаса да бик үк зифа түгел: толымы җиргә җиткән – бик озын, башы бик зур, озынча, күзләре бик зур, тум кара, атылып чыгып тора, күкрәге дә бик киң алга калкып тора, тәне бакырсыман кызыл була»[4].

Болгар чорында да Су анасын чибәр хатын-кыз итеп күзаллаулары мәгълүм. Дөрес, ул Болгар җирендә түгел, ә кай-

---

[1] Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. I. II. С. 211.

[2] *Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. С. 29.

[3] Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы. С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 284.

[4] Шунда ук. Б. 285.

дадыр еракта – Йура җирендә яшәүче зат итеп сурәтләнә. Болгар чорының Су анасы турындагы күзаллаулар Әбү Хәмид әл-Гарнати сәяхәтнәмәсендә урын алган: «...И изнутри его вышла девушка, похожая на потолков Адама: белая, краснотелая, черноволосая, толстозадая, прекраснейшая из женщин. И взяли ее жители Йура и привезли на сушу, и это сушество стало бить себя по лицу, и рвать волосы, и вопить. А Аллах сотворил ей в ее средней части, от пояса до колен, нечто вроде белой кожи, похожую на крепкую плотную ткань, покрывающее ее срам, будто изар обвязанный вокруг пояса и прикрывающий ее срам»[1]. Әл-Гарнати Су кызы турындагы легенданы чынбарлыктагы хәл буларак тасвирлый, аның үз стихиясеннән – судан аерылганнан соң озак яшәмәвен, җирдә үлүен яза[2].

Риваятьләрдә Су анасының аерылгысыз атрибуты итеп аның алтын тарагы күрсәтелә. Ул ярга яки басмага чыгып утырып чәчен тарый, куркып, алтын тарагын онытып калдырырга да мөмкин. В.Я. Пропп, төрле халыкларның фольклорын тикшереп, түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Все, что окрашено в золотой цвет, этим самым выдает свою принадлежность к иному царству. Золотая окраска есть печать иного царства»[3].

Татар халкының Су анасы турындагы күпсанлы мифологик хикәятләренә нигезләнеп Г. Тукай «Су анасы» поэмасын яза. Шагыйрь иҗатында Су анасы түбәндәгечә сурәтләнә:

> Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмага,
> Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
> Шул тарак белән утыра тузгыган сачен тарап[4].

Татар мифларында Су анасы белән беррәттән, су ияләре буларак, Су бабасы, Су атасы, Су иясе яки хуҗасы, Су кызы, Су

---

[1] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную Центральную Европу (1131–1153 гг.) / публикация О.Г. Большакова, А.Х. Монгайта. М.: Гл. раз. вост. лит., 1971. С. 34.

[2] Шунда ук. С. 34.

[3] *Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки. Л., 1946. С. 264.

[4] *Тукай Габдулла.* Әсәрләр: биш томда. 1 т. Шигырьләр, поэмалар (1901–1908). Казан, 1985. Б. 283.

ирәне дә күрсәтелә. Кайбер мифларда аларны бер гаилә итеп тә сурәтлиләр. Сулыкларның төп хуҗасы – Су бабасы, Су анасы – аның хатыны, Су иясе – уллары. Су анасы төн уртасында басмага чыгып улларын юа. «Су бабасы бар тирә-як суларның иң тирәнендә генә торып, шул тирәдәге суларның барысына да боерык таратып тора. Ул инде бик картайган, бүтән су ияләре аны олылап, ни кушса, шуны эшләргә көтеп кенә торалар. Ул бик кирәк чагында гына, бик зур йомышларда гына эшләр карый, боерыклар чыгара». «Су иясе нинди генә су булмасын, шунда тора. Бабасына бер генә дә охшамаган: ул аз гына җүләрсымак итеп эш эшли. Тегермән буаларын ерып җибәрә, балыкчылардан балыкны куа кешеләрне, терлекләрне тотып су астына тарта да, шунда буып үтерә»[1].

Татар һәм башкорт фольклорында Су ияләренең исемнәре дә бар:

Су анасы – Сылубикә,
Су атасы – Сөләйман, –

диеп аларга мөрәҗәгать итәләр[2].

Татарлар дога кылганда «Су атасы Сөләйман, су анасы Сылубикә хакы-хөрмәте өчен» дип дога колалар. Бу мәҗүсилекнең ислам дине белән керешеп китүен күрсәткән бер мисал булып тора.

Татар халкы төрле ияләрнең җеннәр яки шайттаннардан килеп чыгуына ышана. Мифологик ышану тексты су аналарының шайтаннардан килеп чыгуын, аларның кара көчләргә каравын күрсәтә: «Яшен аткан шайтан урманга төшсә – убыр, җиргә төшсә албасты була, суга төшсә Су анасына әверелә»[3].

Бу турыда рус халкының легендасы да бар: « Был на земле только Бог и дьявол. Бог сотворил человека – и дьявол попробовал сотворить, но сотворил не человека, а черта, и как он ни старался, ни трудился, все же не мог сотворить человека, все у него выходили черти. Бог увидил, что дьявол уже сотворил несколько чертей, рассердился на дьявола и велел Архангелу

---

[1] Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. Б. 283–284.
[2] Татар мифлары. 1 том. Б. 127.
[3] Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. Б. 515.

Гавриилу (старшему из всех ангелов) свернуть их (сатану и всю нечистую силу) с неба, Гавриил свергнул. Кто упал в лес стал – леший. кто в воду – водяной, кто на дом, «Кормилец»[1].

Бу ышанулардан күренгәнчә, мәҗүсилек чорында изгеләштерелгән затлар, монотеистик дип кабул ителгәннән соң, явыз шайтани көч буларак күзаллана башлый. Шулай итеп каршылыклы образ туа.

Су ияләре образының матур үрнәге татар һәм башкорт халкының уртак мирасы «Түләк» дастанында сурәтләнә. Бу әсәр татар халкында язма дастан булып популярлашса[2], башкортлардан XX гасырда да телдә сакланган күпсанлы вариантлары язып алынган[3]. Башкорт вариантларын язып алып, бастыру эше XIX йөздә башлана. Дастан ике стихия вәкилләре – җир егете Түләк белән су кызы Сусылуның мәхәббәтенә багышланган. Башкорт версиясендә төп вакыйгалар Түләкнең Ачылы күл буена барып чыгып, Су кызын күрүе, аңа гашыйк булуы белән башланып китә: «Бер вакыт ул, ситендә нур уйнаганын күреп, гәҗәпкә кала. Заятүләк һак кына нур уйнаган ергә якынлаша. Килһә, ни күзе менән күрһен, күлдең ситендә генә ясы таш өстөндә толомдарын таратып, алтын тарак менән алтмыш колас озонлого кара сәсен тарап, һыу кызы ултыра. Асылыкүл өстөндәге нур уйнауга ошо һылыу кыззың һыу астынан сыгып бизәнеп ултырыуы сәбәр булган»[4]. Су кызы үзен нурдан яралуын, җир дөньясы кешесе булмавын әйтә, җир кешесе белән нурдан яратылган Су кызының тиң булмавын белдерә:

– Сибәр егет, шаулама,
Атым минең – Һыуһылыу,
Мине һорап даулама;

---

[1] *Дилакторский П.* Из преданий и легенд Кауниковского уезда Вологодской губернии // Этнографическое обозрение. Кн. XLII. М., 1899.

[2] *Госманов М.Г.* Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан, 1994. Б. 225–300; *Әхмәтҗанов М.* Түләк һәм Сусылу хакында дастан // Әдәби мирас. Казан, 1997. Б. 14–33.

[3] Бу турыда: Башкирский народный эпос. М. 1977.

[4] Башкорт халык ижады. Эпос. Беренсе китап. Өфө: Башк. кит. нәшр., 1972. Б. 190.

Егет, һиңә тиң булмам,
Нурзан тыуган токоммон,
Ерзә йөрөтеп хурлама;
Ер улыма тиң булмас,
Нурзан тыуган кыз бала.
Егет һүзең озайтма,
Ебәрә күр, ер улы,
Атам белһә, яу һалыр,
Башыма киәмәт һалыр[1].

Нурдан яратылу кызның башка дөнья вәкиле булуын күрсәтә. Фольклорда нурдан яратылу илаһи дөнья белән бәйләнешкә дә ишарә итә. Дастанның шушы ук версиясендә су асты дөньясы да тасвирлана: «Иркен болонда исәпһез-һанһыз йылкылар юшап йөрөй, сылтырап аккан йылгаларында алтын балыклар уйнай, тәрән-тәрән күлләрендә һәр төрле өйрәк, аккош, каззары йөзөп йөрөй, ти»[2]. Татар версиясендә сурәтләнгән су асты дөньясы исә анда кояш-ай булмау белән характерлана: «Бер заман көн, ай күренмәс йиргә чыкды. Бер булат сарай торыр. Алда – йаныңдин бердәй [дәрйалар] акып барыр: [йанында] балдин, йәнә алдында сөт дәрйасы акып барыр»[3].

Җир кешесе дә, Су кызы да үз дөньясында гына яши ала, эпос геройларның үлеме белән тәмамлана.

Татар халкында су ияләре белән бәйле ышанулар хәзергә кадәр очрый, су ияләренең күңелен күрер өчен төрле йолалар башкарыла, тыюлар-табулар саклана.

Су ияләре культы белән бәйле йолаларның берсе – яшь киленгә «су юлы күрсәтү» йоласы. Ул туй йолалары циклына кергән, хәзерге көнгә кадәр татарлар яшәгән кайбер төбәкләрдә саклана торган йола. Яшь киленгә су юлы күрсәтү йоласының төп максаты – киленне су иясе белән «таныштыру». Яшь килен беренче тапкыр суга баргач, шул суның хуҗасына бүләк бирә. Ул – түгәрәк икмәк яки акча булырга мөмкин. Килен икмәкне

---

[1] Башкорт халык ижады. Эпос. Беренсе китап. Өфө: Башкортстан кит. нәшр., 1972. Б. 190.

[2] Шунда ук. Б. 192.

[3] *Госманов М.* Каурый каләм эзеннән. Б. 243.

чишмәгә яки коега сала, су иясенә ошарга, аның күңелен күрергә омтыла. Киленгә су юлы күрсәтү күп халыкларда мәгълүм йолалардан. Мәсәлән, осетин халкында ул үзенең асылын саклап калган. Ул донмоконд дип атала, туйның төп йолаларыннан берсе. Бу су хуҗасы Донбеттырга киленне күрсәтү йоласы[1].

Татар халкында чишмәдән беренче тапкыр су эчкәндә анда акча яки чәч өзеп салу йоласы хәзерге вакытка кадәр саклана. Суга: «Сиңа яулык, миңа саулык» дип «бүләк» салу борынгыларның су иясенә корбан бирүенең эзе булса кирәк. Борынгы заманнарда су иясенә корбан бирү әкиятләрдә сакланган. Дәрья төбендә яшәгән аждаһага билгеле бер вакыт саен корбан биргәннәр. Диңгездә давылга эләккән диңгезчеләр дә диңгез патшасына, жирәбә салып, корбан биргәннәр.

Су иясенә корбан бирүнең бер төре – «Яңгыр боткасы пешерү» йоласы. Мәҗүсилек чорында Су ияләренә корбан суеп, аннан корылык җибәрмәвен яки яңгыр сораганнар. Су иясе кара төстәге терлекләрне ярата дип ышаналар. Шуңа күрә тегермәнчеләр дә бары кара төстәге терлек кенә асраган. Корбанга да кара төстәге терлек суелган. Әлеге йоланың эзләре балалар фольклорында, эндәшләрдә сакланган:

Яңгыр, яу, яу!
Кара сарык суярмын,
Ботын сиңа куярмын.

Шулай ук балалар су коенып чыкканда:

Исәнлегем-саулыгым,
Тазалыгым – байлыгым.
Сиңа – яулык,
Миңа – саулык, –

дип чыгалар. Бу да Су анасына ышануны аңлата.

Хәзерге көнгә кадәр сакланган ышануларда яз көне Су анасының улавы тасвирлана. «Су анасы язын бик елады, егетоланнар су кермәсен, батар», – дип ышаналар. Яз көне су анасына корбан бирәләр: икмәк, күмәч һ.б.

---

[1] Мифы народов мира. Т. 1. С. 392.

Төш вакытында, кояш баеганнан соң су коенырга, су алырга барырга да ярамый. Бу су ияләренең вакыты, аларны бимазалау тыела. Башкорт халкында кояш баегач су алырга туры килсә, алар: «Кунак төштө, кунак төштө, һыу бир», – дип, су иясеннән рөхсәт сорыйлар[1]. Шулай ук башкортларда су иясенең дүрт исемен әйтеп су алу йоласы да бар: Вәсәккәһем, Раббаһым, Шарабаһым, Тәһүрә (Васаккахим, Раббахым, Шарабахым, Тахура)[2]. Кояш баегач су коенган, су алган кеше авырып китәргә мөмкин. Бу тыю шулай ук «су пәрдәсе» дигән ышану белән бәйле. «Кояш баегач су пәрдәсен яба икән, шуңа кичен су алырга ярамый», диләр[3].

Су белән бәйле ышануларның берсе – «Су тоту». Ул да төрки халыкларда шактый таралган ышану. Кеше үзе беренче тапкыр күргән чишмәдән су алганчы анда чәч/җеп/тәңкә сала. Шулай эшләмәгәндә су иясе тотарга мөмкин. Су иясе кеше күзенә бака булып күренергә мөмкин[4]. Аңа бүләккә чишмәгә икмәк китерәләр. Нәзер әйтеп су иясенең күңелен күреп, чишмәгә кер борыр өчен сырлы бәләк яки чүкеч, чынаяк куялар.

Йомгаклап әйткәндә, Су ияләре белән бәйле сулыкларның сихри көченә ышануларның асылында кеше белән табигать арасында гармония сакларга омтылыш ята. Хәзерге вакытта суның мәгълүмат сакларга сәләтен төгәл фәннәр дә кире какмый. Шуңа күрә борынгыларның табигать белән җепләре өзелмәгән вакытта ук барлыкка килгән ышанулар яңача караш таләп итә. Аларның тагын бер әһәмиятле ягы бар, алар кешедә табигатькә сакчыл караш тәрбияли. Шул ук вакытта кешенең үзенең әхлагын тәрбияләү чарасы да булып тора. Бүгенге көндә бу ышанулар табигать һәм кеше экологиясенең бер өлеше буларак та өйрәнелергә хаклы.

---

[1] *Хисаметдинова Ф.Г.* Мифологический словарь башкирского языка. М.: Наука, 2010. С. 354.

[2] Шунда ук. С. 355.

[3] Шунда ук. С. 355.

[4] Татарстанның Кама Тамагы районында язып алынган материаллардан.

## БЕРДЕР АЛЛАҺЫМ БӘНЕМ

(Татар халкының ислам динен кабул итү турындагы риваятьләре һәм дини эчтәлекле легендалар)

Татар халкының ислам динен кабул итүенә һәм ислам кануннарына нигезләнеп яши башлавына мең елдан артык вакыт узган. Идел буе болгарлары ислам динен рәсми рәвештә 922 елның май аенда кабул итәләр. Чынбарлыкта болгар халкының ислам диненә күчүе алдарак башлана. Унынчы гасыр фарсы географы Ибне Рустәнең 903–913 елларда язылган энциклопедик характердагы «Ал-Алак ан-нафиса» хезмәтендә Идел буе болгарлары турында да мәгълүмат бирелә: «Царь булгар, Алмуш по имени, исповедует ислам»[1], «Большая часть их исповедует ислам, и есть в селениях их мечети и начальные училища с муэдзинами и имамами»[2]. Бу юллардан күренгәнчә, рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүдән шактый алда Болгарда мәчетләр, мәдрәсәләр булган, халыкның күпчелеге ислам динен тоткан. Ибне Фазлан да болгарлар арасында мөселманнар булуын, мәчетләрен күрүен яза[3].

Галимнәр болгарларның ислам динен 813–833 елларда, хәлиф әл-Мәмун вакытында кабул иткән булырга мөмкинлеген әйтәләр. Бу вакытта хәлиф әл-Мәмун Урта Азиядән Хазар каганлыгына хәрби походлар оештыра. Хазар каганлыгы

---

[1] Известия о Хозарах, Буртасах, Болгарах, Мадьярах, Славянах и Руссах Абу-Али Ахмеда Бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабскаго писателя начала X века, по рукописи Британскаго музея /Издал, перевел и объяснил Д.А. Хвольсон. СПб., 1869. С. 22.

[2] Шунда ук. С. 23.

[3] *Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков: Изд-во Харьковского университета, 1956; Путешествие Ибн Фадлана на Волгу / пер. и комментарии под ред. акад. И.Ю. Крачковского. М.-Л.: Изд-во АН СССР. 1939; Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / публ. О.Г. Большакова и А.Л. Монгайта. М., 1971. С. 131–136.

составында яшәгән халыкның бер өлеше ислам динен кабул итә. Дөрес, болгарларның ислам дине белән тагын да элегрәк танышуы да мөмкин[1].

Димәк, болгарлар Урта Идел буена күчеп килгәнче үк ислам динен кабул иткәннәр. Ихтимал, Идел буенда яшәгән җирле төрки халык арасында да ислам динен тотучылар булгандыр.

Татар халкының төрле чыганакларында сакланган риваятьләргә караганда, Идел буена ислам дине VII гасырда ук үтеп керә. Болгарларның ислам динен кабул итүләре турындагы риваятьләр әл-Гарнати сәяхәтнамәсендә, урта гасырларның Көнчыгыш авторлары әсәрләрендә, фольклор җыентыкларында, тарихи хезмәтләрдә, халык хәтерендә сакланган.

Халык иҗаты әсәрләре болгарларның ислам динен кабул итүен сәхабәләр исеме белән бәйли. Риваятьләр бәян иткәнчә, сәхабәләр Болгарга Айдар хан вакытында киләләр. Болгарның беренче ханы Туки (яки Туфи) атлы була. Ул һиҗри белән 9 нчы елда (милади белән 630 ел) вафат була. Тәхеткә улы Айдар утыра. Айдар хан ил белән илле ел идарә итә. Болгар халкы Айдар хан идарә иткән елларда ислам динен кабул итә[2]. Бу риваятьнең күп төрле версияләре һәм вариантлары бар. Әл-Гарнати сәяхәтнамәсендә аның язмага теркәлгән иң борынгы варианты сакланган. Болгарга Бохарадан мөселман сәүдәгәр килгән. Бу кеше табиплык һөнәрен дә белгән. Ул килгән вакытта патша һәм аның хатыны бик каты авырып китәләр. Мөселман сәүдәгәр аларга: «Әгәр дә мин сезне дәваласам, минем динне кабул итәрсезме?» – дигән. Патша риза була. Болгарлар шул вакыттан ислам динен тота башлыйлар[3]. Әбу Хәмид әл-Гарнати бу

---

[1] *Хузин Ф.Ш.* Волжская Булгария в домонгольское время (X – нач. XIII вв.). Казань: Фест, 1997. С. 113.

[2] *Шпилевский С.М.* Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губернии. Казань: Типография Казанского университета, 1877. С. 38.

[3] Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / О.Г. Большаков, А.Л. Монгайт. М.: Главная редакция восточной литературы издательства «Наука», 1971. С. 31.

риваятьне XII гасыр болгар тарихчысы Якуб бине Ногманның «Болгар тарихы» дигән хезмәтеннән алган.

XVI гасырга караган «Тәварихы Болгария» әсәрендә риваятьнең тагын бер варианты китерелә. Х. Хисмәтуллин: «XVI йөзнең икенче яртысында Казан ханлыгы бетерелү һәм Идел–Чулман буйларының Россия составына кертелүе уңае белән зур тарихи борылышлар, каты бәрелешләр булган. Менә шундый шартларда Мөслими халык телендә йөри торган риваятьләрне җыйган, туплаган һәм аларны язып беркеткән»[1], – дип яза. Тарихи борылышлар вакытында халык үзенең тарихына, үткәненә игътибарын көчәйтә. Күрәсең, үзенең динен саклап калырга тырышкан халык арасында бу риваять бик популяр булган һәм актуаль яңгыраган. Риваять әл-Гарнати сәяхәтнамәсендәге вариантка бик охшаш. Әсәрдә вакыйганың булган вакыты, геройларның исемнәре бирелә: «Тарих тукыз сәнәсендә хут елында вә йолдызында рамазан мөкәрәмнең тугызынчы көнендә, ул заманда Айдар хан ирде, хәзрәте Сәйеде галәм салләллаһы галәйһи вә сәллам өч сәхабә җибәрде тәгълиме ислам вә дин өчен Болгарә: берсе – Габдерахман бине Зөбәер, икенчесе – Зөбәер бине Җәгъдә, өченчесе – Тальхә бине Госман». Бу өч сәхабә үзләрен табиплар дип игълан итеп, күп кешеләрне дәвалыйлар. Айдар ханның кызы Туйбикә дә авырып китә. Сәхабәләр кызны ничек дәваларга икәнен әйтәләр. Алар бер таякны кара савытына куеп дога кылалар. Таяк яфрак ярып утырган каен агачына әйләнә. Кызны мунчада яңа каен себеркесе белән чапканнан соң, ул терелә. Бу могҗизаны күргән халык ислам динен кабул итә. Сәхабәләр Болгарда өч ел яшиләр. Халыкны дингә өйрәтәләр, мәчет салдыралар, мәдрәсә ачалар, Коръән өйрәтәләр. Өч елдан соң ике сәхабә кире Мәдинәгә китә. Хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдә Болгарда кала, хан кызы Туйбикәгә өйләнә, 25 ел Болгарда яшәп, вафат була[2].

---

[1] Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 451.

[2] *Мөслими Х.* Рисаләи тәварихы Болгария вә зикри мәүләнә хәзрәте Аксак Тимер вә харабе Шәһри Болгар. Казан, 1887. Б. 25–27.

Әлеге риваятьнең вариантлары халык хәтерендә озак сакланган. Бу риваятьләрнең барысында да болгарларның ислам динен кабул итүе гарәп миссионерлары, Мөхәммәт пәйгамбәрнең сәхабәләре белән бәйле. Бу риваятьнең берничә варианты 1970 еллар тирәсендә Татарстанның хәзерге Спасс районында язып алына[1].

«Аякка баса. Тәмам терелә бу. Кыз әнисенең бүлмәсенә керә. Әнисе бик аптырый. Айдархан патша янына кереп китә, кызның терелүе турында хәбәр бирә. Хәзер Айдархан сәхабәләргә әйтә:

– Кызны бирәм берегезгә, – дип.

Кызны Коръән хафиз Тәлкага бирергә була. Сәхабәләр Мөхәммәт пәйгамбәргә хат язалар. «Ал», – ди пәйгамбәр әйтә.

Кызына да, атасына да:

– Иманга килегез, – диләр болар.

– Бөтен шәһәрне иманга китерәм, – ди патша.

Туйбикә белән сәхабә Тәлка егерме биш ел бергә торалар»[2].

Әлеге сюжет татар халык әкиятләрендә дә очрый. Патша кызын дәвалаучы кеше ахырдан ул кызга өйләнә һәм патша була.

Әсәрдә Болгар халкының патша кызын дәвалаган өчен рәхмәт йөзеннән һәм мөселман табипларның яки сәхабәләрнең көчен танып ислам динен кабул итүләре бәян ителә. Г.М. Дәүләтшин бу риваятьнең реаль җирлеге булуын яза. Ибне Фазлан сәяхәтнәмәсендә Алмыш ханның үзенә дарулар җибәрүне соравы, ул даруларның аңа тапшырылуы турында мәгълүмат бар[3].

«Сөләйман хуҗа» дигән риваятьтә Мөхәммәт пәйгамбәр исән чакта Мәккә шәһәреннән бер зур галим кешенең Идел буена дин өйрәтер өчен җибәрелүе турында сөйләнә. Бу

---

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 296.

[2] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 25.

[3] *Давлетшин Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. С. 98.

кеше Сөләйман исемле була. Сөләйман Хуҗа илгә чыгып, зур мәдрәсәләр ачып, бик зур муллалар чыгарган. Алар, авылларга таралып, илне агартканнар, ди[1].

Сәхабәләрнең Болгарга килеп җитүе турында «Шәһри Болгар әүлияләре» бәетендә дә сөйләнә:

Шәһри Болгар әүлияләренең җирдә, күктә нурлары,
Шәһри Болгарга килгәннәр сәхабәләрнең зурлары,
Шәһри Болгар мәсҗиден сәхабәләр салганнар,
Газизләр күчкән чакта дога кылып калганнар,
Шәһри Болгар манарасының туксан сигез баскычы,
Болгарга килгән сәхабәләр дин исламның ачкычы[2].

Икенче риваятьтә Болгар халкының ислам динен кабул итүенә сәбәп итеп, Болгар ханының төш күрүе күрсәтелә: «Болгар ханы безнең көннәрдә, ягъни Һиҗри белән 332 елда (943–944 еллар) мөселман иде. Ул әл-Мөктадир вакытында 310 (921–922) елда төш күргәннән соң ислам динен кабул итә»[3]. Биредә Болгарга составында Багдад хәлифе сәркатибе Әхмәт ибне Фазлан булган гарәп илчелеге килүе, илнең рәсми рәвештә ислам динен кабул итүе турында сөйләнә. Бу сюжетка корылган риваять тә бар. Габдешшәмс дигән кеше төшендә, Хозер галәйһиссәламне күргәннән соң, Аллаһы Тәгаләгә табына башлый[4].

Ислам динен кабул итү белән бәйле рәвештә халыкның аң-белем дәрәҗәсен үстерү өлкәсендә дә эш башлана. Шәһәр-авылларда мәктәп-мәдрәсәләр ачыла, халыкның зур күпчелеге гарәп язуы нигезендә укый-яза белә. Бу исә Коръән өйрәнергә, дини китаплар белән танышырга юл ача. Ибне Рустә Болгарда мәчетләр һәм мөәзин-имамнары булган мәдрәсәләр булуын

---

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 26–27.
[2] Татар эпосы: Бәетләр. Казан: Фән, 2005. Б. 55.
[3] *Гаркави А.Я.* Дополнения к сочинению «Сказания мусульманских писателей о славянах и русских. СПб.: Тип. Цидербаума, 1871. С. 41.
[4] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 26.

яза[1]. X–XI гасырлардан башлап, Болгарда югары белем бирә торган мәдрәсәләр дә ачыла. Мәдрәсәләрдә беренче чиратта дини белем биргәннәр, Коръән өйрәтелгән. Шул ук вакытта яшәү өчен кирәк дөньяви белемнәр дә бирелгән. Ул чорга караган язма истәлекләрдә Болгарның тарихчы, философ, юрист, медик галимнәре турында мәгълүматлар очрый. Иң югары белем чит илләрнең алдынгы фән үзәкләрендә алынган. Мәдрәсәләрдә шулай ук гарәп теле өйрәтелә, фарсы теле дә өйрәтелгән булуы мөмкин. Ислам дине, Коръән аша Болгарга дини легендалар, гарәп-фарсы халыклары фольклоры да үтеп кергән.

Халык авыз иҗаты әсәрләрендә Болгар шәһәрләрендә хатын-кызлар өчен махсус мәдрәсәләр булуы турында еш сөйләнә. «Туйбикә мәдрәсәсе» дигән риваятьтә Туйбикә абыстайның бик зур кызлар мәдрәсәсе тотуы, анда төрле илләрдән килгән кызларның зур галим булганчы укулары тасвирлана. Мәдрәсәне «Алтмыш алты абыстай мәдрәсәсе» дип йөрткәннәр. Бу абыстайлар Биләр шәһәреннән Шәһре Болгарга барып сабак укыганнар. Риваять буенча алар сәхабәләрнең шәкертләре булганнар. Туйбикә абыстайның әмере белән, бу алтмыш алты абыстай, алтмыш алты якка таралып китеп, күп халыкны хак юлга күндергәннәр[2]. Кызлар мәдрәсәсе турында «Шәһри Болгар» бәетләрендә дә искә алына:

Шәһри Болгар кызлары бары да әүлия булганнар,
Остазлардан сабак укып, ничә меңгә тулганнар[3].

Алдарак бирелгән риваять буенча, Туйбикә – Айдар ханның сәхабәләр дәвалаган кызы. Ул Зөбәер бине Тәлка сәхабәнең хатыны була. Беренчеләрдән булып ислам динен кабул итә.

---

[1] Известия о Хозарах, Буртасах, Болгарах, Мадьярах, Славянах и Руссах Абу-Али Ахмеда Бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабскаго писателя начала X века, по рукописи Британскаго музея / издал, перевел и объяснил Д.А. Хвольсон. СПб., 1869. С. 23.

[2] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 27.

[3] Татар эпосы: Бәетләр. Казан: Фән, 2005. Б. 57.

«Мәрҗән каласы һәм унике кыз хикәяте» дигән риваятьтә дә хатын-кызлар мәдрәсәсе турында сөйләнә. «Рабига остабикә мәдрәсәсе Биләрдәге Хуҗалар тавы итәгендә бик зур чишмә буена урнашкан була. Рабига көн саен шәһри Болгардан Бүләргә җир асты юлы буенча алтмыш алты шәкертен ияртеп укырга килгән[1]. «Шәһри Болгар бәетләрендә» дә Шәһри Болгар кызларының җир асты юлыннан укырга йөрүе турында әйтелә:

Шәһри Болгарның кызлары киндер башмак кигәннәр,
Сабак укырга килгәндә җир астындин килгәннәр[2].

Риваять буенча, Болгарның Җәмигъ мәчетенә тоташтырган җир асты юллары булган.

Болгарда Коръән, ислам дине аша кергән легендалар да бик популяр булган. Алар ислам дине кабул ителгәнгә кадәрге мәҗүси ышанулар белән бәйле легендалар белән үрелеп тә киткән.

Ибне Фазлан үзенең сәяхәте вакытында Болгарда кунган беренче көнне күктә гаҗәеп күренешләр күзәтүен бәян итә. Күктә, каты тавышлар чыгарып, коралланган ике гаскәр сугыша. Ибне Фазлан бу күренештән куркып калуын яза. Болгар патшасы Ибне Фазланга бу күренешне мөселман һәм кяфер җеннәрнең үзара сугышуы дип аңлата[3]. Коръән буенча, җеннәрнең бер өлеше ислам дине кабул иткән, ягъни «Коръәнгә иман китереп, мөселман булган җеннәр». Икенче өлеше иман китерми: «Дәхи бездән, әлбәттә, яхшылар да бар, вә бездә яхшылардан башка явызлар да бар. Без, әлбәттә, төрле юлда булдык»[4].

Татар халкында алыплар турында легендалар популяр булган, бу образ борынгы дастаннарда саклана. Болгар чорын

---

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Б. 37.

[2] Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 24.

[3] *Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921–922 гг. Харьков: Изд-во Харьковского университета, 1956. С. 134.

[4] Коръән, 72: 8–11.

тасвирлаган язма чыганаклардан мәгълүм булганча, Алыплар турындагы фольклор әсәрләре ислам мифологиясе һәм Коръән аша кергән сюжетлар белән кушылып киткән. Болгар халкы Алыпны Яэҗүз-Мәэҗүз токымыннан (Ибне Фазланда) яки Гад нәселеннән (Әл-Гарнатидә) дип аңлаталар. Яэҗүз-Мәэҗүз һәм Гад халкы шулай ук Коръәндәге мифик халыклар. Татар халкына Нух пәйгамбәр һәм Туфан турындагы сюжет та ислам мифологиясе, Коръән аша кергән.

Татар фольклорына Коръән аша пәйгамбәрләр, хәлифәләр, изгеләр күп үтеп керә. А.Х. Садыйкова: «В Коране упоминаются имена пророков, халифов, праведников, которые в дальнейшем стали популярными персонажами фольклора, литературы и вошли неотъемлемой частью в обрядовый фольклор татар мусульман», – дип яза[1].

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин, Х гасырда рәсми рәвештә кабул ителгән ислам дине, татар халкына күп алда килеп җитә. Халык иҗаты әсәрләре саклаган мәгълүматлар буенча, аны Болгарга Мөхәммәт пәйгамбәрнең сәхабәләре – ислам миссионерлары алып килә. Болгарларның ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгән вакытта мәчетләре, дин нигезләрен һәм дөньяви фәннәрне укыта торган мәдрәсәләре булу гарәп сәяхәтчеләренең юлъязмаларында да теркәлгән. Шул чорда татар халкына Коръән һәм ислам мифологиясе, гарәп фольклоры белән бәйле сюжетлар, образлар үтеп керә. Алар җирле фольклор белән кушылып, бу сюжетлар яңа яңгыраш таба.

[1] *Садекова А.Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество. Казань: Фикер, 2001. С. 94.

## ТУГАН ТЕЛДӘ КЫЛГАН ДОГАМ

(Татар фольклорында багышлау жанры)

Ислам динен рәсми рәвештә X гасырда ук кабул иткән татар халкының рухи кыйммәтләре дә ислам кануннарына нисбәттә формалашкан. Халык гасырлар дәвамында шушы кануннар нигезендә җанын-рухын мәкердән-яманлыктан саклап, тәнен, киемен-йортын һәм бигрәк тә уй-фикерләрен пакь тотып, изге ният кылып яшәргә омтылган.

Хәзерге вакытта уй-фикерләрнең һәм ниятнең зур көчкә ия булуы фән тарафыннан да исбатлана башлады. Бу теләк-ниятләрнең беренче чиратта кешенең үз тормышына тәэсире бәхәссез. Дөньяны яратып кабул иткән, бар кешеләргә яхшы теләктә булган, хәерхаһлы кеше, әлбәттә, сәламәт була, үзенең нерв системасын саклый. Икенче яктан, теләсә нинди теләк кешенең үзенә кире кайта. Шуңа күрә дә кешегә начарлык түгел, үзеңә яхшылык теләргә кирәк. Бүгенге көндә психологлар дошманыңа да, сиңа начар мөнәсәбәттә булган кешеләргә дә яхшы уйда калырга, яки бу начарлыкны онытырга кушалар. Яхшы теләк төгәл формалашкан булырга тиеш. Шуңа күрә дә «тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк» диләр.

Татар халкында яхшы уй-фикер, изге теләкләрнең калыплашкан бик матур үрнәкләре бар. Бу багышлаулар, алкышлар, төрле эш-гамәлләргә һәм вакыйгаларга бәйле рәвештә Аллага мөрәҗәгать иткән шигъри текстлар. Алар барысы да татар телендә. Информантлар бу текстларны дога дип тә атыйлар. Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырендәге юллар нәкъ шушы текстларның асылын ача:

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Сезнең игътибарыгызга әлеге теләкләрнең татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә язып алынган кайбер үрнәкләрне тәкъдим итәбез. Бу текстларда татар халкының ислам һәм

мәҗүсилек белән бәйле күп кенә ышанулары, изге саналган күп кенә шәхесләрнең исемнәре саклана. Текстларда мәгънәләре аңлашылмаган сүзләр дә очрый. Әмма аларны да төшереп калдыру дөрес түгел. Бәлки бу сүзләрнең мәгънәсен, каян килеп чыгуларын белүчеләр укучылар арасындада булыр.

Беренче текстны 2003 елда Свердловск өлкәсенә оештырылган экспедиция вакытында, Красноуфимский районы Табанлы Күл авылында яшәүче Миңнеәхмәтова Фатима апа Гафи кызы биргән дәфтәрдән алдык. Бу – Коръән укудан соң багышлау. Текстта гарәп теленнән кергән сүзләр, ислам мифологиясе белән бәйле исемнәр, терминнар күп сакланган. Алар – текстның, мәдрәсәдә белем алган, гарәп телен яхшы белгән кешеләр тарафыннан төзелүен, буыннан буынга күчеп саклануын күрсәтә. Һәр шәхес яки термин турында мөмкин булган кадәр аңлатма биреп барырга тырыштык.

## Багышлау

Ошбу укылмыш аятьләрне тапшырдым тәрбияче бер Аллам үзеңә. Үзең разый булып, укуымда булган хаталарымны гафу кылгыл. Җир йөзенә нур итеп җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рух шәрифләренә ирештер. Әһле әүляд[1]ларына, әһле бәйтенә[2], әнбияләр[3]-әүлияларыңа[4], чаһриярлар[5], җиде газизләргә[6], мәшаехләргә[7], сәхабәләргә[8], ил имамнарына, ил остазларына, әхмәтләр, солтаннар рухларына әҗер савапларын ирештер, и Ходаем.

---

[1] Әүляд – Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең балалары.

[2] Әһле бәйт – Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаилә әһелләре

[3] Әнбия – пәйгамбәр.

[4] Әүлия – изге.

[5] Чаһрияр –дүрт дус, Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң идарә иткән дүрт тугры хәлифә.

[6] Газиз – изге, пәйгамбәр.

[7] Мәшаех – шәех сүзенең күплек саны.

[8] Сәхабә – Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күреп белгән аркадашлары, фикердәшләре.

Барча рәхим фәрештәләребезгә, газап фәрештәләребезгә, өч йөз алтмыш алты гаип ирәннәренә,[1] караеш яланга, кыйтмир көчекләргә[2] ирештер, әй Ходаем. Барча үзеңнең тиешле урыннарыңа ирештер. Атабыз Адәм белән анабыз Хәүва рухларына, анабыз Мәрьям рухларына, анабыз Гамбәр[3] рухларына, унбер җәннәт әнкәләребезгә[4], мәгърибтән мәшрикъка хәтле пәйгамбәрләребез рухларына, Рәсүлебезнең сигез зәүҗәт мотаһһәраларына[5], Фатыйма[6] разыйаллһу ганһага, Хуҗа Баһаветдин[7], Зәнки бабайга[8], Чулпан атага[9], Мөшкил-шад кызга[10], барча якыннарына, Сөләйман, Идрис, Хызыр галәйһиссәламнәргә ирештер, Ходаем.

Газиз әти-әниемнәрнең, кайнана-кайнаталарымның, ата-бабаларыбызның, җиде буынга кадәр булган кыз туганнарымның, ир туганнарымның, исемсез киткән, кан белән киткән сабыйларымның рух шәрифләренә кабул кыл.

Барчасының бәндәчелек белән кылган гөнаһларын ярлыкыгыл. Җаннарын изге кыл, тулы-нурлы иманнарын мәңге

---

[1] Гаип ирәне – күзгә күренми торган изгеләр.

[2] Кыйтмир көчек – җәннәткә керәчәк хайваннарның берсе.

[3] Гамбәр ана – Урал яны татарларында бала табучы хатыннарга ярдәм итүче изге.

[4] Ислам динендә пәйгамбәрләрнең аналары, хатыннары һәм якыннары булган унбер хатын-кыз. Шулар арасында Хәүва ана, Мәрьям ана да бар.

[5] Зәүҗәт мотаһһәралары – никахлы хатыннары.

[6] Фатыйма разыйаллһу ганһа – Мөхәммәт салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кызы

[7] Хуҗа Баһаветдин – суфи Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди (1318–1389).

[8] Зәнки бабай – төрки халыкларда изгеләштерелгән образ. Эре терлекләрне саклый торган изге.

[9] Чулпан ата – төрки халыкларда изгеләштерелгән образ. Сарыкларны саклый торган изге.

[10] Мөшкил-шад кыз – Биби-Мүшкилкуш, авырлык килгәндә ярдәмгә килә торган изге. Ислам мифологиясе буенча суфый Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәндинең апасы санала.

бакый юлдаш кыл. Кабер газапларыннан коткар. Үзеңнең рәхмәтле урыннарыңа ирештер.

Үзебезнең калган гомерләребезне бәрәкәтле кыл. Иманнарыбызны таза кыйл. Тоткан уразаларыбызны, кылган гамәлләребезне кабул кыйл, заядан кыйлма.

Изгелекләребезнең хәерле әҗерләрен насыйп ит. Шатлыклы-тыныч изге бәхет капуларыбызны ач. Әй Раббым, тулы сәламәтлекләребезне биреп, хәерле шатлыклар, тыныч көннәргә ирештереп, уйламаган җирләрдән, гаип хәзинәләреңнән исәпсез-хисабсыз хәерле, хәләл ризыклар, нигъмәтләр, киң дәүләт насыйп кылып, үзеңә изге гамәлләр кылырга насыйп кыйл, Ходаем.

Барчабызның камил гакылларыбызны, күркәм сабырлыкларыбызны, күркәм холыкларыбызны, тулы зиһеннәребезне насыйп кыл.

Истикамәт[1], һидаять[2], тәүфикъ, миһербан-шәфкатьләребезне насыйп кыл. Кешеләр арасында мәхәббәтле, сөйкемле кыйл. Йөргән юлларыбызны уң кыйл, сөйләшкән сүзләребезне өстен кыйл.

Барча хәрәм ашлардан, нәфеслелекләрдән үзең тый, Ходаем. Тоткынлыкларга дучар итмә, караңгылыкларга, тарлыкларга, хурлыкларга салма.

Шайтан шәреннән[3] үзең сакла.

Дошманнарга ирек бирмә, үз дошманлыкларын үзләренә кайтар.

Барча хәвеф-хәтәрләрдән, бәла-казалардан үзең сакла. Үзеңнең рәхмәтеңнән ташлама. Күңел шатлыкларыбызны, җан тынычлыкларыбызны насыйп кыйл, тигезлек-бәхетләребездән аерма.

Балаларыбызның иман-тәүфикъларын бир. Ислам динен мәхәббәтле кыйл. Игелекле балалар булсыннар. Барысы да тулы бәхет, мәхәббәт белән яшәсеннәр, тигез бәхетләрен ач.

---

[1] Истикамәт – турылык, дөрес юнәлеш

[2] Һидаять – туры юл.

[3] Шайтан шәре – шайтан явызлыгы, зарары.

Икенче текст Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Бортас авылында Шаһиева Асия Харис кызыннан 2006 елда язып алынды. Бу текст мәҗүсилектән калган шактый гына ышануларны саклый, еш кына мөселман һәм мәҗүси культлар кушылып китәләр. Шул ук вакытта ул Болгар дәверен, Шәһри Болгарны, аның халкын изгеләштерүе, ягъни татар халкының Болгарга мөнәсәбәтен күрсәтү ягыннан да кыйммәтле чыганак.

**Багышлау**

И Ходаем, ушбу укыганнарымны багышладым үзеңнең ризалыгың өчен, Мөхәммәт галәйһиссәлам хакы-хөрмәте өчен, өч йөз сәхабәләр хакы-хөрмәте өчен, атабыз Адәм, анабыз Һәүва хакы-хөрмәте өчен, әүвәле Әбү Бәкер Сыйддикъ, аннары Гомәр, өченчесе Госман, дүртенче Гали[1]разыйаллаһу ганһләр хакы-хөрмәте өчен. Ушбу укыганнарымны багышладым унбер ана, Әхмәт хакы-хөрмәте өчен, су атасы Сөләйман, су анасы Сылубикә[2] хакы-хөрмәте өчен, җирдәге вә күктәге фәрештәләр өчен, өч йөз алтмыш изгеләр хакы өчен, өч йөз алтмыш биш гаип ирәннәре өчен, өч йөз унөч мөрсәл[3]-пәйгамбәрләр хакы өчен, җиде әүлияларга, җиде әнбияләргә, җиде султаннарга, туксан тугыз мәшаехләргә, кырык бер кабер әһелләренә, көн ирәннәренә, төн ирәннәренә, гаип ирәннәренә, нигез хуҗаларына, киртә хуҗаларына, гарипләргә, зәгыйфьләргә, заһидләргә-заһидәләргә[4], кыр ирәннәренә, су ирәннәренә, Кабан күлендәге Фәйзулла әфәнде белән Галиәкбәр хуҗаларга[5], Чабыр тау изгеләренә[6], Шәһри Болгар изгеләренә.

---

[1] Әбү Бәкер Сыйддикъ, Гомәр, Госман, Гали – дүрт хәлифә.

[2] Су атасы Сөләйман, су анасы Сылубикә – татар мифологиясендә су хуҗаларының исемнәре дә саклана.

[3] Мөрсәл – пәйгамбәр.

[4] Заһидләр һәм заһидәләр – аскетлар, дөнья рәхәтлекләреннән ваз кичеп, гомерләрен гыйбәдәттә үткәрүчеләр, изгеләр.

[5] Кабан күлендәге Фәйзулла әфәнде белән Галиәкбәр хуҗалар – Кабан күлендәге изгеләр санала.

[6] Чабыр тау изгеләре – Кама Тамагының Келәнче авылы янындагы тау. Анда Болгар чорында илне саклап шәһид киткәннәрнең – изгеләрнең каберләре булган дигән ышану бар.

Өченче һәм дүртенче текстлар 2012 елда Удмуртия республикасында узган экспедиция вакытында Глазов районы Татар Парҗысы авылында Бузикова Фәйрүзә Гайнан кызы биргән язмадан алынды. Бу текст эчтәлеге белән мөнәҗәтләргә якын, информантлар дога дип атый торган әсәрләрнең бер үрнәге.

И Ходаем, үзең сакла
Сән безләрне бәла белән казадин.
Мәхрүм кылмаса безләрне ата берлән анадин.
Дәһил берлән дәрман бир,
Тәүфикъ берлән иман бир,
Хәерле эшкә хәрәкәт бир,
Ашыбызга бәрәкәт бир,
Малыбызга өлеш бир,
Җаныбызга тынычлык бир,
Бездән борын үткәннәргә,
Дога өмет иткәннәргә
Бер «әлхәм» белән өч «колһуаллаһ»савабын бир.
Амин!

* * *

Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим.
И Ходаем, ошбу фани дөньяда, дус-дошманым арасында
Мән мескенне хур итмә,
Бәхетемне ким итмә.
Көннин көнгә тәүфикъ бир.
Барча мөселманнарның ахыр сулышына кадәр иман бир,
Алар белән мән колыңны бергә кыл.
Бу дөньядан күчәрбез,
башсыз атка менәрбез.
Башсыз атка менгәндә
иманымны баш әйлә,
намазымны юлдаш әйлә.
Тар кабергә кергәндә,
соругылар сурганда[1] җавабымны үзең бир.

---

[1] Соругылар сурганда – сораулар сораганда, архаик вариант.

Тар каберем киң ит,
караңгысын якты ит.
таразыга[1] сурганда җавабымны авыр ит,
гөнаһымны җиңел ит.
Сыйрат күперен кичкәндә аягымны тайдырма.
Атабыз Адәм илә анабыз Хәүва йөзен күргез,
Гайшә илә Фатыйма йөзен күргез.
Я Рабби, рәхмәтең илә гөнаһыларыбызны ярлыка.
Рәхмәт кылсаң, рәхмәтең бар,
Каһәр кылсаң, кодрәтең бар,
Рәхмәтеңнән өметем бар,
Каһәреңнән куркуым бар.
Колларыңа кол итмә,
Дошманыңа хур итмә,
Шайтаныңа яр итмә.
Изге колларыңнан аерма.
Яман сагыш тотмактан күңлем сакла,
Җиде әгъзамны сакла, я Рабби.
Иманымны үзең сакла.
Шөкер кыламын барлыкка,
Төшермә безне тарлыкка,
Барчабызны ярлыка,
Яраткучы Җәббар[2]
Сән саклаучы Саттар[3],
Сән сакла, Ходам.

2017 елда Казакстанның Семей (Семипалатинск) шәһәрендә узган экспедиция вакытында да шактый гына материал язып алынды. Семей шәһәрендә яшәүче Ибраһимова Рәйхангөл Закир кызы да әбисеннән өйрәнгән дини эчтәлекле шигъри әсәрне яхшы белә. Бу догаларны әбием сөйли иде, без кабатлап ята идек, дип искә ала Рәйхангөл апа. Әлеге текст Удмуртия тексты белән аваздаш булса да, һәр икесенең дә

[1] Таразы – үлчәү, кешенең яхшылыгы һәм яман эшләре салыначак үлчәү, мизан.

[2] Җәббар – кодрәтле, Аллаһының күркәм исемнәренең берсе.

[3] Саттар – гафу итүче, Аллаһының күркәм исемнәренең берсе.

үзенчәлекле строфалары да күп. Шуңа күрә икесен дә бирүне урынлы дип саныйбыз.

Илаһым, хур кылма,
Талигымны[1] ким кылма.
Көннән көнгә бәхет бир,
Көннән көнгә тәүфикъ бир.
Каһәр кылсаң, каһәрең бар,
Каһәреңнән куркарым бар.
Рәхмәт кылсаң, рәхмәтең бар,
Рәхмәтеңнән өметем бар.
Колларыңа кол итмә,
Шайтаныңа яр итмә.
Туби агач[2] төбиндин,
Тудәиңнең туендин
Мәхрүм кылма илаһым.
Таразыга барганда,
Гамәлемне авыр ит,
Гөнаһымны җиңел ит.
Сыйрат күперен кичкәндә
Аягымны тайдырма.
Фатыймага юлдаш кыл,
Илаһым, шөкер иттем барлыгыңа,
Төшермә мине тарлыгыңа.
Дәүри[3] белән дәүран[4] бир,
Бакый белән иман бир,
Хәерле эшкә хәрәкәт бир,
Башыбызга бәрәкәт бир,
Бездән борын үлгәннәргә,
Бездән дога көткәннәргә
Бер Әлхәм, өч Колхуалланың савабын бир.

Семей шәһәрендәге икенче информантыбыз Насыйрова Гөлфия Хәбибрахман кызы яздырган текст та татарлар яши

[1] Талигъ – бәхет.
[2] Туби агач – туба агач, оҗмах агачы.
[3] Дәүри – бай, җитеш.
[4] Дәүран – чор, гомер.

торган төбәкләрдә популяр әсәрләрдән булган. Гөлфия апа бу текстларны әбисеннән өйрәнүен әйтә: «Әбинең әйтә торган сүзләре бар иде. Ары дөньяга барганда сорак бирерләр. Шул соракларга син җавап бирергә тиешсең, дип. Шул соракларга син җавап бирергә өйрән дип әйтә иде. Шулай җавап бирергә тиешсең, дип әйтә торган иде миңа әби.

– Бердән ни дип beләсең?
– Бер Аллам дип беләмен.
– Икедән ни дип беләсең?
– Ике иңемдәге фәрештә дип беләмен
– Өчтән ни дип беләсең
– Өч витрны дип беләмен.
– Дүрттән ни дип беләрсең
– Дүрт бурычлы Коръән дип беләмен.
– Биштән ни дип беләсең
– Биш мизгеллек намаз дип беләмен.
– Алтыдан ни дип беләсең?
– Ата-ана хакы дип беләрмен
– Җидедән ни дип беләрсең?
– Җиде тәмуг дип беләрмен.
– Сигездән ни дип беләрсең?
– Сигез җомах дип беләрмен.
– Тугыздан ни дип беләрсең?
– Туксан тугыз мәгъриб белән мәшрикъ дип беләрмен.
– Уннан ни дип беләрсең?
– Уңлы-суллы сәлам дип беләрмен.

Семей шәһәрендә Абдулкәримова Галия Хәмит кызыннан язып алынган текст та әби-бабаларыбыз барыбызга да өйрәткән әсәрләрдән.

Башым куйдым ястыкка,
Күңлем бирдем Аллага.
Алла-Алла дигәндә,
Караңгы гүрем яктырсын!
Сөбханалла дигәндә,
Оҗмах ишеге ачылсын!

Семей шәһәреннән ерак түгел Аккүл авылында яшәүче Измаилова Гөлчирә Сәетәхмәт кызыннан язып алынган текст та күбебезгә таныш.

Яттым, я Аллаһ!
Торырмын, иншааллаһ!
Иман белән ятаем!
Ислам белән тораем!
Бу җатканнан торалмасам,
Иман байлыгын бир, Аллаһ!

Бу текстларны бер үзенчәлек берләштерә: аларның барысында да кеше үзенә, якыннарына, туганнарына үзенең изге теләкләрен юллый, Алладан бу кешеләргә итагатьле, шәфкатьле, иманлы, әхлаклы булып яшәргә юл күрсәтүен, мәрхүмнәрнең рухларын шат итүне, урыннарын җәннәтле итүне, гөнаһларын ярлыкауны сорый. Аларда халыкның, кешелекнең иң зур кыйммәтләре турында карашлары саклана. Бу – гаделлек, кешелеклелек, ярдәмчеллек, юмартлык, тугрылык, тырышлык, белемгә омтылыш, инсафлылык, олы җанлылык кебек әхлакый сыйфатлар.

Барыбызга да изге теләктә, яхшы уй-фикердә булып яшәргә язсын.

**АЛКЫШ АЛГАН – АРЫМАС...**
(Татар фольклорының алкыш жанры)

Татар фольклорында бүгенгә кадәр аз өйрәнелгән, яки әлегә кадәр галимнәрнең игътибарыннан читтә калып килгән жанрлар бар. Шундый жанрларның берсе – алкышлар. Бу жанрга караган әсәрләр татар паремияләре составында фольклор җыентыкларына кертелсә дә, әлегә кадәр алкышлар аерым фәнни тикшерү объекты булмады. Бу жанр татар фольклорында, башка төрки халыклардагы шушындый эчтәлекле әсәрләр кебек үк, алкыш термины белән атала. Шулай ук телдә «теләк», «изге теләк» дигән гыйбарәләр дә очрый. Контексттан чыгып, «хәер-фатиха» терминының да алкышка туры килүе күзәтелә. Хәер-фатиха, бер яктан, өлкән, хөрмәтле кешенең зур эшкә, мәсәлән, гаилә корырга, яңа эш башларга, яшәү урынын алыштыруга, күчеп китүгә һ.б.га рөхсәтен аңлатса, икенче яктан, шушы эш-гамәлгә бәйле изге теләкләр, дога да. Алкышлар берничә сүздән генә торган кыска текстлар да, берничә строфадан торган шигъри әсәрләр дә булырга мөмкин. Гаилә йолалары вакытында башкарылган арбау жанры да эчтәлеге һәм функциясе белән алкышларга якын.

Алкышларның нигезендә сүзнең магик көченә ышану, яхшы сүз ярдәмендә кешенең тормышына уңай тәэсир итәргә омтылыш ята. Татар халкында «Кеше теләге кешегә кабул була, ди» дигән ышану да бар. Алкышлар борынгы жанрлардан булып, аларның текстларында яки башкарылуына бәйле мәҗүсилек чорына караган элементлар саклана. Татар халкы ислам кабул иткәннән соң алкыш текстларында ислам дине белән бәйле образлар, мифологик ышанулар урын ала.

Бу текстлар төрле шартларда һәм вакыйгаларга, эш-гамәлгә, йолаларга бәйле рәвештә башкарыла. Башкарылу үзенчәлегенә карап татар фольклорында һәм телдә сакланып калган алкышларны төп ике төргә бүләргә мөмкин. Беренче төр алкышлар көнкүрештә башкарыла, дөресрәге әйтелә. Бу

алкышлар күләмнәре белән кечкенә, берничә сүздән тора. Әмма, кагыйдә буларак, алар тотрыклы, үзгәрми торган текстлар. Үзгәрә ала торган текстлар да аерым кагыйдәләргә буйсына. Икенче төр алкышлар календарь яки гаилә-көнкүреш йолалары составында башкарыла торган текстлар. Күпчелек очракта алар берничә юлдан торган тезмә әсәрләр.

Хәзерге вакытта көндәлек тормышта әйтелә торган алкышларны үзләрен дә ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренчесе берәр вакыйга, эш-гамәлгә бәйле рәвештә изге теләк рәвешендә әйтелсә, икенчеләре берәр гамәлгә яки бүләккә каршы рәхмәт буларак әйтелә. Беренче төргә караган, татар халкында еш кабатлана торган алкышларга түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин.

Эш белән бәйле текстлар кешенең ниндидер эш эшләгән вакытында туры килгәндә әйтелә. «Алла куәт бирсен!» яки «Алла ярдәм итсен!» «Җиңеллеген бирсен!» Эшләүче кеше җавап буларак рәхмәт әйтә, «Сине дә безгә бирсен!» кебек шаярып әйтелгән җавап та очрый. Татар телендә «Алкыш алган арымас» дигән мәкаль бар. Ул хезмәткә нисбәттә әйтелә торган текстларның магик көченә ышануны күрсәтеп тора.

Кешенең өенә кереп аш вакытына туры килгән кеше «Ашыгыз тәмле булсын!», «Чәегез тәмле булсын!» дигән теләк әйтә. Җавап рәвешендә «Бергә булсын!» дип килгән кеше дә табынга чакырыла. Татар халкында чит кеше өенә кергәннән соң, йорт хуҗаларына изге теләкләр теләп дога кылу күренеше соңгы ун-унбиш ел эчендә юкка чыгып бара. Егерме ел элек татар өенә кергән кунак, исәнләшкәннән соң, «Ягез, бер дога» дип өй хуҗалары белән утырып дога кыла, бу йорт хуҗаларына теләк тели, шуннан соң гына йомышын әйтә иде. Кунаклар өстәл яныннан торганда да, ризык-сый өчен рәхмәт әйтеп, дога кылалар, теләк телиләр. Бу теләкләр шактый күләмле тексттан гыйбарәт. Анда йорт хуҗаларына, балаларына бәхет, иминлек, малларының артуы кебек теләкләр бар.

2016 елгы экспедиция вакытында Алтай өлкәсе Угловский районы Бөкер авылында Баһавиева Фатыйма Нургата кызыннан берничә алкыш язып алынды. Хәзерге вакытта бу текстлар

татар фольклор җыентыкларында теркәлмәгән булу сәбәпле, аларны тулысынча бирәбез.

### Алкышлар

Гомерлек мәхәббәт бирсен,
Бетмәс дәүләт бирсен,
Акылларыгыз ашсын,
Бәхетләрегез ташсын,
Һич яманлык булмасын!
Аман булсын йорт-җирләгез,
Алла Тәгалә диннәрегезгә саулык бирсен,
Дәстәрханегезгә байлыгын бирсен!
Ахирәттә иман бирсен,
Терелектә тәүфикъ бирсен,
Бирәхмәтикә
Йә әрхәмәр рахимиин.
Илаһи, амин! Илаһи, амин!
Аллаһ әкбәр, амин,
Аллаһ әкбәр, амин!

Чәегез кызыл булсын,
Гомерегез озын булсын,
Дәүләтегез таша бирсен,
Дошманыгыз кача бирсен!
И ходаем, үзегезгә озын гомер яза бирсен.
Илаһи, амин! илаһи, амин!
Аллаһ әкбәр, амин,
Аллаһ әкбәр, амин!

Бисмилла ирахман ираһим,
Йа раббы Ходаем,
Безнең хушыбызга керешеп,
Безнең арабызда йөрерлек булсын!
Йа рабби Ходаем,
Тынычлык белән, хәерле ризык белән,
Хәерле тормыш белән,
Йа рабби үзләребезгә,
Мал туарларыбыз аман булып,

Йортларыбызга сәламәтлек биреп,
Сабырлык белән яшәргә насыйпка ирештерсен!
Илаһи, амин!Илаһи, амин!
Аллаһүммәгъфирли,
Фәгъфирли,
вәли-вәлидәйнә,
вәли җәмигол мөэмининә
вәл мөэминәт,
вәл мөслиминә вәл мөслимәт,
вәл моңзиләл бәрәкәт,
вә рафигад-дәрәҗәт,
вә казиел-хәҗәт.
Амин.
Бирәхмәтикә йә әрхәмәр рахимиин. Илаһи, амин
Илаһи, амин, илаһи, амин!
Аллаһ әкбәр, амин,
Аллаһ әкбәр, амин!

Татар халкы Ислам динен рәсми рәвештә X гасырда кабул итә. Шул вакыттан белем бирү системасы формалаша, мәктәп-мәдрәсәләр ачыла. Мәдрәсәдә, матди хәленең ничек булуына карамастан, һәр бала белем ала. Халык укуга бит җитди карый, шул ук вакытта гарәп теле язуын үзләштерү, мәдрәсәдә белем алу балага да җиңел бирелмәгән. Татар халкында баланың шушы авыр бурычын изге теләк ярдәмендә җиңеләйтүгә юнәлтелгән алкышлар, теләкләр формалашкан. Бу төр алкышларга түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: «Ходай тел ачкычлары бирсен!», «Укытучыларың/остазларың күзенә сөйкемле күрен!», «Башыңа зиһен бирсен!». Шунысын да әйтеп китү урынлы, әлеге текстлар хәзер дә актив кулланылышта.

Алкышларның бер төре бүләк өчен җавап рәвешендә рәхмәт урынына әйтелә. Ягъни кеше үзенә карата эшләнгән яхшылыкка яки үзенә бирелгән бүләккә каршы алкыш әйтә. Бу очракта алкыш җавап бүләкнең/рәхмәтнең эквиваленты булып тора. Мәсәлән кешегә эш белән ярдәм өчен «Аяк-кулың сызлаусыз булсын!» дигән теләк әйтелә.

Эш өчен рәхмәт әйтеп башкарылган алкыш мисалы татар халкының «Ак Көбек» дастанының бараба вариантында сакланган. Ак Көбек үзенә корал ясаган остага рәхмәтен алкыш белән белдерә:

Торга пүтсүн бу җирдән-әй!
Камга пүтсүн бу җирдән-әй!
Ишегеңнән тәк иңсен-әй!
Төнлегеңнән тәк төшсен-ай!
Адың-елгыс бай булсын!
Баеп-череп үлерсең![1]

(Затлы ефәк булсын бу җирдән-әй!
Кытай ефәге булсын бу җирдән-әй!
Ишегеңнән бәхет иңсен-әй!
Төнлегеңнән бәхет төшсен-әй!
Атың-елкың бай булсын,
Баеп-череп үләрсең!)

Ярдәм күрсәтүченең яшь үзенчәлекләре, гаилә хәле һәм башка яклары истә тотылып, һәр конкрет очракка туры килгән теләкләр дә әйтелә. Мәсәлән, балага карата «Тәүфикълы бул, тигез канатлы – ата-аналы булып үс!» дигән теләк, уку яшендәге бала өчен алдарак әйтелгән теләкләр әйтелсә, гаилә кору яшенә чыкканнар өчен «Хәләл ана сөте эчкән яр насыйп булсын! «Тигез мәхәббәт бирсен!» дигән теләкләр бар.

Пермь краенда узган экспедиция вакытында алкышларның тагын бер төре язып алынды. Аларны информант «әби-бабайның тиргәшкәне» дип атый. Алар баланың берәр ярамаган эшен күргәндә, кисәтү урынына да башкарылырга мөмкин. Аларда да сүзнең магик көченә ышану ята:

– Әй, кызым, балам, бәхетең арткыры, акча тапкыры, сөйкемле булгыры, телең баллы булгыры.

---

[1] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Часть IV.Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменьских татар. СПб., 1872. С. 48.

Бу алкышларның кешегә яки гаиләгә байлык, иминлек теләгәннәре дә бар:

– Икмәгең чапчагыңнан артып чыккыры, мичтә ипиең кызарып пешкере, айраның күп булгыры, сыерың сөтле булгыры, ике бозау тапкыры[1].

Хәзерге вакытка кадәр яхшы хәбәр китерүчегә, яхшы сүз әйтүчегә карата «авызыңа бал да май» дигән алкыш әйтәләр.

Бу карап узган алкышлар көнкүрешкә, көндәлек тормышка бәйле рәвештә әйтеләләр. Алар җыйнак текстлар. Шартлы рәвештә бу тектсларны көнкүреш алкышлары яки теләкләр дип атарга мөмкин. Көнкүреш алкышлары ритуал-йолалар вакытында да кулланыла, алар универсаль әсәрләр. Икенче төр алкышлар аерым йолаларга бәйле рәвештә башкарыла. Алар күләмнәре белән зуррак, тотрыклы шигъри текстлар. Аларны шартлы рәвештә йола алкышлары дип аерабыз. Аерым йола белән бәйле алкышлар, бары шул йола вакытында гына башкарыла.

Йола алкышлары төрле йолалар, гореф-гадәтләр, ритуаллар вакытында башкарыла. Календарь йолалар белән бәйле алкышлар аерым кешегә генә түгел, илгә, халыкка имин тормыш теләүгә юнәлтелгән.

Мәсәлән, Нәүрүз, Нардуган, Карга боткасы кебек календарь бәйрәмнәрдә, һәр йортка кереп, бәйрәм боткасы өчен ризык җыючылар рәхмәт урынына алкыш әйтәләр:

Мал-туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннәрегез уңсын,
Күкәй кебек тук булсын![2]

Гаилә йолалары вакытында башкарыла торган алкышлар да бар. Яңа туган балага, яңа гаилә коручыларга атап әйтел-

---

[1] Пермь крае Уин районы Чәйкә авылында Әҗмуханова Фәйхунә Шаһинур кызыннан (1940 елгы) язып алынды.

[2] Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче И.Н. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. Б. 46.

гән алкышларда аларга бәхетле имин гомер теләнә. Яңа туган балага иң еш әйтелә торган алкыш «Тулы бәхете, тәүфигы, үз ризыгы белән килсен!». «Кешене ризыгы йөртә» дигән мәкальдән аңлашылганча, татар халкында ризык ашамлык мәгънәсендә генә кулланылмыйча, язмышны да аңлата. Шулай ук баланың тәрбияле булуын, әхлак ягыннан камил кеше булып үсүен, ягъни тәүфикълы булуын телиләр.

Туй йолаларында яшьләргә тигез мәхәббәт, тигезлек, күп бала телиләр: «Ал итәгеңне бала бассын, арт итәгеңне мал бассын!» Туй йолалары вакытында башкарыла торган арбау жанры да эчтәлеге белән алкышларга якын. Арбаулар сүз ярдәмендә киленне яңа йортына бәйләү өчен башкарылган. Аларда да киленгә, яңа гаиләгә бәхет теләнә:

> Төкле аягың белән, таймас кулың белән,
> Таймас табаның белән кил!...
> Эшең, көнең уң булсын,
> Ашың, суың мул булсын![1]

Арбауларның алкышлардан аермасы шунда, аларның нигезендә магиягә басым ясала, сүз ярдәмендә кешенең тормышына магик тәэсир итәргә омтылыш ята.

Алкышлар татар фольклорында шактый күпсанлы жанр булса да, алар бүгенгә кадәр махсус өйрәнелмәгән. Аерым текстлары язып алынган очракта да, алар башка жанрлар (мәсәлән, йола фольклоры) составында гына язып алынган. Соңгы елларда узган экспедицияләр бу жанрга караган әсәрләрнең хәзер дә телдә саклануын күрсәтә. Алкышларны, башкарылу үзенчәлегенә карап, шартлы рәвештә көнкүреш һәм йола алкышларына бүләргә мөмкин. Бу жанр халыкның менталь кыйммәтләрен ачыклау ягыннан да, милли этикетны өйрәнү өчен дә әһәмиятле чыганак булып тора. Алкышларда җәмгыять һәм гаилә кыйммәтләре, гомумешелек өчен мөһим әхлакый сыйфатлар алга чыга.

---

[1] Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. Б. 158.

## АРЫ УТЫРЫҢ, ИНӘЛЕКЛӘР

(Татар фольклорында кендек әбиләре образы)

Татар халкының әниләр һәм әбиләр белән бер дәрәҗәдә хөрмәткә лаек, бөтен кеше тарафыннан олылана, хөрмәтләнә торган кендек әбиләре турында хәзерге вакытта белүчеләр азая бара. Шактый четерекле тема буларак, бу мәсьәлә шактый вакыт фольклорчылар игътибарыннан да читтә калып килгән. Татар халкының кендек әбиләре турында мәгълүмат диалектолог Флера Баязитова хезмәтләрендә тупланган. Шулай ук бу мәкаләне әзерләгәндә татар язучылары документаль характердагы әсәрләрендә сакланган мәгълүматларга мөрәҗәгать итәргә туры килде. Татар фольклорчыларының бала багу фольклорына багышланган хезмәтләрендә, балалар фольклоры җыентыкларында да кендек әбиләре әйтә торган тотрыклы шигъри яки чәчмә текстлар урын алган. Үзебез катнашкан экспедицияләр вакытында язып алынган материаллар да бу теманы ачарга ярдәм итте.

Гасырлар дәвамында аналарга бала тудыру вакытында ярдәм күрсәтүче, баланы кабул итүче кендек әбиләре булган. Алар, кагыйдә буларак, өлкән яшьтә булып, бу һөнәрләр буыннан буынга, анадан кызга күчкән. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә кендек әбиләрен төрлечә атыйлар: кендек әби, мамай, кендекче, инәкә мама, инәкә әби, кендек мама, бахсы, кендегәч карчык, корткааяк, кентекләгән мамай, аппай корткаяк, инәкә, инәлекколака, колагинә һ.б. Шунысы да бар, бала табучы хатын өчен кендек әби булса, шушы әби ярдәмендә туган бала өчен ул кендек әни булган. Ягъни кендек әби ярдәмендә туган бала аны әнисе кебек якын күргән.

Хәзерге көнгә кадәр халыкта кендек әбиләре турында истәлекләр саклана, алар ярдәмендә бала тапкан хатыннар, үзләренә ярдәм иткән кендек әбиләрен яхшы сүз белән искә ала. Тәҗрибәле кендек әбиләре баланы бик җиңел таптырган, катлаулы очракларда, бала дөрес килмәгәндә дә, кендек

әбиләре ананың да гомерен саклап, баланы да имгәтмичә тудырырга ярдәм итә белгәннәр. Татар халкында баланы кендек әбиләр ярдәмендә өйдә тудыру күренеше XX гасырның урталарына кадәр дәвам итә. 1960 елларда, бер яктан, авылларда фельдшер-акушерлык пунктлары ачылу аркасында, икенче яктан, кендек әбиләренең эшчәнлеген тыю нәтиҗәсе буларак бу күренеш юкка чыга.

Татар фольклорында һәм әдәбиятта кендек әбиләре турында төрле мәгълүмат табарга мөмкин. Россиянең төрле регионнарында яши торган татар халкының риваять-легендаларында, истәлекләрдә кендек әбиләренең осталыгы, эшләрен яхшы белүләре, табиблык осталыклары бәян ителә.

Хатын-кыз балага авырый башлауга, өйдәгеләрнең берсе кендек әбисен чакырырга йөгергән. Кагыйдә буларак, кендек әби бала дөньяга киләсе вакытны якынча белеп, булачак ананың хәлен белеп тә торган. Авырлы хатыннарның үзе теләгән кендек әбиләре белән алдан сөйләшеп кую да булган. Кендек әби беркайчан да, бер кешегә дә ярдәм итүдән баш тартмаган.

Кендек әбиләренең бәби туачак өйгә кергәндә, бала туган вакытта, баланы биләгәндә әйтә торган тотрыклы шигъри текстлары, сүзләре булган. Күп төрле йолалар башкарылган. Бу йола һәм текстларны башкаруның максаты – ананың баласын исән-сау, җиңел табуын теләү, баланың таза-сау, бәхетле булып тууын тәэмин итәргә омтылу, ана белән баланы кара көчләрдән, сихердән саклау була.

Кендек әбиләрнең бала туасы йортка кергән вакыттан бөтен гамәлләре аерым ышанулар, йолалар, тыюлар кысаларында бара. Кендек әби ишектән кергәндә үк төрле такмаклар, сүзләр әйтеп, аерым бер ырымнар башкарып кергән. Инәлекләр бусагадан кергәндә бисмилла әйтеп:

> Шайтаннар ияреп кермәсен,
> Шайтаннар-майтаннар кермәсен,
> Җен-мазар кермәсен, –

дип атлап кергәннәр[1].

---

[1] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2010. Б. 184.

Кендек әбиләр ишектән кергәндә күлмәк итәкләрен җилпеп кергәннәр:

Бисмилли, бисмилла,
Җен булмасын,
Җиңеллек булсын,
Озын гомерле булсын[1].

Кайбер кендек әбиләре бусагадан атлаганда шырпы сызып, ут яндырып атлаганнар, утны «җен үтмәсен» дип үзләренең аяк арасыннан да уздырганнар. Бала табучы хатын янына шул рәвешле ут белән чистарынып кергәннәр.

Бу – татар халкының яңа туган баланы җен алыштыра дигән ышануы белән бәйле. Татарлар баланы кырык көнгә кадәр ялгыз калдырмыйлар. Татар халык иҗатында җен алыштырган балалар турында әкиятләр, легендалар бар.

Кендек әби тулгагы башланган хатынга бал каптырган, аның биленә массаж ясаган. Шул рәвешле хатын-кызның организмы бала тудыруга әзерләнгән.

Бала озак тумый торса, кендек әбиләре төрле ырымнар башкарган. Мәсәлән, хатынның чәч толымнары сүтелгән, иренең чалбарын идәнгә салып, хатынны чалбар өстеннән атлатканнар, ишекне ачып:

Кысылдым, кысылдым,
Алла, бушат, кысылдым[2], –

дип кычкыра торган булганнар.

Фольклорда кендек әбиләренең ана карынындагы туачак бала белән сөйләшүе тасвирлана. «Ак Күбек» дастанында кендек әбиләре – инәлекләр туарга теләмәгән баланы дөрес туарга үгетлиләр. Алар тиешенчә дөньяга килергә теләмәгән Ак Күбеккә, дөрес туган очракта алтын-көмеш бишекләр вәгъдә итәләр.

---

[1] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Б. 183.

[2] Шунда ук. Б. 181.

Алтын бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне,
Көмеш бишеккә бер салып
Биләр идек Көбәйне[1].

Дастанның икенче вариантында Ак Күбек үзе инәлекләргә мөрәҗәгать итә:

Ары ултырың, инәлекләр,
Бире ултырың, инәлекләр![2].

Бу мотив та күпмедер дәрәҗәдә чынбарлыкны чагылдыра. Кендек әбиләре туачак бала белән сөйләшкәннәр, тәмле тел белән аны туарга үгетләгәннәр.

Бала тугач кендек әби баланы игътибар белән тикшергән. Бала тугач та тавыш бирмәсә, баланы түбәндәгечә им иткәннәр: кендек әби баланы аякларыннан учлап йөзтүбән тоткан да, артына суккан. Икенче кеше бу вакытта чүмечкә сугып тавыш чыгарып торган. Шуннан соң бала кычкырып, елап җибәргән[3]. Бала хәлсез туса, аны догалар укып өшкергәннәр.

Мари Элның, Бәрәңге бистәсендә яшәүче Г. Габидуллина кендек әбиләрнең балаларны тергезеп җибәрүенең тагын бер ысулын яза: « Зәгыйфь туган баланы кендек әбисе җилпучка (он или торган озынча агач җайланма) салып, догалар укып, җилпеп, бераз эссесе сүрелгән мичкә тыгып ала торган булган. Җылыда изрәгән баланы сарык тиресенә төреп, ана куенына салган. Бу балалар арасыннан хәтта көрәшчеләр дә чыккан»[4]. Җитлекмичә туган балаларны толып җиңендә үстерүләре хакында истәлекләр хәзергә кадәр очрый.

Кендек әби баланың кендеген кискән. Кисеп алынган өлешен – кендек бавын беркайчан да ташламаганнар. Аны төреп, кеше кулы тими торган җиргә кыстырып куйганнар, еш

---

[1] *Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной сибири и Дзунгарской степи. Ч. IV. СПб., 1872. С. 45.

[2] Шунда ук. С. 143.

[3] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Б. 172.

[4] *Габидуллина Г.* Кендек әбиләре // Безнең гәҗит 2012, № 11 (21 март).

кына сандыкта, иң кадерле әйберләр янында да саклаганнар. Балага күз тисә, авырса, еласа, шуны чайкап суын эчергәннәр. Кендекнең туган йортта булуы саклануы шушы йортка бәйләп тора дип ышанганнар. Татар телендә «Кендек каны тамган җир» дигән гыйбарә дә туган җир белән бәйләнешне аңлата. Кендек каны, кендек бавы кешене шушы җиргә бәйли. Татар шагыйрәсе Эльмира Шәрифуллинаның «Кендек әбекәем» дигән шигырендә нәкъ шушы ышану турында сүз бара:

...Бәби тоткан кендек әбекәем
Ераклашкан саен – янәшә.
Кендекләрне кистең,
Җиргә тектең –
Истәлеккә күчеп, мең яшә!

Кендек әбисе яңа туган баланы юындыргач, беренче эш итеп, аны атаның иске күлмәгенә төргән. Бер үк киемгә мөнәсәбәт аша ата белән бала арасында якынлык, мәхәббәт көчле була дип ышанганнар.

Кендек әбиләре туган балага беренче булып бәхет-тәүфыйк теләгәннәр. Бала тугач та авызына бал-май тигезү йоласы «баланы авызлыкландыру» дип атала. Тәмле телле булсын, ризыклы-бәхетле булсын өчен баланың ирененә бал белән май тидерәләр. Бу бала аш-сулы булсын, ризыклы булсын, тормышы татлы булсын дип башкарыла торган ырым. «Ипитозлы, тәмле телле бул, әти-әниле, тигез канатлы бул» дип теләк теләгәннәр. Кайбер төбәкләрдә баланың ирененә тоз да тидергәннәр. Бу дөньяның төрле чагы була, җебегән, юаш булмасын, дип теләгәннәр. Бу очракта

Усал булсын,
Эшкә батыр булсын,
Бәхетле булсын,
Каршы килгәнгә
Күкрәге белән бәрелсен![1]

дип теләгәннәр.

[1] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Б. 193.

Шуннан соң баланы әнисенә имезергә биргәннәр.

Кендек әби соңгылыкны да юып җиргә күмгән. Соңгылыкны кеше аягы басмый, мәче-эт тими торган җиргә күмгәннәр. Бала соңгылыкны киеп, яки битлек белән туса, аны, киптереп, гомер буе саклаганнар. Битлекле бала бик күз тиючән була дип, аның белән баланы имләгәннәр дә.

Бала тудырган вакытта хатын-кызның һәр буыны, һәр сөяге урыныннан кузгала дип, кендек әби аңа да зур игътибар биргән. Бала тугач «Бәби мунчасы» якканнар. Бу мунчада кендек әби баладан котылган хатынны мунча керткән. Анда хатынның буыннарын сылап, һәр әгъзасын урынына утырткан.

Эльмира Шәрифуллинаның «Бәби мунчасы» шигырендәге кендек әбинең шушы вазифаны башкаруы сурәтләнә:

Буыннарны сылап, сөеп,
Сыйпап оеш каннарны.
Мунча кертәләр әбиләр
Җан тудырган җаннарны.

Ананы юындырганнан соң, кендек әби шул ук мунчада яңа туган бәбине дә юындыра. Бу очракта да бәби мунча кертү гади юындыру гына түгел. Кендек әби баланың һәр буынының-сөягенең урынында булуын тикшергән. Берәр кимчелеге , мәсәлән, баш формасы дөрес булмаган очракта, юындырган вакытта, сыйпап-сылап, ул дөрес формага кертелгән. Мунча керткән вакытта балага теләк теләнгән, догалар укыганнар.

Эльмира Шәрифуллинаның «Бәби мунчасы» шигырендә бу эпизод та чагыла:

Мунча кертәләр әбиләр,
Укыйлар теләк-дога.
Шуңадырмы авыллардан
Рәхимле җаннар чыга.

Бала изге дога, изге теләкләр ишетеп үссә үзе дә тәртипле, затлы кеше булып үсә.

Кендек әбинең мунчада баланы юындырганды әйтә торган шигъри текстлары да бар:

Дәү бул, бай бул,
Тәүфикълы, талигалы бул,
Чыршыдай озын бул,
Нараттай кызыл бул,
Имәндәй таза бул,
Суы сарыксын,
Үзе калыксын![1]

Балага җен-пәри кагылмасын дип, аларны бутау өчен аның кем баласы икәне яшерелгән дә:

Атаң кискән утын түгел,
Анаң яккан мунча түгел,
Аюдай ага бул,
Бүредәй бөгә бул.
Аю баласы,
Бүре баласы,
Суы сарыксын,
Үзе калыксын![2]

Яки:

Әбине «әби» дип әйт,
Бабайны «бабай» дип әйт,
Аю кебек симез бул,
Бүре кебек җитез бул[3].

Кендек әби балага исем кушу мәҗлесендә кадерле кунак булган.

Баланы беренче тапкыр юындырганнан башлап, аны юуындырыр өчен 40 көн дәвамында мунча ягылган, һәм һәр көнне кендек әбисе килеп баланы юындырып киткән. Шул ук вакытта кендек әби баланы юындырып кына калмаган, баланың баш формасында, кул-аякларында, аркаларында җитеш-

---

[1] Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры / төзүчесе Рәшит Ягъфәров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 31

[2] Шунда ук. Б. 28.

[3] Шунда ук. Б. 28.

сезлекләр булганда, алар да массаж һәм мунча ярдәмендә дәваланган, урынына утыртылган.

Татар халкында һәрбер кеше үзенең кендек әбисен белгән. Хәрби хезмәткә китүче егетләр кендек әбиләре белән саубуллашырга кергән. Кайткач, исәнләшү дә мәҗбүри булган. Кендек әбигә бәйрәмнәрдә күчтәнәчләр китергәннәр. Ул һәрбер өйдә кадерле кунак булган.

Татар әдәбиятында кендек әбиләре образлары әледән-әле яңартыла. Әдипләр бу образ аша татар хатын кызларының асыл сыйфатларын да, туган туфракка мәхәббәтне дә, буыннар бәйләнешен дә бирәләр.

Кендек әбиләренең татар тормышында тоткан урыны Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» повестенда яктыртыла. Документаль әсәрдә кендек әбиләренә аерым бүлек багышланган. «Берәү улдан – берәү кыздан» дигән бүлектә авторның авылдашлары Газзә һәм Гайшә исемле кендек әбиләрнең тормышы һәм эшчәнлеге яктыртыла. Бу хезмәткә махсус тукталуыбыз очраклы түгел. Татар халкының иң популяр язучыларыннан булган Мөхәммәт Мәһдиев әдәбият һәм фольклор галиме дә. Язучының бу әсәрләре халыкның рухи дөньясын, гореф-гадәтләрен өйрәнү өчен бай материал да булып тора. Автор кендек әбиләренең үзе таптырган һәр баланы белүләрен, аларның тәртипләре, ничек үсүләре, яшәүләре белән кызыксынып торуларын яза. Бу – кендек әбиләренең үзләре таптырган балалар өчен үзләрендә җаваплылык хисе тоюларын күрсәтә. М. Мәһдиев үзенең кендек әбисенең Газзәтти (Газизә түти) урамда балалар белән очрашуын түбәндәгечә сурәтли:

«Һәркем белән исәнләшә, һәр бала янында туктый. Инде урамда мине очратса, башымнан бисмилла әйтеп сыпыра да елап җибәрә:

– Тәүфыйклы булып үс, балам, анаң сине бик авырлык белән тапты, дип яшь коя»[1]. Кендек әбисе шул рәвешле баланы

---

[1] *Мәһдиев М.С.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. 3 т.: повесть, роман. Казан, 2009. Б. 118.

тәртипле булырга, әнисен кадерләргә, аның кадерен белергә чакыра. Авылдагы икенче кендек әби Гайшәтти. Бу әби дә авылдагы һәр баланы белә, күзәтеп яши. Автор кендек әбисенең балалар белән сөйләшүен болай тасвирлый: «Аннан Гайшәтти дөньяга чыгарга үзе виза биргән балаларны сөя.

– Син ни атлы әле? (Безнең авылда карт-карчык беркайчан да «ни исемле» дип сорамады.) Ә-ә, шулай шул, мин әле онытканыем. Сиңа, бәбекәем, арыш урагы җитсә ун тула инде... Ә менә монысының исемен беләм. Зәйнагытдин. Сөннәткә утырттыгызмы әле? Бик яхшы, бик яхшы, улым. Каз суйганда сиңа да җиде тула бит инде»[1]. Кендек әбиләре үзе әбилек булып, тудырганда ярдәм иткән малайларны «кендек малаем», кызларны «кендек кызым» дип йөртәләр. Димәк алар үзләре туарга ярдәм иткән баланы үзе баласы кебек күргән.

Мөхәммәт Мәһдиев кендек әбиләре ярдәмендә дөньяга килгән балаларның игелекле булып үсүен, аларның бу дөньяга килү шартлары белән бәйләп карый.

Татар фольклорында кендек әбиләренә багышланган әсәрләр бар[2]. Мәсәлән, кендек әбиләренең җеннәргә дә әби булуы турындагы легенда татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә мәгълүм. Аның дистәләгән варианты билгеле. Россиянең төрле төбәкләрендә узган экспедиция вакытында язып алынган бу әсәрләр белән сезне дә таныштырып китәргә телибез. Легендаларда кендек әбиләренең җен яки пәри хатынына бала табарга ярдәм итүе турында сүз бара. Бу риваятьнең төрле вариантлары төрле регионнарда язып алынды. Шундый риваятьләрнең күпсанлы вариантларын Себер татарларыннан язып алдык. Беренче варианты Төмән өлкәсе Вагай районы Казанка авылында яшәүче Шәрәфетдинова Алия Әйтмөхәммәт кызыннан язып алынды. Информант аны чынбарлыкта, үзенең әбисе – Мәймүнә исемле хатын белән бәйле вакыйгага бу-

---

[1] *Мәһдиев М.С.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. 3 т. Б. 121.

[2] Автор тарафыннан Россиянең татарлар компактлы яшәгән төбәкләренә экспедицияләр вакытында язып алынган, авторның шәхси архивында сакланган материаллар файдаланылды.

ларак бәян итә. Риваятьнең кыскача эчтәлеге болай: Мәймүнә Уфадан була. Ул заманының укымышлы хатыннарыннан саналып, бөтен тирә-якка инәлек була. Бервакыт аны пәринең ире килеп ала. Инәлек бер кемгә дә ярдәм итүдән баш тарта алмый. Барырга тиеш була. Бала тугач, баланы юындырырга су булмый. Инәлеккә сөт бирәләр. Инәлек сөт савытының үзенеке булуын таный, сөткә йөзеген сала. Пәринең ире инәлекне кире өенә илтеп куя. Сөт савыты үзенең урнында була. Инәлек өендә сөт эченнән йөзеген ала. Шул барганда инәлек пәри хатынының йонын йолкып кайта. Бу йонны такыясына (баш киеменә) тегеп куя. Шул вакыттан ул инәлек булган бер хатын да, бер бала да үлми. Ул бөтен авыруларны да дәвалый башлый.

Бу риваятьтән күренгәнчә, инәлекләрнең осталыгы гади тәҗрибә белән генә аңлатылмый, халык инәлекләрнең сихри көчкә ия булуына да ышана. Бу очракта аның көче инәлекнең пәриләр, ягъни башка дөнья вәкилләре белән бәйләнеше аша килә. Пәринең йоны, ягъни икенче дөньяга караган предмет хатынга сихри көч бирә. Кендек әбиләрен икенче дөнья белән бәйләнештә карау очраклы түгел. Кендек әбисе үзенең функциясе белән дә ике дөнья арасында арадашчы ролен үти, балага ике дөнья арасындагы чикне үтәргә ярдәм итә.

Бу риваятьнең функциясе, бер яктан, кендек әбисенең осталыгын мактау, аның гадәти булмаган көчен бәян итү булса, икенче яктан, ул татар халкының тагын бер инануы белән бәйле: мәсәлән, бер генә ризыкны да, суны да, сөтне дә өстен япмыйча калдырырга ярамый дигән ышану бар. Өсте ачык калган ризыкны пәри ялый, мунчада суның өсте ябылмыйча калса, җеннәр юына, сөт өсте ачык калса, пәри баласын юа дигән ышанулар, бер яктан, чисталыкка-пөхтәлеккә өндәсә, икенче яктан, төрле стихияләр арасында чикләрне билгели. Ят дөньяларны һәм аларның вәкилләрен хөрмәт итәргә, үз дөньяңны сакларга өйрәтә. Шул рәвешле авырулардан саклану чараларын күрсәтә.

Әсәрнең икенче варианты да шушы ук авылда язып алынды. Бу очракта кендек әбисенең баланы юганда күрше хатынының сөт савытын тануы һәм үзенең йөзеген салуы тасвирлана.

Шушы ук риваятьнең тагын ике варианты Татарстанның Балтач һәм Кама Тамагы районнарында язып алынды. Балтач районы информанты Фасихов Наил Шамил улы да аны үзенең әбисенең әбисе – авыл халкы атаганча, Сәйфетдин Фатыймасы белән бәйле вакыйга буларак бәян итә. Мәгълүм эчтәлек бу юлы да кабатлана. Кендек әбисе җен хатынына кендек әбисе булырга алып китүләрен, җен баласын сөт белән юуын сөйли. Чынлап та, бер хатынның өсте ябылмаган чиләгендәге сөт канлы була. Кама Тамагы районында язып алынган вариантны да информант Хәбибуллина Нәсимә үзе белгән кешеләр белән бәйле вакыйга буларак бәян итә.

2015 елгы Томск өлкәсендә узган экспедиция вакытында бу риваятьләрнең тагын берничә варианты язып алынды. Аларда кендек әбисен чәй өстәленә чакырулары, чанага утыртып алып китүләре кебек детальләр өстәлә.

Әсәрнең төрле регионнарда популяр булуы, аның барлык кендек әбиләренә карата да сөйләнүен күрсәтсә кирәк. Алар кендек әбиләренең профессиональ осталыкларын күрсәткән; бала табучы хатыннар аларга ышансые өчен, бала табучыны да, кендек әбиләрен дә психологик яктан әзерләгән, бу үз чиратында ананың да, баланың да исәнлеген-иминлеген тәэмин иткән. Шул рәвешле бу легенда кендек әбиләренең белгечлеген, бу эшкә алынуының дөреслеген раслаган диплом яки сертификат ролен үтәгән.

Кендек әбиләренең тагын бер вазифасы турында әйтми калсак, әлеге тема ачылып бетмәс иде. Бу – әбиләрнең хатын-кыз табиблары вазифасын да башкаруы. Кендек әбиләре төрле авырулар вакытында хатын-кызларга сылап, өшкереп ярдәм иткән. Балага уза алмаган хатын-кызлар да кендек әбиләренә мөрәҗәгать иткән. Алар баласыз хатыннарны сылап-дәвалап ана булу бәхетенә ирештергән. Кендек әбиләре хатын-кызга «эчләре төшкән» вакытта «чүлмәк салган». Чүлмәк салу эчне генә күтәреп калмаган, эчке органнарның эшчәнлеген дә яхшыртып җибәргән. Кендек әбиләренең сулышы да шифалы дип ышанганнар. Әлбәттә, бу ышану хатын-кызларга тизрәк аякка басарга ярдәм иткән.

Хәзерге вакытта кендек әби вазифасы юкка чыкты. Әмма алар турында истәлекләр исән. Кендек әбиләре турында риваятьләр-легендалар сөйләнә. Аларның рухына дога кылалар. «Инәлек килеп керсә, өйдәге матча да иелеп китә» дигән татар халык мәкале кендек әбиләренең изгеленә ишарә ясый[1].

Кендек әбиләре баланы бик җайлап-көйләп кенә тудырган. Бала туган минутыннан бу дөньяга чит түгеллеген, кирәкле һәм кадерле булуын тойган. Кендек әбиләре тудырган бала кешелекле, мәрхәмәтле, тырыш шәхес булып үскән. Бары шушы тәҗрибәне генә саклар өчен дә кендек әбиләренең эшчәнлеген өйрәнү бүгенге актуаль бурыч булып кала бирә.

---

[1] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2010. Б. 525.

## МӘҢКЕ БАБАЙГА СӘЛАМ
(Татар халкының «Боз озату» йоласы)

Борынгыдан төрле ышанулар, мифологик карашларга нигезләнеп гореф-гадәт формасын алган, төгәл һәм билгеле таләпләргә нигезләнгән йолалар тормышта зур урын алып тора. Катлаулы яшәү шартлары, адым саен сагалап торган куркыныч, фаҗига, кешенең үз тормышына һәм табигатькә йогынты ясарга омтылышы – болар барысы да төрле гореф-гадәтләр, йолалар формалашуга китергән. Алар ярдәмендә кеше үзенең тормышындагы көндәлек һәм аерым очраклар белән бәйле вакыйгаларга йогынты ясарга омтылган. Магик көчкә ия сүз, хәрәкәт һәм гамәл нигезендә формалашкан йолалар ярдәмендә үзен якларга һәм сакларга, тормышында билгеле бер тотрыклылык һәм гармония булдырырга тырышкан. Йолаларның нигезендә ритуал булып формалашкан сүз һәм хәрәкәт ярдәмендә тормышта гармония булдыруга ышану ята. Йолалар кеше тормышындагы аерым зур вакыйгалар яки табигатьнең ел фасылларына, кояш-ай һәм һава торышына бәйле борылышлары, үзгәрешләре вакытында башкарыла. Кеше тормышындагы вакыйгалар белән бәйле һәм гаилә мөнәсәбәтләрен, кешенең гаиләдәге статусын билгеле бер традицияләр кысаларында тәртипкә сала торган гамәлләр гаилә-көнкүреш йолалары буларак билгеле. Табигатьтәге үзгәрешләр вакытында, ягъни табигатьнең һәм галәмнең аеруча сизгер вакытында башкарыла торганнары исә календарь йолалар, дип йөртелә.

Татар халкының йола фольклоры, аның традицияләре, башкарылу үзенчәлекләре, мифологик нигезләре һәм поэтик текстлары Ф.И. Урманчеев, Ф.С. Баязитова, Р.К. Уразманова, Р.Ф. Ягъфәрев, Л.И. Минһаҗева, И.Г. Закирова, М.Х. Бакиров, И.Н. Надиров хезмәтләрендә тикшерелә. Бүгенге көндә йолаларның күбесе тикшерелгән булса да, аерым йолалар хәзергә кадәр тикшеренүчеләрнең игътибарыннан читтә калып килә. Шундый йолаларга татар халкының боз озату йоласы

да керә. Әлеге йола хәзерге вакытта онытылып бара торган йола булып, аның эзләре генә саклана. Татар авылларында боз карарга чыгу йоласы турында мәгълүмат фольклорчылар хезмәтләрендә, әдәби әсәрләрдә, диалектологлар туплаган материалларда теркәлгән булса да, ул фольклористикада бүгенгә кадәр, аерым вакыты булган, традицияләре формалашкан, функцияләре ачыкланган мөстәкыйль календарь йола буларак өйрәнелмәгән.

Татарлар Россия Федерациясенең төрле регионнарында һәм дөньяның төрле илләрендә яшиләр. Теләсә кайсы гореф-гадәт яки бәйрәм, аерым бер халыкка хас уртак традицияләргә ия. Шул ук вакытта һәр йоланың локаль үзенчәлекләре дә бар.

«Боз озату» йоласы татарлар яшәгән регионнарда төрлечә атала: боз карау, боз багу, боз озатма, боз озату, зин китү, су-туй, ташу карау. Күп төрле исемнәренә карамастан, йоланың эчтәлеге нигездә охшаш. Елгада боз кузгалгач, бәйрәмчә киенгән авыл халкы елга янына, боз акканны карарга җыела. Баязитова Ф.С. Себер татарларының боз озатырга барганда иң яхшы киемнәрен киюләрен болай дип терки: «Боз озатабыз дип иң яхшы шәлең бармы, аны киеп чыкканнар»[1]. Аккан бозларга салам яндырып җибәрәләр. Яшьләр бергә җыелалар. Шунда ук гармунчылар да була. Су буенда шау-шу, гармун тавышы төнгә кадәр тукталмый.

Россиянең төрле регионнарында яшәгән татар халкының «Боз озату» йоласы хәзерге вакытта, нигездә, реликтлар хәлендә генә сакланып калган. Татарстанда яшәүче татарлар боз кузгалган көнне боз озатырга яки боз карарга чыгалар. Элегрәк ул бөтен авыл халкының бергә җыелып күңел ачу гадәте булган. Су буенда гармун уйнап, җырлап, биеп, әйлән-бәйлән уеннары уйнап, агып барган боз өстенә учаклар ягу тамашасы рәвешендә узган[2]. Бары Себер татарларында гына

---

[1] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2010. Б. 471.

[2] Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2002. Б. 644–645.

боз озату йоласы «Су-туй» исеме белән хәзер дә уздырыла. Ул, бер яктан, «Карга боткасы» кебек язны каршылау бәйрәме. Каргалар килү белән бәйле «Карга боткасы» йоласының асылы каргаларның язны, җирнең җанын алып кайтуын, җир уянуны белдерсә, елгаларда боз китү ел фасылларының алышынуын, кышның тәмамлануын, китүен белдерә. Боз кышны, салкынны гәүдәләндерә. Боз китү, табигать уяну вакыты, бу вакытта табигатьтәге хаос кеше тормышына да йогынты ясый ала, аның аеруча сизгер һәм көчле вакыты санала.

Боз китү белән бәйле ышанулар, гореф-гадәтләр дә формалашкан. Йолалар, ритуаллар, гореф-гадәтләр, ягъни халыкның йолаларда гәүдәләнгән үз-үзен тотышы шул халыкның дөньяны танып-белүе турында мәгълүмат саклый[1].

Мәсәлән, Омск өлкәсенең Иртыш буенда урнашкан авылларда «Боз озату» мифологик ышануларга нигезләнгән асылын саклаган хәлендә хәзергә кадәр уздырыла. Аны Тәвриз районы Козгын авылында, «Су-туй» буларак, Иртыш елгасында боз кузгалгач уздыралар. Бу көнне авыл халкы елга буена җыела, үзләре белән самоварлар алып төшеп, чәй кайнаталар, милли камыр ризыклары алып барып, бөтен халык күңел ача, бәйрәм ясыйлар. Информант йоланы түбәндәгечә бәян итте: «Су-туй була. Су бәйрәме дип тә әйтәләр иде. Иртеш буенда уздыра идек. Самаварлар куеп, Су-туй ясый идек. Пешеренеп киләбез. Боз киткән вакытта бөтен авыл бәйрәме була иде. Төрле уеннар уйный идек. Бозга ипиләр ташлыйбыз. Хәер итеп. Теләкләр тели идек. Бәрәңге пешерә идек»[2].

«Боз озату»ның, милли йола буларак, халык традицияләрен саклауда да әһәмияте зур. Шул ук вакытта туганнар,

---

[1] *Закирова И.Г.* Народное творчество периода Золотой Орды: Мифологические и исторические основы: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2011. С. 44.

[2] Информант Туктасимова Маһинур Кәлимулла кызы. (1929) (Омск өлкәсе Тәвриз районы Кускуны ав.); *Закирова И.Г.* Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 253.

авылдашлар, кешеләр бер берсенә якынаялар. Яшь буын милли традицияләрне үзләштерә, рухи багланышлар ныгый, гомүмкешелек кыйммәтләре барлана. Су буенда яшьләр уеннар уйный, гармун уйныйлар. Атна-ун көн дәвам иткән яшьләр уеннары башланып китә.

Су буена төшкәч тә кешеләр үзләренә сәламәтлек, исәнлек теләп суга икмәк салганнар. Шушы ук районның Тау авылы информантлары да елгада боз аккан вакытта үзләренә сәламәтлек теләп суга акча атуларын сөйләделәр[1]. Татар халкының ышанулары буенча боз киткәндә бөтен авыруларны, күңелсезлекләрне алып киткәнгә ышаналар. Шуңа күрә боз киткән вакытта авыру кешеләр дә, аягына баса алган очракта, елга буена ашыккан, боз өстенә авыру кешеләрнең киемнәрен салып җибәргәннәр. Шулай ук язгы боз киткәндә язгы су авыруларны, гөнаһларны алып китә, кеше сафланып, яшәреп кала дигән ышану белән тиз генә бозлы суга кереп чыгу, ташу суы белән юыну, бит-кулларны юу гадәте дә булган[2].

Халык ташу суына икмәк, акча салып Су ияләренең күңелен күрергә омтыла. Бөтен гомерләре зур елга буенда узган халык шул рәвешле үзенең тормышын, эшчәнлеген җайларга тырыша. Су иясенең күңелен күреп, кеше үз дөньясына куркыныч тудырырга сәләтле су стихиясен булдырмаска, ягъни су иясе аша дөньяда гармония булдырырга омтыла. Су иясенә сәдака бирелмәгән, аның күңелен күрмәгән елларда суда бәла-казалар күп була дигән ышану булган. Шушы ук ышану Татарстан территориясендә яшәүче татар халкында

---

[1] Омск өлкәсе Тәвриз районы Тау авылы (информатлар: Ниязова Гөлсинә Наил кызы, 1959 елгы; Зәйдуллина Хәлимә Шарип кызы, 1956 елгы; Абдразакова Гөлшат Искәндәр кызы, 1959 елгы; Ниязуллина Әльфия Альфред кызы, 1968 елгы); *Закирова И.Г.* Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 259.

[2] Омск өлкәсе Усть Ишим районы Әшеван авылы (информантлар: Хәмитова Зәкия Әйтмөхәммә кызы, 1938 елгы; Хәмидуллина Шәмсия Касимкызы, 1925 елгы; *Закирова И.Г.* Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 261.

да XX гасыр ахырына кадәр сакланган. Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Бортас авылында яшәүче информант Бикмуллина Рушания Гарифулла кызы һәр елны бозлар киткәч Су анасының күңелен күреп, аңа икмәк бирүләрен сөйли: «Су анасы бик елый торган булган. Җәгъфәр бабай карчыгын «Ник Су анасына әйбер бирмәдең?» дип кыйный торган булган»[1]. Су анасына язын икмәк бирмәсәләр, ул кешеләрне батыра дип ышаналар.

Омск өлкәсендә яшәүче татарларның язгы бозларга курчаклар куеп җибәрү традициясе да булган. Себер татарларында язып алынган материаллардан кешенең авыру-сырхауларын им-том белән курчакларга күчерүләре аңлашыла.

«Курчакны чүпрәккә утыртам да пөхтәләп төреп, боз өстенә утыртам да агызып җибәрәм. Булган авыру-сырхауларны, хәвеф-хәтәрләрне агызып алып кит, дип»[2].

Бараба татарларында курчакка (коңгырчак) табыну йоласы XX йөз ахырына кадәр сакланган. Еш кына халык, рәсми рәвештә ислам динендә саналса да, яшереп кенә курчакларны олылаган. Бу курчаклар тукыма кисәкләреннән тегелгән, аларны яңартканнар да. Курчакларга көн саен ашарга, терлек суйган көннәрдә кан биргәннәр. Курчакларга мөрәҗәгать итеп сәламәтлек, иминлек, хуҗалык эшләрендә уңыш сораганнар. Эш уңышлы бармаганда, курчакларны урманга яки курчаклар куелган берәр агачка илтеп куеп, алар урынына башкаларын ясау күренеше дә булган.

Себер авылларында аккан бозлар аркылы киләчәккә яки мәңгелеккә сәлам әйтәләр.

«Мәңгәли бабайга – төньяк рухына сәлам әйтәбез. Аңа мөрәҗәгать итеп, акча атканда да «Мәңгәли бабай, безгә сәламәтлек бир!» дибез[3].

---

[1] Информант Бикмуллина Рушания Гарифулла кызы, 1954 г.р. ТР Кама Тамагы районы Олы Буртас авылы.

[2] *Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2010. Б. 454.

[3] Омск өлкәсе Тевриз районы Тау авылында яшәүчеләр.

«Миңа әнием өйрәткән: «Боз кузгалса, Мәңкеләгә сәлам әйт» дип әйтергә. Мәңкелә – мәңге ята торган боз ул»[1].

Әшеван авылында боз киткәндә башка рухларга – Тәен-Вәенгә яки Әхәләй-Мәхәләйгә сәлам әйтәләр, Сәңке бабай рухына сәдака бирәләр. Ихсиңер авылында боз озатканда Мәңке бабайга, Мәңкелек бабайга сәлам юллыйлар. Мәңке бабай, Мәңкелек бабай – Иртышнең хуҗасы дип ышаналар. Күчүм авылында боз киткәндә: Әхәләй-Мәхәләйгә сәлам әйт, дип аккан бозларга икмәк яки акча аталар[2]. Бу йолаларда татар фольклоры өчен әлегә кадәр таныш булмаган мифологик образ – Мәңке, Мәңкелек, Мәңгәли турында сүз бара. Аны информантлар төрлечә аңлата. Ул Су иясе, Иртыш хуҗасы, Төньяк рухы, яки Төньяк боз океаны рухы буларак аңлатыла. Нигездә ул «мәңгелек» төшенчәсенә кайтып кала. Мәңгелек – ул икенче дөнья, яки үлеләр дөньясы. Евразиянең төньяк халыклары мифологиясендә Төньяк боз океаны үлеләр дөньясы, караңгылык дөньясы булып күзаллана. Себер татарлары мифологиясе буенча параллель дөньялар горизанталь буенча бүленә, алар бер яссылыкта урнашкан, төньяк, шул исәптән аның үзәге булып саналган Төньяк боз океаны да үлеләр дөньясы. Карап узган материаллар буенча параллель дөньяларны елгалар бәйләп тора. Елга боздан ачылган вакыт – дөньялар арасындагы бәйләнеш аеруча көчәйгән чак.

Татар халкының язгы календарь йолаларының берсе булган «Боз озату» йоласы хәзерге вакытта онытыла бара торган йолалардан. Бары Себер татарлары яшәгән Омск һәм Новосибирск өлкәләрендә генә бу йоланың борынгыдан килгән атрибутлары сакланып калган. Анализланган материаллардан аңлашылганча, боз озату йоласы, кышны озату, язны каршы алу йоласы гына булмыйча, табигатьнең үлеләр һәм

---

[1] Омск өлкәсе Тевриз районы Әйрә авылыннан информант Фаттахова Асия Хәмидулла кызы. (1937 елгы); *Закирова И.Г.* Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 258.

[2] *Закирова И.Г.* Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. Б. 240–266.

тереләр дөньясы арасындагы бәйләнеш көчәя торган аеруча сизгер бер мизгеле булуын да раслый. Кешеләр аны үлеләр дөньясы капкалары, ягъни портал ачыла торган вакыт буларак кабул итәләр. Шул вакытта халык үзенә кирәкмәгән күренешләрдән – авырулардан, бәхетсезлекләрдән котылырга омтыла, аларны бозлар белән кире юлы булмаган дөньяга озата. Мәңке/Мәңге/Мәңгәли/Мәңкелә Себер татарлары мифологик ышанулары буенча үлеләр дөньясын символлаштырган Төньяк боз океаны хуҗасы буларак күзаллана. Бу образлар – мәңгелек дөнья белән бәйле рухлар, дигән фикергә килә алабыз.

Татар халкының «Боз озату» йоласы, бу йола белән бәйле образлар турында мәгълүматлар киләчәктә дә язып алыныр, аларның функцияләре тагын да ачыкланыр дип уйлыйбыз.

## ХАН БИЛГЕСЕ ТУ БУЛЫР

(Фольклорда һәм татар әдәбиятында хөкемдар образы)

Төрки халыклар фольклорында шул исәптән татар фольклорында да хөкемдар образына зур игътибар бирелә. Хөкемдар – патша яки падиша(һ), солтан, хан (хан-солтан) образлары әкиятләрдә, җырларда, мәкаль-әйтемнәрдә, дастаннарда, мәзәкләрдә, бәетләрдә – гомумән алганда, татар фольклорының барлык жанрларында да очрый. Һәр жанрда, аларның таләпләре һәм закончалыкларына бәйле рәвештә, хөкемдар образы төрле яктан ачыла.

Төрки фольклорда аерым шәхеснең, кагыйдә буларак, кан аша тәхеткә хокукы булмаган кешенең, хакимияткә килүе аның харизмасы, ягъни гади кеше генә булмавы белән аңлатыла. Идарәнең харизматик тибы соңгы берничә дистә елларда гына өйрәнелә башлаган өлкә. Бу очракта шәхеснең хакимияткә килүе аның харизмасы, ягъни тиңдәшсез булуы, алдына куйган максатына ирешә белүе, башкалардан аерылып торуы, таланты белән аңлатыла. Харизма туганда ук Алла тарафыннан бирелә, бер кеше дә үз тырышлыгы белән аңа ирешә алмый. Харизматик абруй да халыкның хакимияткә килүченең гадәти булмавына, Алла тарафыннан сайланган булуына инануыннан формалаша. Ханның харизмасы аның илдә-ыруда тәртип булуны тәэмин итүче сыйфаты, ул шул ук вакытта ыру-кабилә харизмасы да булып тора. Алла тарафыннан сайланган ханның бер генә гамәле дә халыкта ризасызлык яки шик тудыра алмый. Бу халыкның ханга хөрмәтендә, ышануында, аның һәр әмеренә буйсынуында чагыла, һәм, үз чиратында, илнең, халыкның бердәмлегенә китерә. Харизма татар фольклорында *кут/кот, тын* терминнары аша бирелә. Харизмага ия шәхесләр аларны гади кешеләрдән аерып торган сыйфатларга да ия буларак тасвирлана. Бу аларның нурлы йөзле, нурлы күзле булуы, алтын чәч тотымы булу, яки тәннәрендә илаһи мөһер булу һ.б.

VIII гасырга караган Орхон-Енисей ташъязмаларында да ил башының Тәңре тарафыннан сайланган булуы турында сүз бара. Мәсәлән, Күлтәгин истәлегенә куелган ташта: «Тәңри ярлыкадукын үчүн, өзим кутым бар үчүн, каган олуртым» («Тәңре ярлыкаган өчен, үземнең котым булганга каган булдым»), дип язылган. Икенче өзектән каганның илаһи ярасылышы аңлашыла: «Күк кебек Күктә яралган, белекле түрек каганы бу урынга утырдым».[1] VIII гасырга караган Күлтәгин язмасында борынгы төркиләрдә хакимлеккә хокукның Күкләр тарафыннан бирелүе, котка ия шәхеснең генә тәхеткә утыруы, ягъни каган булып сайлануы аңлашыла. Кеше үзенең күрсәткән эше белән түгел, «котлы булуы хакына» каган була. Кот, сульде (*монг.* сүлд) яки харизма турында ышанулар төрек-монгол халыкларында көчле була.

Һәрбер тылсымлы әкияттә илнең башында патша яки падишаһ тора. Ул халыктан шактый ерак, әмма шул ук вакытта, гади кеше буларак, һәр кешегә хас сыйфатлар белән сурәтләнә. Ул дию урлап киткән кызы өчен борчыла, авырып киткән кызына дәва эзли. Башка патшалар алдында мактаныр өчен алтын каурыйлы кош яки дөньядагы иң матур кызны кулга төшерергә хыяллана. Әкият батырының ахыр максаты хакимлек булмаса да, ул, ахыр чиктә, тәхеткә менә. Бу очракта тәхет һәм хакимлек гади халык өчен бәхетнең иң югары ноктасы булуы аңлашыла. Патша итеп куелган батыр да, халык тормышында нәрсәдер үзгәртергә омтылмый. Әкияти тәхет аерым бер кешенең тормышына гына үзгәреш кертә. Әкиятләр реаль тарихи шәхесләрнең исемен дә сакларга мөмкин. Мәсәлән, татар әкиятләрендә Зөлкарнәй патша исеме сакланган. Борынгы Македониянең мәшһүр патшасы – гаскәр җитәкчесе, дөньякүләм держава булган Македония империясенә нигез салучы. Александр Макендонскийны күпчелек мөселман халыклары Искәндәр Зөлкарнәйн буларак белә. Әкиятләргә чынбарлыктан Искәндәр Зөлкарнәйннең дөньяның бер батыры булуы һәм

[1] *Госманов М.Г.* Гасырдан – гасырга. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 40.

ике мөгезле баш киеме турында мәгълүмат кергән. Татар әкиятләрендә ул «Зөлкарнәй патшаның мөгезе бар, Күргән юк та, ишеткән бар,» дип тасвирлана. В.В. Радлов Себер татарларыннан язып алган җырда да аның мөгезе искә алына:

Сөяндәй мөгез үстергән
Зөлкарнәй үткән дөньядан[1].

Александр Македонский үз дәверендә сугылган акчаларда арыслан башлы Геракл баш киеме, яки Аммон алла мөгезләре белән сурәтләнгән. Бу рәсемнәр буенча фикер йөрткәндә, Александр Македонский үзе мөгезле булып аңлашыла. «Зөлкарнәй батыр»да әкият каһарманы дөнья күрергә дип чыгып китеп, диюләрне җиңеп кайткан батыр буларак тасвирлана.

Тылсымлы әкиятләрдә батыр тәхеткә берничә юл белән килә. Беренче очракта ул патша кушкан бөтен эшләрне башкарып чыкканнан соң, патша кызына өйләнеп, кияү буларак тәхеткә утыра. Икенче очракта билгеле бер ризык ашау геройның язмышын хәл итә. Мәсәлән, берәр кошның башын яки йөрәген ашаган кешенең патша буласы алдан тәгаенләнгән була. Өченче очракта булачак патшаны дәүләт кошы сайлап ала, аның башына куна. Бу әкиятләрдә геройның тәхеткә киләсе алдан ук илаһи көчләр тарафыннан хәл ителүе аңлашыла. Дастаннарда геройның тәхеткә утыруы аның илаһи көчләр тарафыннан сайлап алынган булуыннан килә.

Харизматик шәхеснең нәсел-шәҗәрәсе, тууы турындагы легенда-риваятьләр аның гадәти кеше булмавын раслауга хезмәт итә. Дастаннарда әлеге шәхесләрнең эпик биографиясе дә аларның гади кеше булмавын исбатлый. Геройның нәсел җебе тотем хайваннан башланырга мөмкин. Яки аның кояш нурыннан яралуы турында сөйләнелә. Шәҗәрә пәйгамбәр яки изгеләрдән башланырга да мөмкин. Татар фольклорында Чыңгыз ханга, Идегәйгә багышланган әсәрләрдә бу күренеш бик ачык чагыла. Чыңгыз хан турындагы дастанда Чыңгыз хан

---

[1] *Радлов В.В.* Образцы... С. 137.

күктән иңгән нурдан туа. Бу аның Алла тарафыннан сайланган шәхес булуын бәян итә.

Илаһи ата кешеләргә нур булып күренә. Кояш, кояш нуры, яктылык, балкыш – илаһи күренешләр. Харизмага ия шәхеснең гәүдәсе яки йөзе дә балкый, ягъни нур сибә, ул эчтән яктыра. Бу аның башкалардан аерылып торган сыйфаты. Яктылык, нур, балкыш – Кояш атрибутлары да. Ә ул алтын яки алтын-кара төс белән тәңгәлләшә. Харизмага карата алтын-кара эпитеты да кулланыла. Үзенең харизмасын ныгыту өчен шәхес аерым көннәрдә обо (ташлар өеме) булган биек тау башына менеп корбан бирә, ягъни Күк Тәңрегә якыная, кояштан көч ала. Татар телендә хәзерге вакытта да сакланган «Нурлы йөз», «Йөзе балкый», «Кояш йөзле», «Күзендә ут бар», «Күзләре яна» кебек гыйбарәләр дә шушы мотивларның эзе булса кирәк.

Илаһи нәсел җебе яки нәсел башы тотемга барып тоташу да булачак хөкемдарның гади кешеләрдән аерылып торганын күрсәтә. Күктән төшкән нур, бүрегә әверелеп китә. Чыңгыз ханның 23 буыннан торган шәҗәрәсе Буртэ-Чино һәм аның хатыны Гоа-Марал исемнәре белән башланып китә. Буртэ-Чино – соры бүре, ә Гоа-Марал нәфис болан дип тәрҗемә ителә. Бурят галиме Доржи Банзаров исемнәре хайваннарны аңлаткан әлеге геройларны реаль шәхесләр буларак кабул итүгә шикләнеп карый, исемнәрнең тотемистик мифларга барып тоташуын фараз итә[1].

Ыру-кабилә тарихын, ыругның килеп чыгуын аңларга тырышу тотемистик мифлардан башлана, һәрбер кабилә үзенең килеп чыгышын мифик тотем баба образы белән бәйләп аңлата. Аерым бер территориягә беренче булып килеп урнашкан кеше турындагы риваять тә тотем-баба турындагы мифтан үсеп китә. Буртэ-Чино белән Гоа-Марал образлары да зооантропоморф табигатьле образлар. Алар риваятьтә кешеләр буларак тасвирлансалар да, исемнәре зооморфологик билгеләрен саклап калган.

---

[1] *Банзаров Доржи.* Собрание сочинений. М.: Изд-во Академии наук СССР, 1955. С. 168.

Варисның хакимлеккә хокукы аның илаһи нәсел башы, яки тотем белән кан туганлыгы аша нигезләнә. Бу очракта да Чыңгызның, бер яктан, тотем-баба – бүре белән бәйләнеше, икенче яктан, Илаһи Күк улы булуы, ягъни илаһилыкка дәгъвасы аша хакимлеккә хокукы раслана.

Төрки халыкларның күбесенә таныш «Идегәй» дастанында Идегәйнең нәсел башы Изге Баба Төкләс белән Су кызы никахыннан башлана. Идегәйнең улы Норадын исә үзенең илаһи килеп чыгышына ишарә ясый: «Ай белән Көн кушылып, ике нурдан» пәйда булуын сөйли. «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә Чыңгыз ханның күктән төшкән нурдан яралуы турында сүз бара. Күктән төшкән нур – Илаһи ата булып аңлашыла. Герой шул рәвешле үзенең Күк-Тәңрегә мөнәсәбәтен бәян итә.

Тәхет мирас булып күчмәгән очракта, геройның тәхеткә килүе дә төрки халыкларның фольклорында чагылыш тапкан. Бу кешегә дәүләт кошы кунарга, яки ул кошның күләгәсе төшәргә мөмкин.

Татар халык иҗатында Казан ханлыгының соңгы ханбикәсе Сөембикә образы да идеал хөкемдар буларак гәүдәләнә. Халык аны, бер яктан, әкияти матурлык иясе итеп сурәтләсә, икенче яктан, илен сакларга омтылган көрәшче образы кузаллана. Легендалар Сөембикә ханбикәнең дошман кулына төшәргә теләмичә манарадан ташлануын бәян итә. Сөембикә дәвере белән татар халкының дәүләтле чоры да тәмамлана. Фольклорда Сөембикә идеал хөкемдар гына булмыйча, дәүләтле һәм горур халык, буйсынмаган халык символы булып та саклана.

Гадел хөкемдар образы фольклордан күчеп, төрки һәм соңрак татар әдәбиятында да үстерелә. Тарихи романнар авторы Мөсәгыйть Хәбибуллин «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», «Хан оныгы Хансөяр», «Аллаһы бүләге», «Батый хан һәм Ләйлә», «Атилла» романнарында татар тарихында исемнәре сакланган ханнарның образларын иҗат итә. «Кубрат хан» романында җиденче гасырда Азов һәм Төньяк Кавказ буйларында төзелгән төрки телле Бөек Болгар дәүләте, аңа нигез салучы Кубрат

хан сурәтләнә. «Кубрат хан»ның дәвамы рәвешендә язылган «Илчегә үлем юк» романында Идел буе Болгарстаны хөкемдары Сәлим хан, «Хан оныгы Хансөяр» романында Болгар дәүләтенең соңгы илбашы Илһам хан , «Батый хан һәм Ләйлә» романында Идел буе Болгар дәүләтенең монголлар хакимияте чоры, Батый хан белән болгар кызы Ләйләнең мәхәббәте тасвирлана. «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романында Казан ханлыгының соңгы чоры, Сөембикә ханбикәнең фаҗигале язмышына бәйле вакыйгалар бәян ителә.

Бу әсәрләрдә хөкемдар образы, бер яктан, гадәти кеше – ир-егет, ир, ата яки ул булып ачылса, икенче яктан, Аллаһ тарафыннан илен-халкын яклар һәм саклар өчен сайланган шәхес буларак тасвирлана.

Тарихи романнар авторы Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» әсәрләрендә, Вахит Имамовның архив материалларына һәм тарихи чыганакларга таянып иҗат ителгән романнарында да татар халкының дәүләтле чоры, аның ханнары, ил башлыклары, төркиләрнең бердәмлеге турында сүз бара.

Йомгак ясап шуны әйтергә мөмкин, төрки фольклор хөкемдарның Алла тарафыннан сайланган шәхес булуын бәян итә. Алла тарафыннан билгеләнгән хөкемдарга буйсыну гына ил-юрунын бердәмлеген һәм иминлеген тәэмин итә ала. Бу мотив алга таба татар фольклорында һәм, тагын да соңрак, әдәбиятта да үстерелә.

## ЧЫҢГЫЗ ХАН ҮТКӘН ДӨНЬЯДАН

(Төрки-монгол халыклары фольклорында
Чыңгыз ханның эпик биографиясе)

Бөек империяләрнең берсе саналган Монгол империясенә нигез салган Тимучинны бөтен дөнья халкы Чыңгыз хан буларак белә. Чыңгыз ханның тормышы бик яхшы өйрәнелгән. 850 еллап элек яшәгән Тимучинга күп санлы әдәби әсәрләр һәм фәнни хезмәтләр багышланган.

Чыңгыз ханга багышланган язма истәлекләрнең иң борынгылары һәм иң әһәмиятлеләре – XIV йөз монгол язма истәлеге – «Юань-чао би-ши», XIII йөз кытай язма истәлеге – «Мэнда бэй-лу», авторлыгы галим лама Лубсан Данзанга нисбәт ителгән XVII йөзгә караган «Алтан тобчи», фарсы тарихчылары Җүвәйни (XIII йөз), Рәшит-әд-дин (XIII ахыры – XIV башы), гарәп тарихчысы Ибн-әл-Асир (XII йөз ахыры – XIII йөз башы), италияле де Плани Карпани, Марко Поло, фламанд Вильгельм Рубрук һ.б.еың хезмәтләре. Төрки, рус, әрмән, әфган, грузин һ.б. елъязмачылар да үзләренең әсәрләрендә Чыңгыз хан турында мәгълүмат бирәләр.

Бөек каган образына халык иҗатында да, тарихта да күп урын бирелгән. Чыңгыз хан турында риваять-легендалар бер халыктан икенчесенә, буыннан буынга күчкән. Кайсы гына халыкның Чыңгыз ханга багышланган фольклор әсәрләрен алсак та, аның нигезендә ханның гадәти кеше булмавына инану ята, әлеге әсәрләр олуг затның гадәти түгеллеген күрсәтергә хезмәт итә.

Чыңгыз ханның культын өйрәнүче галимнәр аның гадәти булмаган ихтыяр көчен, талантын, популярлыгын ханның харизмасы белән бәйләп аңлаталар. Чыңгыз ханның 23 буыннан торган шәҗәрәсе Буртэ-Чино һәм Гуа-Марал исемнәре белән башланып китә. Күпчелек галимнәр Буртэ-Чино һәм Гуа-Маралны генеалогик мифлардан килгән фольклор

персонажлары итеп карыйлар[1]. Монголларның үзләренең шәҗәрәләрен бик яхшы белүләрен истә тотсак, бу реаль шәхесләрнең исемнәре дә булырга мөмкин. «Юань-чао би-ши» әсәрендә Чыңгыз ханның нәсел башы турында мәгълүмат берничә җөмләгә сыя: «Чыңгызханның борынгы бабасы Югары Күк ихтыяры белән дөньяга килгән Буртэ-Чино иде. Хатыны Гоа-Марал була. Алар диңгез кичеп киләләр. Онон елгасы янында, Бурхан-Халдунда күчмә тормыш белән яшиләр. Аларның уллары Бата-Чиган була»[2]. Буртэ-Чино – соры бүре, ә Гоа-Марал нәфис болан дип тәрҗемә ителә. Бурят галиме Доржи Банзаров исемнәре хайваннарны аңлаткан әлеге геройларны реаль шәхесләр буларак кабул итүгә шикләнеп карый. «Бу риваять Чингизидлар нәселенең шушы хайваннардан килеп чыгуына ишарә итә» – дип, исемнәрнең тотемистик мифларга барып тоташуын фараз итә[3].

Ыру-кабилә тарихын, ыруның килеп чыгуын аңларга тырышу тотемистик мифлардан башлана, һәрбер кабилә үзенең килеп чыгышын мифик тотем – *баба* образы белән бәйләп аңлата. Аерым бер территориягә беренче булып килеп урнашкан кеше турындагы риваять тә тотем-баба турындагы мифтан үсеп китә. Е.М. Мелетинский мифлардагы тотем баба образының дуалистик характерын ачыклап: «Мифлардагы тотем бабалар дифференциацияләнеп бетмәгән ике төрле зооантроморф табигатьле зат буларак күзаллана, әмма аңарда кешелек башлангычы өстенлек итә», – дип яза[4]. Буртэ-Чино белән Гоа-Марал образлары да зооантропоморф табигатьле образлар.

---

[1] *Коновалов П.Б.* Об историческом и этническом сознании средневековых монголов // Тайная история монголов: источниковедение, филология, история. Новосибирск: Наука, 1995. С. 27.

[2] *Козин С.А.* Сокровенное сказание. Монгольская хроника 1240 г. // Институт востоковедения АН СССР. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1941. Т. I: Введение в изучение памятника, перевод, тексты, глоссарии. § 1.

[3] *Банзаров Доржи.* Собрание сочинений. М.: Изд-во Академии наук СССР, 1955. С. 168.

[4] *Мелетинский Е.М.* Фольклор австралийцев // Мифы и сказки Австралии.М., 1965. С. 6.

Алар риваятьтә кешеләр буларак тасвирлансалар да, исемнәре зооморфологик билгеләрен саклап калган. Шулай да риваятьтә әлеге образларның тотем баба буларак бер функциясе сакланып калган: алар монголларның билгеле бер территориягә булган хокукларын законлаштыралар. Н.А. Криничная ыру-кабиләнең аерым бер территориягә дәгъвасын законлаштыруны тотем бабаның бер функциясе буларак күрсәтә: «Тотем нәсел башы билгеле бер тотем төркемнең үзләре яшәгән һәм алар тарафыннан үзләштерелгән территориягә хокукын раслый һәм ныгыта»[1].

Ф.И. Урманчеев бүре образы белән бәйле риваять-легендаларның төркиләрдә килеп чыгып, XIII гасырда монгол хроникаларына үтеп керү ихтималын күрсәтә[2]. Төркиләр үзләренең нәсел башын тотем бүре образы белән бәйлиләр һәм ул төрки халыклар иҗатында бик популяр була. VI гасырга караган Кытай елъязмаларында бүренең төркиләр дөньясында зур роль уйнавы әйтелә. Кытай хроникалары буенча «Төрки хан» һәм «бүре» сүзләре синоним булганнар[3]. Төркиләрнең байракларын алтын бүре башы сурәте бизәгән[4]. Төркиләрдә бүрене үзләренең нәсел башы итеп тасвирлаган ике риваять билгеле[5]. Һуннарның килеп чыгуы турындагы бу риваятьләр Чыңгыз ханның генеалогиясен сурәтләгән риваять белән аваздаш. Икесендә дә илаһилаштырылган бүре турында сүз бара. Беренчесенең эчтәлеге буенча бүренең күкләр тарафыннан җибәрелүе аңлашыла. Чыңгыз ханның бер бабасы булган Боданчарның тууын тасвирлаган риваятьтә илаһи затның бүрегә яки эткә әверелүе турында сүз бара. «Монголларның

[1] *Криничная Н.А.* Персонажи преданий: Становление и эволюция образа. Л.: Наука, 1988. С. 55.

[2] *Урманчеев Ф.И.* По следам Белого волка. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1994. С.28.

[3] *Гумилев Л.Н.* Древние тюрки. М.: Товарищество Клишников-Комаров и К`, 1993. С. 23

[4] *Бичурин Н.Я. (Иакинф).* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. 1. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1950. С. 229.

[5] Шунда ук. С. 214.

яшерен тарихы» әсәрендә Алан-гоа үзенең нурдан авырга калуын сөйли: «...һәр төн, эчтә ут сүнгән сәгатьтә, төнлек аша тирмәгә аксыл чәчле кеше үтеп керә, ул минем эчемне сыйпаштыргалый, аның нурлары минем карыныма үтеп керә. Ә китүе болай: кояш белән ай очрашкан сәгатьтә, сары эт кебек, тырнаштыргалап, чыгып китә»[1]. «Алтан тобчи»да да шул ук риваять кабатлана. Анда сүз төнлек аша үтеп кергән кешенең сары эткә әверелеп чыгуы турында гына бара. Алан-гоа улының күкләр тарафыннан яратылганын, гади кеше булмаячагын аңлата:

> Аңлаган кешеләр өчен
> Бу билге: ул Күк улы. Әйе![2]

Бу риваять татарларда да, башка төрки халыкларда да мәгълүм була. XVII гасырларга караган «Дәфтәре Чыңгызнамә» җыентыгындагы беренче дастан Чыңгыз ханга багышланган, һәм анда алда искә алынган хезмәтләрдәге риваятьләрнең үзгәртелгән версияләре урнаштырылган[3]. Тотем бүре образы шушы рәвешле Илаһи Күк белән тәңгәлләштерелә. Риваятьтә ике образ – тотем бүре һәм илаһи күк образлары кушылып китеп, синкретик образ туа. Күктән төшкән нурның бүрегә (эткә) әверелүе тотем баба турындагы риваятьтән килгән мотив, мифологик геройлар тормышларының иң әһәмиятле моментларында үз асылларына кайта яки әверелә ала. Андый моментлар булып үлем һәм үлемгә тиң никах санала. Күп халыкларның фольклор әсәрләре, бигрәк тә әкиятләр буенча фикер йөртсәк, никах күп геройларга үз асылларына кайтырга булыша. «Зөһрә», «Өч бүләк», «Каракош» әкиятләрен мисалга китерергә була.

Варисның хакимлеккә хокукы аның илаһи нәсел башы, яки тотем белән кан туганлыгы аша нигезләнә. Бу очракта да Чыңгызның, бер яктан, тотем-баба – бүре белән бәйләнеше,

---

[1] *Козин С.А.* Сокровенное сказание. § 21.

[2] *Данзан Лубсан.* Алтан тобчи. С.56.

[3] Дәфтәре Чыңгыз-намә / китапны басмага хәзерләүче сүзлек һәм аңлатмаларның авторы Сәлим Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 12.

икенче яктан, Илаһи Күк улы булуы, ягъни илаһилыкка дәгъвасы аша хакимлеккә хокукы раслана.

Геройның тотемистик һәм соляр билгеләргә ия булган, үлгән атадан тууы да борынгыдан килгән мотив. Кыргыз, казак һәм Алтай халыкларында мәгълүм риваятьләрдә Чыңгыз хан үлгән атадан туа[1]. Әлеге риваять мифологиядә билгеле булган реинкарнация күренешенә мисал булып тора, ягъни илаһи ата үзенең баласында яңадан туа.

Монголларда харизма сульде термины белән белдерелә һәм галимнәр аның борынгы төркиләрдәге «кутка» туры килүен әйтәләр. Мәсәлән, Л.П. Потапов та «кут» терминын Алла тарафыннан бирелгән хакимлиек дип аңлата[2]. «Кот» яки «кут» терминының харизманы аңлатуы Күлтәгин истәлегенә куелган каберташ язмасында да аңлашыла. М.Г. Госманов тәрҗемәсендә борынгы язма болай яңгырый: «Тәңренең ярлыкавы буенча, үземнең котлы булуым хакына мин каган булдым. Каган булгач, сине – ярлы халыкны бай иттем, сине – аз халыкны күп иттем! Әллә бу сүзләремдә минем ялган бармы?»[3].

Алла тарафыннан сайланган шәхеснең атрибутлары яктылык, кош, хайван булырга мөмкин. Бу атрибутлар бер үк вакытта Күк атрибутлары да. Аллаларның асыл сыйфатлары аларның атрибутларына һәм геройларны характерлаучы билгегә әверелә. Аллалар, аларның атрибутлары һәм әлеге атрибутларның семантикасы О.М.Фрейденберг тарафыннан өйрәнелә[4]. Галимә аллаларның атрибутлары архаик тотемнарга барып тоташуын күрсәтә. Әйбер, үсемлек һәм хайван атрибутлары аллаларның стадиаль формалары булып тора.

---

[1] *Потанин Г.Н.* Казах-киргизские и алтайские предания, легенды и сказки // Живая старина. 1917. Вып. 25. С. 50.

[2] *Потапов Л.П.* Умай – божество древних тюрков в свете этнографических данных // ТС. 1972, М., 1973. С. 50

[3] *Госманов М.Г.* Гасырдан – гасырга. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 41.

[4] *Фрейденберг О.М.* Миф и литература древности. 2-е изд., испр. и доп. М.: Изд. фирма «Восточная литература» РАН, 1998. С. 153–161.

Төрки халыкларда таралган риваятьтә Чыңгыз-ханның алтын чәчле булып тууы турында сөйләнә: «Беркадәр вакыттан соң ул ир бала тапты. Аның баш түбәсендә бер тотам алтын чәче, ә аркасында Җәбраил мөһере була»[1].

«Сокровенное сказание»дә Тимучинның гадәти булмаган нурлы йөзе турындагы мәгълүмат берничә җирдә кабатлана. Чыңгыз ханның нурлы йөзле булуы Тәңредән күчкән билгесе булып тора. Хакимияткә килүне идеологик яктан дәлилләгәндә ханның Алла белән мөнәсәбәте, аның нәселенең Тәңредән килүе зур әһәмияткә ия.

«Алтан тобчи» әсәрендә Чыңгыз ханның тууы Будда исеме белән үк бәйләнә. Эсруа Тәңре Будда әмере белән Чыңгыз җиргә хан булып туа[2]. Аллаларның патша яки юлбашчы булып җирдә тууы, ягъни билгеле бер геройда реинкарнацияләнү мотивы дөнья халыклары фольклорында һәм мифологиядә очрый. Әлеге мотив һинд мифологиясендә популяр. Мәсәлән, «Рамаяна»дагы идеал хөкемдар Рама образы Вишнуның аватарасы булып тора. Бу мотив та тәхеткә очраклы кешенең килмәвен расларга хезмәт итә. Җиргә яңадан кайткан Тәңре хәкимлеккә үзе утыра, һәм аның белән, әлбәттә, бер җир кешесе дә тиңләшә алмый. «Алтан тобчи» җыентыгында урын алган риваятьтә Чыңгызханның тәхеткә хакы икеләтә исбатлана. Беренчедән, ул үзе реинкарнацияләнгән Тәңре, икенчедән Будда тарафыннан җирдә тәртип урнаштыру өчен сайланган.

Мөселман халыкларның Чыңгыз ханны Аллаһы Тәгалә тарафыннан гөнаһлары өчен җибәрелгән җәза коралы дип кабул итүләре тарихта мәгълүм. Чыңгыз хан үзе дә бу идеяне үткәрә. Мәсәлән, Бохара шәһәрен алганнан соң, халыкны җыеп, үзенең Алла тарафыннан гөнаһлар өстенә җибәрелүен белдерә: «Мин – Алла җибәргән җәза. Әгәр сезнең тарафтан олы го-

---

[1] Сказание о Чингизхане / перевод В.А. Панова // Тамерлан. Автобиография, уложение. М.: Изд-во Эксмо, 2005. С. 483.

[2] *Данзан Лубсан.* Алтан тобчи. М.: Наука, Гл. редакция восточной литературы, 1973. С. 67.

наһлар кылынмаса, Бөек Аллаһ сезнең башларыгызга минем кебек җәзаны җибәрмәс иде»[1].

Әлеге әсәрләр Чыңгыз ханның һәм аның гаилә әгъзаларының культын ныгытырга хезмәт итә, ягъни Чыңгыз нәселенең илаһилыгын раслый. Чыңгыз хан турындагы риваять-легенда һәм мифларның сюжетлары Үзәк Азиядә Чыңгыз ханга кадәр үк таралган була. Ул риваять-легендалар төрле хөкемдарларга бәйле рәвештә сөйләнелгән. Һәр хан шушы әсәрләр ярдәмендә үзенең хакимлеккә хокукын исбатлаган. Чыңгыз ханны культлаштыру аның оныгы, Юань династиясенә нигез салучы Хубалай исеме белән бәйле. Монголларның ата-бабалары рухына табынуы, аларны олылау, сакральләштерү традициясе Чыңгыз хан культы белән кушылып китә.

Чыңгыз хан монгол каганнарының – бөек ханнарның нәсел башы буларак игълан ителә. Чыңгыз ханның культы аның сульдесе культыннан аерылгысыз. Ханның сульдесе байрагында матдиләштерелә. Әмма бу сульденең бердәнбер матдиләштерелү очрагы түгел. Сульде, ягъни кот өч төрле иконографик образда гәүдәләндерелә: антроморфик, орнитоморфик образлар һәм байрак. Беренче икесен без алдарак карап киттек. Беренчесе – Чыңгыз ханның нәсел башын – тотем-баба бүрене илаһилаштыру. Орнитоморфик образларга килсәк, бу – бөркет, карчыга һәм лачын образлары аша сакраль субстанцияне бирү. Монгол сәнгатендә харизманы кош сурәтендә тасвирлау очрый. Мәсәлән, Сулде-Тәңре аллага багышланган танкада атка атланган җайдак өстендә канатларын җәеп һавада очкан кош тасвирлана[2]. Сулде-Тәңре һәм байрак бер образ буларак аңлашыла. Сульде, кут яки харизманы бу рәвешле бирүнең башлангычы – аллаларның дүрт атрибутив компоненты – ономастика, әйбер, хайван һәм үсемлек аша аңлатыла, һәрберсе аерым бер алланын үткән фазасын аңлата[3].

---

[1] *Рашид-ад-дин.* Сборник летописей. Т. 1. Книга вторая. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1952. С. 205.

[2] *Цултэм Ням-Осорын.* Искусство Монголии с древнейших времен до начала XX в. М.: Наука, 1982. С. 102.

[3] *Фрейденберг О.М.* Миф и литература древности. С. 157.

Чыңгыз ханның туганда кушылган исеме Тимучин. Риваятьләрдә бу исемнең барелүе берничә төрле аңлатыла. Беренче риваять буенча, Чыңгыз хан туган вакытта, атасы Есугай-Баатур берничә татар кешесен әсирлеккә алып кайта. Бала туганда алып кайткан кеше Тимучин-Уге исемле була, шуңа күрә туган балага Тимучин дигән исем бирәләр[1]. Монгол халыклары ышануы буенча, җиңелгән сугышчының – дошманның яшәү көче, энергиясе исеме белән балага күчүгә ышаналар. Әлбәттә, бу исем Есугайга үзенең җиңүен исенә төшереп, күңелен дә хушландырып торган.

Риваятьләрдә Тимучин дигән исемне тимерче дигән сүз белән бәйләп аңлату да очрый. Монгол һәм төрки халыкларында тимерче һөнәре культ дәрәҗәсенә үстерелә. Тимерче сихри көчкә ия зат була. Төркиләрнең ыру башы Ашина да беренче шаман һәм тимерче дә булып санала. П. Пельо Тимучин дигән исемнең хәзерге монгол телендәге Тимерче дигән сүзгә туры килүен расларга омтыла, *temüyin* сүзендә *r* авазының төшеп калуын күрсәтә[2]. Г. Рубрук монголларның Чыңгыз-ханны тимер дип атаулары турында яза[3]. Чыңгыз-ханның тимерче булуы турындагы риваять-легендалар бурятларда һәм монголларда таралган. XIX гасыр башында Е. Тимковский монголлардан язып алган риваятьтә Чыңгыз ханның тимерче булып корал сугуы, Дархан тавында бурын дигән металлдан эшләнгән сандалы саклануы турында сүз бара[4]. Чыңгыз ханның тимерче булуы турындагы риваятьләр бурят халкында хәзергә кадәр саклана. Бурятиядә Чика елгасының сул ярында формасы белән пирамиданы хәтерләткән Дөш тавы урнашкан. Аның түбәсе формасы белән тимерче сандалын хәтерләткәнгә ул шулай ип атала. *Дөш (dos)* монгол телендә тимерче сандалын аңлата. Бурят халкының Чыңгыз ханның ике аягы белән елга-

[1] *Козин С.А.* Сокровенное сказание. § 59.

[2] *Pelliot P.* Notes on Marko Polo. Paris, 1959, I. P. 290.

[3] *Карпини Дж. дель и Рубрук Г. де.* Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Рубрука. М., 1957. С. 180.

[4] *Тимковский Е.* Путешествие в Китай через Монголию в 1820 и 1821 гг. СПб., 1824, ч. I. С. 202.

ның ике ярына басып, Чика суында суыта-суыта тимер сугуы турындагы риваяте бүгенгә кадәр килеп җиткән[1].

Риваятьтә Тимучинның Чыңгыз исемен алуын аңлатырга омтылу да сизелә. Исемнең килеп чыгышы турында галимнәрдә төрле фикер бар. Абел-Гази «чин» сүзенең «бөек» дигәнне, ә «гис» – күплекне-артыклыкны белдерүче кисәкчә булып, бу сүз «иң бөек» дигәнне аңлата дип яза[2]. Д'Оссон «чинг» сүзен кодрәтле һәм «гиз» сүзен күплек кушымчасы дип аңлата[3]. Сүзнең этимологиясен шул рәвешне аңлатырга омтылу башка хезмәтләрдә дә очрый. Хаммер-Пургшталь, Эрдман, И.Л. Мосгейм да «чыңгыз» сүзенең мәгънәсен шулай тәрҗемә итә. Мөселман тарихчылары да шушы ук фикерне әйтәләр. Рашид-әд-дин Чыңгыз титулының мәгънәсен түбәндәгечә бәян итә: «Чин сүзенең мәгънәсе көчле һәм нык, ә чынгыз – сүзнең күплек сандагы формасы»[4]. Д. Банзаров әлеге этимологияне кире кага, һәм әлеге сүзнең монгол телендә бернинди мәгънәсе юклыгын күрсәтә[5].

Мифологиядә геройның кулына киләчәгеннән хәбәр булган берәр предмет тотып тууы мотивы бар. Тимучинның дөньяга килүен тасвирлаган легендаларда да шушы мотив бар. Чыңгыз хан учына укмашкан кан тотып туа. Бу мотив «Юаньчао би-ши»да сүз уңаеннан гына телгә алына «Ә туар вакыты җиткәч, ул уң кулында кузна сөяге зурлыгындагы оешкан кан кисәге тотып туды»[6]. «Алтан тобчи»да шушы ук мәгълүмат кабатлана: «Ул туганда уң кулына кузна сөягенә охшаган оешкан кан төере кысып тоткан булган, дип сөйлиләр»[7].

---

[1] Мэн-да бэй-лу («Полное описание монголо-татар») / Факсимиле ксилографа. Перевод с китайского, введение, комментарий и приложения Н.Ц. Мункуева. М.: Наука, Гл. редакция восточной литературы, 1975. С. 96.

[2] *Абул-Гази.* Родословное древо тюрков / перев. Г.С. Саблукова. Казань, 1906, I. С. 252.

[3] *Д`Оссон.* История монголов. Т. I. Иркутск, 1937. С. 77.

[4] *Рашид-ад-дин.* Сборник летописей. Т. I. М.-Л., 1952. С. 150.

[5] *Банзаров Д.* Собрание сочинений. М.: Изд-во АН СССР, 1955. С. 176-177.

[6] *Козин С.А.* Сокровенное сказание. § 59.

[7] *Данзан Лубсан.* Алтан тобчи. С. 66.

Чыңгыз хан турындагы риваять-легендаларда бердәмлек һәм тугрылык идеяләре беренче планга чыга, төп кыйммәт булып санала.

Бердәмлек мотивы легендар Алан-гуа образы белән бәйле риваятьтән үк башлана һәм Чыңгыз-хан образы белән бәйле һәр легенда-риваятьтә кызыл җеп булып сузыла. «Юань-чао би-ши» әсәрендә, ягъни «Монголларның яшерен тарихы»нда Алан-гуаның, улларын бердәмлеккә чакырып, үгет бирүе тасвирлана. Әгәр бәйләнгән биш чыбык кебек бердәм һәм дус булсагыз, кемгә булса да, җиңел генә табыш булырсызмы?»[1]. Бу сюжет бик борынгы булып, аның тамырлары скиф фольклорына тоташа[2]. Ул грек чыганакларында Кубрат ханга мөнәсәбәттә искә алына. Кубрат хан улларына бердәмлекнең көчен шушы ысул белән раслап күрсәтә. Җәләлетдин Ата-Мәлик Җүвәйни бу сюжетны Чыңгызханның үзенә бәйле вакыйга буларак бәян итә. Чыңгыз хан улларын янына җыеп, алар алдында садактан бер ук алып сындыра, аннары ике ук ала, аларны да сындыра. Шулай итеп ул алган саен берәр ук күбрәк ала башлый һәм кулында баһадирлар да сындыра алмаслык ук бәйләме җыела. Шуннан соң ул улларына түбәндәге үгетне бирә: йомшак ук башка уклар белән бергә генә ныгый, хәтта көчле сугышчылар да аны сындыра алмыйлар. Сез дә, бер-берегезгә булышканда, берегез икенчегездә ярдәм иткәндә, дошманнарыгыз, нинди генә көчле куәтле булсалар да, сезне җиңә алмыйлар[3].

Чыңгыз хан өчен улларының бердәмлеге һәм татулыгы актуаль мәсьәлә. Чөнки өлкән Җүчи анасы Бүрте меркитларда булып кайтканнан соң туа, шул сәбәпле башка балалары аны ханның законлы варисы итеп танымыйлар. Дөрес, шул

---

[1] *Козин С.А.* Сокровенное сказание. § 19–22.

[2] *Хомонов М.П.* Образцы общемонгольского фольклора в «Сокровенном сказании монголов» // «Тайная история монголов»: источниковедение, история, филология. Новосибирск: Наука, 1995. С. 126.

[3] *Джувейни.* Чингизхан. История завоевателя мира, записанная Ала-ад-Дином Ата-Мелик Джувейни / перевод с текста Мирзы Мухаммеда Казниви на английский язык Дж.Э. Бойла; пер. текста с англ. на рус. яз. Е.Е. Харитоновой. М.: Магистр-Пресс, 2004. С. 29.

чорга караган чыганаклар бу четерекле мәсьәләне әйләнеп узарга омтыла. Авторлар Җүчинең атасының уң кулы, таянычы һәм киңәшчесе булганны бәян итәләр. Аноним авторның «Шәдҗәрәт әл-әтрәк» дигән хезмәтендә (XV йөз) Җүчинең үлеме тасвирлана[1]. Бу эпизодта Чыңгыз ханның улын никадәр яратуы, хөрмәт итүе, аңа ышануы ачык күренә. Җүчинең үлем хәбәре килеп җиткәч, бу турында беркем дә Чыңгыз ханга җиткерергә кыймый. Бу авыр миссияне хезмәткә Олуг-Җырчы исеме белән тарихка кереп калган чичәнгә тапшыралар. Чыңгыз хан җырларга кушкач, Олуг Җырчы төрки телдәге җырны башкара:

Тенгиз баштын булганды, ким тондурур, а ханым?
Терек тубтым джыгылды, кем тургузур, а ханым?

Чыңгыз хан да җыр белән җавап бирә:

Тенгиз баштын булганса, тондурур олум Джучи дур,
Терек тубтым джыгылса, тургузур Олум Джучи дур.

Олуг Җырчы үзенең җырын кабатлый, бу вакытта аның күзләреннән яшь ага башлый. Һәм шул вакытта Чыңгыз хан бөтенесен аңлый:

Көзөң йәшен чөкүртүр көңлүң толды болгаймы?
Җырың күңел өкүртүр Җүчи үлде булгаймы?
Олуг Җырчы янә җыр белән җавап кайтара:
Сөйлемәккә иркем юк, син сөйләдең, а ханым!
Үз ярлыгың үзгә җаб айу өйледен, а ханым!

Чыңгыз хан беркем дә әйтергә кыймаган хәбәрне үз авызы белән әйтә. Үз соравына үзе җавап бирә. Соңгы сүзләреннән Чыңгыз ханның югалтуны бик авыр кичерүе, улы белән соңгы вакытта аралары бозылуга бик нык үкенүе сизелә:

Кулун алган кулandай кулунумдин айрылдым,
Айрылышкан аңкаудай эр олумдин айрылдым.

---

[1] Из родословия тюрков // Сборник материалов относящихся к истории Золотой Орды. Извлечения из персидских сочинений собранные В.Г. Тизенгаузеном. т. II. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1941. С. 202.

Төркиләрдә әлеге җырның иҗат ителүе халыкның Чыңгыз хан турында яхшы мәгълүматлы булуын күрсәтә.

Чыңгыз ханның сугыш тактикасы да, аның кансызлыгы, басып алынган ил халкына карата шәфкатьсезлеге дә риваять-легендаларга кереп калган. Гарәп, фарсы, кытай һәм башка язма чыганакларда бу турында шактый мәгълүмат теркәлгән. Фарсы тарихчысы Рәшид әд-дин Чыңгыз ханның 1205 елда Минья империясенә һөҗүмен бәян итә[1].

Шәһәрне яклаучылар басып алучыларның таләбенең җиңеллегенә шаккаталар, әмма аның артында мәкер күрмиләр. Тиз генә бөтен мәчеләрне һәм кошларны тотып монголларга тапшыралар. Монголлар сүс алып, аны кошларның аякларына һәм мәчеләрнең койрыкларына бәйлиләр, сүскә ут төртеп аларны күп-күп итеп кире җибәрәләр. Шәһәрдә яшәгән мәчеләр дә, оялары шунда урнашкан кошлар да, уттан котылу эзләп үз ояларына ашыга. Шулай итеп шәһәр бик күп урында яна башлый, аны ут чорнап ала. Паникага бирелгән шәһәрне яулап алу кыенлык тудырмый[2]. Шәһәрне алганда кошлардан файдалану тактикасы монгол гаскәрләре тарафыннан соңрак та кулланыла. Риваятьләр буенча, Болгар дәүләтенә һөҗүме вакытында Аксак Тимер дә шушы ук тактиканы исенә төшерә.

Чыңгыз хан улы Җүчи үлгәннән соң алты ай яши. Аның үлемен дә риваять-легендалар романтикага өретеп сурәтли.

Чыңгыз хан үзе берничә тапкыр яуга чыгып та, ахырына кадәр буйсындыра алмаган Си-Ся, ягъни Тангут җирләреннән ерак түгел дөнья куя. Ханның үлгән урыны аның үлеме турындагы бер риваятькә сәбәп була. Бу риваять бурят-монголларда төрле версияләрдә мәгълүм. Аның бер версиясе «Алтан тобчи»да да бар. Риваять Чыңгыз ханның тангутларны яулап алыр өчен оештырган сугышларын, ягъни тарихи фактларны кире какмый. Киресенчә, анда ханның бу илгә кат-кат һөҗүм итүен аңлату омтылышы сизелә.

---

[1] *Рашид-ад-дин.* Сборник летописей. 1952. Т. 1. Кн. 2. С. 253.
[2] *Хоанг Мишель.* Чингизхан. Ростов-на-Дону: Феникс, 1997. С. 195.

Бу риваятьтә Чыңгыз ханның иң матур хатынга (Си-Ся дәүләте патшасының хатынына) өйләнергә теләве, һәм шул хатын кулыннан үлемен табуы тасвирлана.

Чыңгыз ханның чибәр хатынын эзләп юлга чыгуы, аның үлемсез ирен үтерүе татар әкиятләрендәге батыр егетнең патша кызын эзләп дию патшалыгына барып чыгуын, диюнең чит предметларда урнашкан җанын эзләп табып үтерүен хәтерләтә. Гомумән, әлеге легендаларда Чыңгыз хан икенче дөньяга үтеп кереп, икенче дөнья патшасын җиңеп чыккан батыр буларак сурәтләнә.

Фольклорда һәм мифологиядә Чыңгыз хан үзе дә Күкләр улы, Тәңре улы булып, үлемсез итеп тасвирлана. Аның – үлемсез ханның үлемен халык кабул итә алмый. Шуңа күрә, беренчедән, Чыңгыз ханның бүтән булмавын хәбәр итү, икенчедән, әгәр башка дөнья вәкиле булмаса, хан мәңге яшәр иде дигән идеяне үткәрү максатыннан шундый әсәрләр иҗат ителә. Чыңгыз хан үлгәндә үзенең берничә йөз яки мең елдан яңадан кайтачагын әйтә. Бу эпизод та ханның үлемсез булуына ышанудан туган.

Чыңгыз хан турында легендалар-риваятьләр, монгол-бурятлардан тыш, төркиләрдә дә популяр булган. Казакларда, татарларда, үзбәкләрдә, башкортларда һ.б. халыкларда әлеге шәхес исеме белән бәйле риваять-легендаларның халык телендә XX йөзләргә кадәр саклануы шул турында сөйли.

Төрки халыкларда таралган риваять-легендалар «Юань-чао би-ши» җыентыгындагы риваять-легендалар белән аваздаш. Алтын Урдада Чыңгыз хан һәм чыңгызханидларның тормышлары бәян ителгән «Алтын дәфтәр» дигән хезмәт була. Аның турында мәгълүматлар Рәшид-әд-диндә сакланган. Халык теленә риваять-легендалар шушы «Алтын дәфтәр»дән дә кергән булырга мөмкин. «Алтын дәфтәр» эчтәлеге белән «Юань-чао би-ши» һәм «Алтан тобчи»ны хәтерләтеп, шуларның төрки телдәге версиясе дә булырга мөмкин.

Чыңгыз ханның шәҗәрәсен Нух пәйгамбәр белән башлау, төркиләр аңында, хәтерендә Чыңгыз ханның ят, басып алучы булып түгел, үзләренеке булып урнашуын исбатлый.

Төркиләрдә шул исәптән, Казан татарларында да фольклорлашкан Чыңгыз хан илаһи нәселле, гадел патша, уңай образ булып тасвирлана. «Дәфтәре Чыңгызнамә»дә бу факт алга таба да раслана. Әсәрдә ул: «Халыкка гадел хөкем итеп файдалы булды. Халык аны яратты, аңа иярә башлады. Чыңгызны гаять яхшы хан дип, хан җенесе, баласы дип мактадылар», – дип сурәтләнә.[1]

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Чыңгыз хан образы төрки-монгол халыклары фольклорында бик популяр булып, ул безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Монгол халкында бу образ «Юань-чао би-ши», «Алтан тобчи» кебек җыентыкларда, төркиләрдә безнең көннәргә килеп җитмәгән, яки әлегә табылмаган «Алтын дәфтәр»дә мәңгеләштерелгән. Образ язма әдәбият белән параллель рәвештә фольклорда да яшәгән. Чыңгыз образына бәйле риваять-легендалар алардан күп алда барлыкка килгән мифларга, фольклор традицияләренә таянып иҗат ителгән. Бу әсәрләрдә Тимучин – Чыңгыз ханның Күк-Тәңре улы булып нурдан яралуы, аңа исем кушу, яулап алу сугышлары, ил-көннең бердәмлеге өчен тырышуы, беренче мәхәббәте һәм хатыны Бүртэ белән мөнәсәбәтләре, Си-Ся дәүләтенә каршы кат-кат яуга чыгуы, аның патшасының хатынына гашыйк булуы һәм үлеме, һәм үлемсезлеге турында сүз бара. Монгол фольклорында Чыңгыз ханны илаһи образ, Күк улы итеп тасвирласа, төркиләр аны идеал хөкемдар образына гәүдәләндерәләр.

---

[1] Дәфтәре Чыңгызнамә. Б. 12.

## ЙОМГАК УРЫНЫНА

Фольклор гасырлар дәвамында халык тарихының үзенчәлекле юлдашы булып килә һәм халыкның кабатланмас рухи һәм мәдәни байлыгын тәшкил итә. Халык иҗаты әсәрләрендә халыкның дөньяны күзаллавы, гореф-гадәтләре, ышанулары турында мәгълүмат саклана. Дөньяны күзаллау белән бәйле карашлар үзгәрми торган кыйммәтләрдән. Алар фольклор әсәрләрендә, онытыла-югала барган мифларда саклана, кайбер очракларда аерым карашлар йола элементлары булып безнең көннәргә дә килеп җиткән. Еш кына алар телдәге гыйбарәләрдә, күпсанлы ышануларда саклана. Һәрбер карашны реконструкцияләү өчен бу чыганакларны бер комплекс буларак карау, өйрәнү сорала. Бу хезмәттә кешеләрнең үзләрен аңлый башлаган көннән «без кайдан? ни өчен дөньяда яшибез?» дигән сорауларына җавапларны татар халык иҗатында теркәлгән юллардан табарга тырышыйк. Бер җавап та соңгы хакыйкать булырга дәгъва белдерми. Чөнки чыганакларыбыз – халык иҗаты әсәрләре. Фольклор – тарихи документ түгел, ул билгеле бер вакыйгага, шәхескә, күренешкә халыкның мөнәсәбәте. Татар фольклоры халыкның язмыш һәм бәхет, кешелеклелек һәм намус, гаделлек һәм ирек турындагы карашларын һәм өметен саклый, рухи байлыкның бер өлеше буларак, милли үзаң формалашуда роль уйный. Шул ук вакытта фольклор әсәрләренең бер кыйммәте – алардагы карашларның бүгенге фән тарафыннан исбатлана баруы.

Дөньяның һәм кешелекнең барлыкка килүе, параллель дөньялар, аларның хуҗалары турындагы ышанулар дөньяның күпчелек халыкларына мәгълүм, уртак сюжетка корылган әсәрләр. Бүгенге көндә – кешелек экологик катастрофа алдында торганда, рухи кыйммәтләр җуела барган чорда алар тагын да актуаль яңгырый. Табигать кебек үк, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, игелек, кешелеклелек кебек сыйфатлар да яклауга һәм саклауга мохтаҗ. Татар халкының фольклор әсәрләрендә кешенең җирдәге, җәмгыятьтәге урыны билгеләнә. Алар җәмгытьтәге һәр зат белергә һәм буйсынырга тиеш язылмаган яшәү кануннары ролен үти. Шушы кануннарның үтәлүе җирдәге тотрыклылыкның, тынычлыкның нигезен тәшкил итә.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

*Pelliot P.* Notes on Marko Polo. Paris, 1959.

*Абуль-Гази.* Родословное древо тюрков. Сочинение Абуль Гази, Хивинского хана / перевод и предисловие Р. С. Саблукова с послесловием и примечаниями Н.Ф. Катанова. Казань, 1906.

Аламжи Мерген: бурятский эпос / под общ. ред Ю.М. Соколова; стихотворный пер. И.А. Новикова; вводн. статья и коммент. Г.Д. Санжеева. М.-Л.: Полиграфкнига, 1936.

*Аристов Н.А.* Заметки об этническом составе тюркских племен и народностей и сведения об их численности. СПб.: тип. С.Н. Худекова, 1897.

*Әхмәтҗанов М. Т*үләк һәм Сусылу хакында дастан // Әдәби мирас. Дүртенче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. Б. 14–33.

*Банзаров Доржи.* Собрание сочинений. М.: Изд-во АН СССР. 1955. 375 с.

*Баранов Е.Э.* Козу-Корпеш и Баян-Слу. Киргизское народное предание // Ежемесячные литературные приложения к журналу «Нива» на 1899 г. за янв. СПб., 1899. С. 307–344.

*Бартольд В.В.* Сочинения. Т. 5. Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов. М.: Наука, Гл. изд-во восточной литературы, 1968. 758 с.

*Баскаков Н.А.* Душа в древних верованиях тюрков Алтая (Термины, их значения и этимология) // Советская этнография. 1973. № 5.

Башкирский народный эпос. М. 1977.

Башҡорт халыҡ ижады. Риүәйәттәр һәм легендалар / төҙөүсе, инеш мәҡәлә яҙыусы, аңлатмалар биреүсе Ф.А. Нәҙершина; яуаплы редакторы Кирәй Мәргән. Өфө, 1980.

Башкорт халык иҗаты. Эпос. Беренсе китап / төзөүсе, баш һүз язы-усы, аңлатмалар биреүсе Мөхтәр Сәгитов. Өфө: Башкортостан кит. нәшр., 1972. 344 б.

*Баязитова Ф.С.* Себер ареалы татар диалектларында этнокультура лексикасы. Казан, 2010.

Беовульф. Старшая Эдда. Песнь о нибелунгах (Сер. Библиотека всемирной литературы)М.: Художественная литература, 1975.

Библия. Книги Священного писания Ветхого и Нового завета. Брюссель: Изд-во «Жизнь с Богом», 1989. 2535 с.

*Бичурин Н.Я. (Иакинф).* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена Т. I. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1950. 383 с.

Борынгы татар әдәбияты / Төзүчесе Х. Мөхәммәтов һ.б. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.- 580 б.

Вербицкий Б.И. Алтайские инородцы. М., 1893. 221 с.

*Габидуллина Г.* Кендек әбиләре // Безнең гәҗит 2012, №11 (21 март).

*Гаркави А.Я.* Дополнения к сочинению «Сказания мусульманских писателей о славянах и русских. СПб.: Тип. Цидербаума, 1871.

*Гордлевский В.А.* Что такое «босый волк». Избр. соч., т. 2. М., 1961.

*Госманов М.Г.* Гасырдан – гасырга. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 488 б.

*Госманов М.Г.* Каурый каләм эзеннән: археограф язмалары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. 464 б.

Гумилев Л.Н. Древние тюрки. М.: Товарищество Клышников, Комаров и К`, 1993. 527 с.

*Гурвич И.С.* Космогонические представления и пережитки тотемического культа у населения Оленекского района // СЭ. 1948. № 3. С.

*Д`Оссон А.К.* История монголов. От Чингиз-хана до Тамерлана. 2-е изд., рус. пер., т. 1, Иркутск, 1937

*Давлетшин Г.М.* Волжская Булгария: духовная культура. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 192 с.

*Давлетшин Г.М.* Научные и прикладные знания // История татар с древнейших времен. В семи томах. Т. III. Улус Джучи ( Золотая Орда). XIII – середина XV в. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2009. С. 644-653.

*Данзан Лубсан.* Алтан тобчи / перевод с монгольского, введение, комментарий и приложения Н.П. Шастиной. М.: Наука, Гл. редакция восточной литературы, 1973. 440 с.

*Дәүләтшин Г.М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 512 б.

Дәфтәре Чыңгыз-намә / китапны басмага әзерләүче сүзлек һәм аңлатмаларның авторы Сәлим Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 2000. 44 б.

*Джувейни Ата-Мелик.* Чингизхан. История завоевателя мира, записанная Ала-ад-Дином Ата-Мелик Джувейни / перевод с текста Мирзы Мухаммеда Казвини на английский язык Дж.Э. Бойла; с предисловием и библиографией Дэвида О. Моргана; перев. с анг. Е.Е. Харитоновой. М.: Магистр-Пресс, 2004. 690 с.

*Дилакторский П.* Из преданий и легенд Кадниковского уезда Вологодской губернии // Этнографическое обозрение. Кн. XLII. М., 1899. № 3. С. 173–174.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Закирова И.Г.* Мәңгелеккә аккан сулар бар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. – Б. 240–266.

*Закирова И.Г.* Народное творчество периода Золотой Орды: Мифологические и исторические основы: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Казань, 2011.

*Иванов В.В.* Реконструкция индоевропейских слов и текстов, отражающих культ волка. Известия АН СССР: серия литературы и языка, 1975. Т. 34. № 5.

Идегәй. Татар халык дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 254 б.

Из родословия тюрков // Сборник материалов относящихся к истории Золотой Орды. Извлечения из персидских сочинений собранные В.Г. Тизенгаузеном. т. II. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1941.

Известия о Хозарах, Буртасах, Болгарах, Мадьярах, Славянах и Руссах Абу-Али Ахмеда Бен Омар Ибн-Даста, неизвестного доселе арабскаго писателя начала X века, по рукописи Британскаго музея / издал, перевел и объяснил Д.А. Хвольсон. СПб.,1869.

*Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре. Казан, I т., 1959. 916 б.; II т. 1963. 960 б.; III т. 1967. 1014 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык табышмаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 568 б.

*Карпини Дж. дель и Рубрук Г.де.* Путешествие в восточные страны Плано Карпини и Рубрука / перевод А.И. Малеина; редакция, вступительная статья и примечание Н.П. Шастиной. М.: Государственное издательство географической литературы, 1957. 270 с.

*Катанов Н.Ф.* Качинская история о сотворении мира // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. Казань, 1894. Т. 12. Вып. 2. С. 185–188.

*Ковалевский А.П.* Книга Ахмеда Ибн Фадлана о его путешествии на Волгу в 921-922 гг. Харьков: Изд-во Харьковского университета, 1956.

*Козин С.А.* Сокровеное сказание. Монгольская хроника 1240 г. под названием Mongjol-un nijuca tobciyan Юань чао би ши. Монгольский обыденный изборник / Институт востоковедения АН СССР. М.-Л : Изд-во АН СССР, 1941. Т. I: Введение в изучение памятника, перевод, тексты, глоссарии. 618 с.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф / төз. Н. Хисамов. Казан: «Дом печати», 2008. 604 б.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 544 б.

*Коновалов П.Б.* Об историческом и этническом сознании средневековых монголов // Тайная история монголов: источниковедение, филология, история. Новосибирск: Наука, 1995. С. 26–48.

Коран. Перевод смыслов и комментарии Валерии Пороховой / Просветительский Центр Аль Фуркан. Дамаск–Москва. 1996. 800 с.

Коръән тәфсире. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 684 б.

*Кошгарий М.* Туркий сузлар девони (Девону луготит турк). Тошкент: Узбек. ССР ФА нашр., Т. I. 1960. 498 б.; Т. II. 1961. 427 б. ; Т. III. 1963. 460 б.

*Крамер С.Н.* Мифология Шумера и Аккада. Мифология древнего мира. М.: Наука, 1977. 402 с.

*Крейнович Е.А.* Очерк космогонических представлений гиляк острова Сахалина // Этнография. 1929. № 1.

*Криничная Н.А.* Нить Жизни (Реминисценции образов божеств судьбы в мифологии и фольклоре, обрядах и верованиях). Петрозаводск: Изд-во Петрозаводского университета, 1995. 41 с.

*Криничная Н.А.* Персонажи преданий: становление и эволюция образа. Л.: Наука, 1988. 192 с.

*Кун Н.А.* Легенды и мифы древней Греции. Душамбе: Гл. науч. ред. тадж. сов. энциклопедии, 1988. 287 с.

*Лундквист А.* Воля неба: картины из жизни Чингисхана. М.: Аграф, 2001. 240 с.

Маадай Кара: Алтайский героический эпос/ запись текста, перевод на русский язык и приложения С. Суразакова; подготовка тома и вступительная статья И.В. Пухова. М.: Наука, 1973. 474 с.

*Малов С.Е.* Енисейская письменность тюрков. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1952. 116 с.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюкской письменности. Тексты и исследования. М.-Л.: Изд-во АН СССР,1951. 452 с.

*Мелетинский Е.М.* Фольклор австралийцев // Мифы и сказки Австралии. М., 1965. С. 3–24.

*Мәһдиев М.С.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. III т.: повесть, роман. Казан, 2009.

Мифы древнего мира / составитель М.Б. Бурдыкина. СПб.: Каравелла, 1995. 496 с.

Мифы народов мира: Энциклопедия в 2-х т. / гл. ред. С.А. Токарев. 2-е изд. М.: Советская энциклопедия. I т. 1991. 671 с. II т. 1992. 719 с.

*Мишель Хоанг.* Чингисхан. Ростов-на-Дону: «Феникс», 1997. 352 с.

*Мөслими Х.* Рисаләи тәварихы Болгария вә зикри мәүләнә хәзрәте Аксак Тимер вә харабе Шәһри Болгар. Казан, 1887.

*Мөхәммәдъяр*. Нуры Содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

Мэн-да бэй-лу («Полное описание монголо-татар») / факсимиле ксилографа; перевод с китайского, введение, комментарий и приложения Н.Ц. Мункуева. М.: Наука, Гл. редакция восточной литературы, 1975. 286 с.

*Негматов Н.Н., Соколовский В.М.* Капитолийская волчица в Таджикстане и легенды Евразии // Памятники культуры: Новые открытия: Ежегодник,1974. М., 1975.

*Низами.* Поэмы и стихотворения. Л.: Советский писатель, 1960. 489 с.

*Никифоров Н.Я.* Аносский сборник. Собрания сказок алтайцев с примечаниями Г.Н. Потанина // Записки Западно-Сибирского отделения русского географического общества. Омск, 1915. 293 с.

*Пиотровский М.Б.* Ислам и судьба // Понятие судьбы в контексте разных культур / Научный совет по истории мировой культуры. М.: Наука, 1994. С. 92–97.

*Пиотровский М.Б. Коранические сказания.* М.: Наука, Главная редакция восточной литературы, 1991. 219 с

*Потанин Г.Н.* Казах-киргизские и алтайские предания, легенды и сказки // Живая старина. Петроград, 1917. вып. 2–3 за 1916 г. 152 с.

*Потапов Л.П.* Умай – божество древних тюрков в свете этнографических данных // Тюркологический сборник. 1972. М.: 1973. С. 265–286.

*Пропп В.Я.* Исторические корни волшебной сказки. Л.: Изд-во ЛГУ, 1946. 340 с.

Путешествие Абу Хамида ал-Гарнати в Восточную и Центральную Европу (1131–1153 гг.) / Публикация О.Г. Большакова, А.Л. Монгайта. М.: Гл. ред. вост. лит., 1971. 134 с.

*Рабгузи Насретдин.* Кыйссасел Әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. 479 б.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменьских татар. СПб., 1872. 411 с.

*Рашид-ад-дин.* Сборник летописей. Т. 1. Книга вторая. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1952. 223 с.

*Сагалаев А.М.* Мифология и верования алтайцев. Центрально-азиатские влияния. Новосибирск: Наука, 1984. 120 с.

*Сагалаев А.М., Октябрьская И.В.* Традиционное мировоззрение тюрков Южной Сибири. Знак и ритуал. Новосибирск: Наука. Сиб. отд-ние, 1990. 209 с.

*Садекова А.Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество. Казань: Фикер, 2001. 260 с.

Сибирские сказания / переводы и переложения А.В. Преловского. М.: Современник, 1991. С. 37–124.

Сказание о Чингизхане / перевод В.А. Панова // Тамерлан. Автобиография, уложение. М.: Изд-во Эксмо, 2005.

*Суразаков С.С.* Алтайский героический эпос. М.: Наука, 1985. 256 с.

*Суразаков С.С.* Героическое сказание о богатыре Алтай-Буучае. Горно-Алтайск: Алт. кн. изд-во, 1961. 179 с.

Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.- 338 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры / төзүчесе Рәшит Ягъфәров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Беренче китап / томны төзүчеләр, искәрмәләрне хәзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Беренче китап. Казан, 1977.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Икенче китап / томны төзүчеләр, искәрмәләрне әзерләүчеләр Х.Х. Гатина, Х.Х. Ярми. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.

Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче И.Н. Надиров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.

Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Хуҗиәхмәт Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.

Татар халык иҗаты. Бәетләр / томны төзүчеләр: Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова; кереш мәкалә авторлары: Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, Р.Ф. Ягъфәров. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 352 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

Татар халык иҗаты. Табышмаклар / томны төзүче, искәрмәләрне әзерләүче һәм кереш мәкаләне язучы Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 271 б.

Татар энциклопедия сүзлеге. Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2002

Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләрне язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. 640 б.

Татарский энциклопедический словарь. Казань: Институт татарской энциклопедии АН РТ, 1998. 703 с.

*Тимковский Е.Ф.* Путешествие в Китай через Монголию в 1820 и 1821 гг. СПб., 1824, ч. I. 509 с.

*Топоров В.Н.* Космогонические мифы // Мифы народов мира. М., 1995. Т. 2. С. 6–9.

*Топоров В.Н.* О космогонических источниках раннеисторических описаний // Труды по знаковым системам. VI. Тарту: Тип. Им. Х. Хейдеманна, 1973. С. 106-150.

Төш юрау китабы / Текстны туплаучы, фәнни эшкәртүче, искәрмәләр авторы Марсель Әхмәтҗанов. Казан: Татар «Мирас» фонды. 1991.

Традиционное мировоззрение тюрков Южной Сибири. Пространство и время. Вещный мир / Э.Л. Львова, И.В. Октябрьская, А.М. Сагалаев, М.С. Усманова. Новосибирск: Наука, Сиб. отд-ние, 1988. 225 с.

Традиционное мировоззрение тюрков Южной Сибири. Человек. Общество / Э.Л. Львова, И.В. Октябрьская, А.М. Сагалаев, М.С. Усманова. Новосибирск: Наука, Сиб. отд-ние, 1989. 243 с.

*Тукай Габдулла.* Әсәрләр: биш томда. I т. Шигырьләр, поэмалар (1901–1908). Казан, 1985.

*Турсунов Е.Д.* Древнетюркский фольклор: истоки и становление. Алматы: Дайн-Пресс, 2001. 172 с.

*Тэйлор Э.* Первобытная культура. М.: Государственное социально-экономическое издательство, 1939. 568 с.

*Улагашев Н.У.* Алтай-Бучай. Ойротский народный эпос / под редакцией А. Коптелова. Новосибирск: ОГИЗ – Областное государственное издательство, 1941.- 408 с.

*Улагашев Н.У.* Малчи-Мерген. Алтайский героический эпос / под ред. А Коптелова. Горно-Алтайск, 1947. 230 с.

*Урманче Ф.И.* Народный эпос «Идегей». Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, 1999. 200 с.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: I т. (А–Г). Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.; II т. (Д–С). 2009. 343 б.

*Урманчеев Ф.И.* Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 312 с.

*Урманчеев Ф.И.* По следам белого волка: Ранние этнокультурные взаимосвязи тюрко-татарских племен. Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ, 1994. 125 с.

*Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. 224 с.

*Фрейденберг О.М.* Миф и литература древности. 2-е изд., испр. и доп. М.: Издательская фирма «Восточная литература» РАН, 1998. 800 с.

*Халидова М.Р.* Мифологический и исторический эпос народов Дагестана. Махачкала: Даг. науч. центр РАН, Ин-т яз., лит. и искусства им. Г. Цадасы, 1992. 273 с.

*Халиков А.Х.* Беренче дәүләт: Болгар иле. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 216 б.

*Халиков А.Х.* Отражение космогонических и генеалогических легенд волжских булгар в археологических материалах // Из истории ранних булгар: (Сб. ст.) / ред. А.Х. Халиков. Казань, 1981. С. 5–20.

*Хисаметдинова Ф.Г.* Мифологический словарь башкирского языка. М.: Наука, 2010. 456 с.

*Хомонов М.П.* Образцы общемонгольского фольклора в «Сокровенном сказании монголов» // «Тайная история монголов»: источниковедение, история, филология. Новосибирск: Наука, 1995. С. 123–127.

*Хузин Ф.Ш.* Волжская Булгария в домонгольское время (X – нач. XIII вв.). Казань: Фест,1997.

*Цултэм Ням-Осорын.* Искусство Монголии с древнейших времен до начала XX в. М.: Изобразительное искусство, 1982. 232 с.

*Шпилевский С.М.* Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань: Университетская типография, 1877. 587 с.

*Юсуф Хос Хожиб.* Котадгу билиг. Тошкент: Фан, 1971.

ЭЧТӘЛЕК


Кереш сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Әүвәл башлап ни битти? (Космогоник мифлар һәм легендалар) . 5
Үзенә итагать өчен төзде халкын...
(Татар халкының генеалогик легендалары) . . . . . . . . . . . . 23
Күбәләктәй җан биргән (Төрки фольклорда җан белән
бәйле ышанулар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Үземнең котым бар өчен... (Борынгы кот/кут сүзенең
мәгънәләре турында) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Тәкъдиренә ни язган булса Ходa... (Төрки фольклорда
һәм Урта гасырлар әдәбиятында язмыш мифологемасы) . . . 47
Су иясез булмый (Төрки-татар фольклорында су
һәм су ияләре белән бәйле мифологик мотивлар) . . . . . . . . 64
Бердер Аллаһым бәнем (Татар халкының ислам динен
кабул итү турындагы риваятьләре һәм дини эчтәлекле
легендалар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Туган телдә кылган догам (Татар фольклорында
багышлау жанры) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Алкыш алган – арымас... (Татар фольклорының
алкыш жанры) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
Ары утырың, инәлекләр (Татар фольклорында
кендек әбиләре образы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Мәңке бабайга сәлам (Татар халкының
«Боз озату» йоласы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Хан билгесе ту булыр (Фольклорда һәм татар
әдәбиятында хөкемдар образы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Чыңгыз хан үткән дөньядан (Төрки-монгол халыклары
фольклорында Чыңгыз ханның эпик биографиясе) . . . . . . 129
Йомгак урынына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Файдаланылган әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144

Научное издание

**Закирова Ильсеяр Гамиловна**

**ӘҮВӘЛ БАШЛАП НИ БЕТТЕ**

(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать: 16.11.2017.
Печать офсетная. Гарнитура «Cambria».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 8,8. Уч.-изд. л. 6,4. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

ООО «ТКС Контакт»
420021, Казань, ул. Г. Тукая, 91